

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 8 / 2022
СӨЕМБИКӘ
ISSN 0869-1398
ә мәхәббәт
ГОМЕРЛӘРДӘН
ОЗЫН
булган хәл
ӘНИ ТҮГЕЛ,
ӘНИЕМ
җылы кочакта –
13 бала
алмалы крамбл
август –
АЛМА АЕ
Рәзинә
ХИСАМЕТДИНОВА:
«Безнең эшебез
яратудан башлана...»

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

Әнием белән әтиемнең туйлары сентябрьнең бик яңгырлы бер көненә туры килгән. Авыл җирендә андый көнне күлмәкнең аклыгын саклап калу – ай-һай, авыр шул... Туйның икенче көне әле әниемнең туган авылында – Кече Елгада да үтәсе икән. Туй күлмәгенең бөтен матурлыгын, аклыгын, сафлыгын үз авылында да күрсәтәсе килә бит!.. Әтием белән әнием туйдан соң төне буе мунчада икәүләшеп туй күлмәгенең итәген юганнар... Иртәгәсен кәләш ягында да туй гөрләгән. Ә әнием – янә ап-ак күлмәктән...

Динә ШАҺИЕВА.
Лаеш районы, Державино авылы.
Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Наил Зыятдинов

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасарлары 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Рәзинә Хисаметдинова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.07.2022 ел.
Чыгу көне: 1.08.2022 ел.
Заказ О-2272
Тираж 8732

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык), П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: ПО279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



«   ».

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Ак калфак

(Поэмадан өзек)


Их! Башлыйсы иде өр-яңадан –
Ак биләүдән – иң гөнаһсыз чактан.
Ап-ак сөттән, ап-ак каеннардан,
Ак ефәк шәл белән – Ак калфактан!!!
Ай, Ак калфак! Көмеш ай, ука-чук,
Чын осталар чиккән – беркайда юк!..
Җепкә тезгән энҗе – ак инәдә,
Энҗе калфак – милли хәзинә лә...
Ах, Ак калфак! Сихри нурың ахак!
Әбием догаларын калган отып...
Ант итәрлек – изге гамәлләргә,
Ант иткәндәй бабам, Коръән тотып...
Юк, кагылмыйм әле китапларга,
Исемнәргә, бөек талантларга, –
Күкрәгемә кысып ант итәрлек
Изге мирас – Ак калфагым барда, –
Мин ант итәм бүген сезнең алда,
Хәмдияләр, Лалә, Сөмбелләрнең
Ак калфагы белән – безгә калган...
Ишетеп торсын апа-сеңелләрем...
Әнкәм сөте төсе итеп аны,
Ак биләүләр төсе итеп аны,
Ак әбием төсе итеп аны –
Саклап кына киярмен мин тагы!!!

* * *

Их! Башлыйсы иде өр-яңадан,
Ап-ак сөттән – иң гөнаһсыз чактан...
Туен көткән керсез ак күлмәктән,
Ак ефәкләр белән – Ак калфактан!!!


1992





Безнең тышлыкта

«Мондагы әби-бабайларны күргәч, күзгә яшьләр килә иде. Хәзер дә шул ук әби-бабайлар, хәзер дә шул ук мохит, ләкин без үзебезне башкача тотарга өйрәндек. Аларга күз яшен күрсәтергә ярамый. Шуңа күрә елыйсы килсә, урамда елап бетерәбез, алар янына елмаеп керәбез.»



12

Диңгез күзле ут Рәзинә

Фәнзилә Мостафина







6 Агылып торыр «Ак калфак»ның нуры!

Эльмира Закирова

20 Беренче адым

Лилия Гәрәева

24 «Баланы хезмәт тәрбияли»

Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Заман һәм без

Татар самурае 16
Чулпан Галиәхмәтова

Начар һәм яхшы кредитлар 19
Ләйсән Халикова

Татар дөньясы

Гыйльфановлар килене мин! 26
Фәнзилә Гыйльфанова

Намаз 29
Илнар хәзрәт Зиннәтуллин

Эх күңелле өмәсе! 30
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш

Керфек чыланган мәл. Карашың – сөюдән төнәтмә 42
Энҗе Хөсәенова. Дания Нәгыйм

Нәнәй догасы 44
Гөл Мирһади

Яшәеш

Хатлар 50

«Ә мәхәббәт гомерләрдән озын...» 52
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау–җавап 56

Детокс 58


Кобидо 59

Өйнең яме – гөлләрдә 62

Тест& йолдызнамә 63

Сыннарында – татар мохите 64
Зилә Нигъмәтуллина

34




«Ерып барырга яратам!»
Алсу Шакирова

38



«Иң бәхетле көнем...»
Гөлнур Сафиуллина

60



Алмалы крамбл
Резеда Мусина тәкъдим итә

АКТУАЛЬ ТЕМА

АГЫЛЫП ТОРЫР «АК КАЛФАК»НЫҢ НУРЫ!











Эльмира ЗАКИРОВА

Ак калфак... Татар хатын-кызларының сафлыгы, матурлыгы билгесе. Аңа миллилек тә, затлылык та, тарих та сыйган. Ак калфак кигән кыз башын горур һәм югары тотып йөргән. Безгә – татар кызларына шуны сеңдереп үстерделәр. Һәм менә шушы образ, татар хатын-кызының тышкы матурлыгы, бизәге генә булып калмыйча, аны тирәннәнрәк ача, аңа бик күп вәкаләтләр, җаваплылык өсти торган зур символга – татар милләтенең рухи бишегенә әйләнде. Сүзем – Бөтентатар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы турында. Моннан 30 ел элек, 1992 елның июнендә Бөтендөнья татар конгрессы оешкан көннәрдә дөньяга аваз сала ул. «Сөембикә» редакциясендә туган әлеге оешманың башында журналның баш мөхәррире, күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм язучы Роза Туфитуллова тора. Милләтнең киләчәге татар кызларында икәнен тирәнтен аңлаган бер төркем зыялы хатын-кызлар «Ак калфак» тирәсенә туплана. Шул көннән «Ак калфак» хатын-кызлар өчен хикмәтле сүзгә әйләнеп китә.

«Сөембикә» журналистлары өчен «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы уздырган һәр чара – зур вакыйга. «Гыйффәт туташ», «Киленбикә» Халыкара бәйге-тамашаларын, «Бишек җырлары» конкурсларын кайта-кайта искә төшерәбез. Шулай булмыйча! Үзебез дә шул дөньяда кайныйбыз бит. Хәзер дә милләттәшләребез яши торган төбәкләргә – Башкортстан, Чуашстан, Пенза, Пермь, Оренбург, Әстерхан, Чиләбе якларына барып чыгабыз, Татарстан авылларын иңлибез.

Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессында «Ак калфак»лар белән булып узган җылы очрашу кабат бөтен хатирәләрне яңартты. Конгрессның конференцияләр залында – таныш йөзләр, абруйлы ханымнар. «Ак калфак»ның «әнисе», оешмага нигез салучы күренекле җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова, төрле елларда аның эшен дәвам иткән, Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе директоры буларак тарихка кереп калган Камәрия Хәмидуллина, педагогика фәннәре докторы, профессор Резеда Мөхәмматшина, «Ак калфак» оешмасының бүгенге җитәкчесе Кадрия Идрисова... Борынгы Болгар дәүләтеннән башлап хәзерге көннәргәчә хатын-кызларның икътисадый, иҗтимагый-сәяси хәлен өйрәнгән тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимирова, галимәләр Лена Таҗиева, Рәүфә Уразманова; «Ак калфак» эшләрен халыкка иң актив җиткерүче язучы-журналист Роза Камалетдинова, язучы Нәзифә Кәримова; оешма җитәкчеләренең уң кулы булып җигелеп эшләп йөргән Филисә Хәкимова, аналар һәм балалар хокукын яклап мөнбәрләрдән чыгыш ясаган депутат Сүрия Усманова, табибә Руфина Фәттахова, телевидение режиссерлары Дания Гаязова һәм Лилия Нигъмәтова, сәнгать белгече, Г. Тукай премиясе лауреаты, шагыйрә Розалина Шаһиева, күренекле артисткабыз Дания Нуруллина, халкыбызның яраткан җырчысы Гөлзадә Сафиуллина, Әстерхан, Ульяновскида милләт өчен җан атып йөргән Наилә Потеева, Сәйдә абыстай Аппакова... Һәркайсының җан җылысы, күңел байлыгы кучкән «Ак калфак»ка. Ә оешмага «Ак калфак» исемен күренекле галимә Флора Әхмәтова-Урманче тәкъдим иткән булган! Камәрия Зиннур кызы әнә нәрсә ди: «Ни генә дисәк тә, «Ак калфак» ул – барыбер Роза ханымның баласы, «Сөембикә» журналы – аның бишеге. Мин ул калфакны да, «Сөембикә»не дә талбишектә тибрәлеп ята торган бала итеп күз алдыма китерәм...» Кадрия Рәес кызы да шул фикерне куәтли: «Башланган эшне алып бару, дәвам итү – бер нәрсә. Аны оештыру, юк җирдән бар итү – анысы инде бөтенләй башка! «Ак калфак»ның чишмә башында торган Роза апа Туфитуллова милләтне саклап калуда хатын-кызның төп ролен безгә программа итеп калдырды», – ди. «Ак калфак»ның бүгенге җитәкчесе Кадрия Идрисовага Роза ханым Туфитуллованың ак энҗе мәрҗән муенса бүләк итүендә дә тирән мәгънә бар. Димәк, традицияләр дәвам итә!

Их! Башлыйсы иде әр-яңадан –
Ак биләүдән – иң гөнаһсыз чактан.
Ап-ак сөттән, ап-ак каеннардан,
Ак ефәк шәл белән – Ак калфактан!..

Луара Шакирҗанова, апасы Лена Шагыйрьҗанның «Ак калфак» шигырен укып, кабат 1992 елның июненә, Бөтендөнья татар конгрессы оешкан көннәргә алып китте... Конгрессның «Милләт, хатын-кыз һәм гаилә» секциясе утырышында «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза Туфитуллованың татар милләтен саклап калу турындагы тирән чыгышы... «Дөньяны аклыкка, пакьлеккә күмәргә килә торган оешма», – дип, Төркиянең Мәрмәрә университеты профессоры Надир Дәүләтнең «Ак калфак»ка югары бәясе...

30 ел дәверендә «Ак калфак» оешмасы башкарган игелекле эшләрне туплап, зур бер китап язарлык. «Ак калфак»ның Екатеринбург, Уфа, Төмән, Санкт-Петербург, Иваново шәһәрләрендә эшләп килүче оешмалары чакыруны да көтеп тормаганнар, берәр кызыклы тәкъдим килеп чыгуга, шундук Казанга килеп җитә торган булганнар. «Ак калфак» шулай ук БДБ һәм ерак чит илләрдә дә үзенә теләктәшләр таба. Америка, Австралия, Канада, Финляндия, Япония, Төркия, Кытай кебек илләрдә яшәүче татар хатын-кызлары да «Ак калфак»ның бүлекчәләрен оештырып җибәрә. Төрле елларда «Ак калфак»ны җитәкләгән зыялы ханымнарны тыңлыйк әле. Ул истәлекләр – үзе бер тарих. Матур хатирәләр дә, өмет-хыяллар да, каршылыкларны җиңү дә...





Халыкара «Киленбикә» бәйге-тамашадан бер күренеш. Сәхнәдә – Роза Туфитуллова һәм Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина.



1993 ел. Фотосурәттә – бөтен татар дөньясын шаулаткан «Гыйффәт туташ» бәйге-тамашаның авторы, күренекле журналист Филисә Хәкимова һәм Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Айдар Хафизов. (Режиссёры – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Дания Гаязова).



Әлфинур Гафурова (Санкт-Петербург), Наилә Потеева (Әстерхан), Фәридә Кудашева (Уфа), Роза Туфитуллова, Бибинур Сабирова (Төмән).



Роза ТУФИТУЛЛОВА,
күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист, язучы

Бөтендөнья татар конгрессының I съезды барган көннәр. «Кемнәр без – татар хатын-кызлары?» кебек сораулар кат-кат яңгыраган иде ул чакта. «Ак калфак» – Бөтендөнья татар конгрессы белән берлектә, аның кысаларында эшләп китте. Конгрессның Башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров бик күп игелекле эшләребезгә хәер-фатыйха биреп килде. Берчак Казакъстанның Семипалатинск шәһәрендә татар конгрессының күчмә утырышы барган көннәрдә бер татар гаиләсе кунакка дәшеп алды. Табын янына утыруга, махсус безнең өчен видеоязма куеп җибәрделәр. Бу безнең «Гыйффәт туташ» видеосы иде. Казанга йөреп торучы Чимкент кешесе алып кайткан. Аннан яздырып алып, башкаларга тараткannar. Бу минем өчен Симей шәһәрендә ишеткән иң кадерле сүзләр булды. 1999–2000 елларда безнең берләшмә дөньяны сугышлардан арындыру максатыннан «Ак яулык» акциясен уздырды. Борынгы бабаларыбыз – төрки халыкларда күркәм бер гадәт булган. Ир-атлар бәхәсне сугыш юлы белән чишәргә тотынса, төркиләрнең зирәк хатын-кызлары башларындагы ак яулыкларын алып, уртага сала торган булганнар. Сугышны туктатыгыз дигәнне аңлаткан бу. Безнең акциядә катнашучылар исә ак яулыкларга төрле телләрдә иң изге теләкләрен яздылар. Без юллаган 627 яулык БМО штаб-квартирасына барып ирешә. Милләт хатын-кызлары үз сүзен дөньяга шулай җиткерде. Милләт язмышын үз кулына алырдай буын саф милли гаиләләрдә генә туа, үсә ала. Баланың яшәү рәвешен, телен, иманын иң әүвәл һәм гомерлеккә дип әнкәсе сеңдерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең: «Ана, Ана, тагын бер тапкыр Ана, бары шуннан соң гына Ата», – дигән гыйбрәтле сүзләре шул хакта түгелмени? Татарның киләчәге иң әүвәл ана карынында, бишектә, гаиләдә хәл ителә. Менә ни өчен яшь кызларыбыз, булачак әниләр, яшь әниләр белән эшләүне без иң кирәкле, иң мөһим юнәлешебез итеп алдык. Минем өчен Бакый Урманче, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники кебек абруйлы затларның фикере, киңәшләре һәрчак таяныч булды. Язучы Гомәр ага Бәширов: «Татар хатын-кызы, ир хатыны булудан бигрәк, беренче чиратта балалар анасы ул», – дия торган иде. Милләтнең асыл сыйфатларын килер буыннарга тапшырырлык әниләр тәрбияләү бурычын олы максатыбыз итеп күрдек ул чакта. Уфада яшәүче язучы Сәйфи Кудаш бер хатында: «Роза җан! Тәвәккәллегегез алдында башымны иям. Сезгә бүләк итеп гаиләбездә мин белә-белгәннән бирле үсеп, чәчәк атып утыручы «Мәрьям ана» гөлен җибәрәм. Нишләргә икәнен үзегез чамаларсыз...» – дип язды. Милләтне саклап калыр өчен күп балалар тудырырга кирәк дигән фикерен Сәйфи ага әнә шулай гөл орлыкларына да төреп җибәрде. Ни генә димәсеннәр, бүгенге татарның язмышы хатын-кыз кулында. «Сөембикә» журналына биргән интервьюсында (иң соңгы интервьюларының берсе ул) күренекле рус галиме Лев Гумилев: «Татар кавеме үзенең югалмый калуы белән татар Анасына бурычлы. Бу халыкның барлык уңышлары балаларын зирәк тәрбия кыла белүдән, гыйлемгә омтылудан», – дигән иде. Бүген әниләргә мөнәсәбәтле тагын бер игелекле эшебезне искә алмый булдыра алмыйм. Ул да булса – кыз балалар өчен махсус гимназияләр оештыруыбыз. Казанда татар кызлар гимназиясен ачу һәм аны яшәтү өчен никадәр көч түгүебезне генә сөйләсәм дә, «Ак калфак»ның милли хәрәкәтебездә әзле оешма булуын раслаучы фактлар килеп чыгар иде. Җәмгыятебезгә хатын-кызның йөрәк тавышын ишеттерер өчен икеләтә, өчләтә зирәклек күрсәтү, нечкә дипломатиягә ия булу сорала иде. Кирәк чакта митинглардан да баш тартмадык. Чечен сугышы барганда солдат аналарын яклап, үз сүзебезне – әниләр сүзен әйттек.



Камәрия ХӘМИДУЛЛИНА,
Татарстан Республикасының
халык укытучысы,
күренекле җәмәгать эшлеклесе,
Казан шәһәр Думасы депутаты

Роза Рәхмәтулловна милли мәгариф проблемаларын да шушы «Ак калфак» оешмасы эшчәнлегендә күрде. Ул елларда безнең татар гимназиясе уңышлы гына эшләп килә иде инде. Роза ханым мине гел мәгариф мәсьәләләренә кагылышлы сөйләшүләргә тарта башлады. Үзе Дәүләт Советына депутат итеп сайлангач, «Ак калфак»ны җитәкләүне миңа тапшырды. Эшчәнлегебездә төп юнәлешне милли мәгарифне күтәрүдә күрдем. Мәскәү, Петербургларда, башка зур шәһәрләрдә шимбә-якшәмбе мәктәпләре эшли башлады. Мәскәүдә Лемма Гыйрфанова татар этно-мәдәни компонентлы 1186 нчы мәктәпне ачып җибәрде. Лемма ханым безнең гимназиягә кайтып, безнең концепцияләрне алып, без аларга барып, бер-беребезгә булыштык. Ә Нәзифә Кәримованың Мәскәүдәге «Зыялылар клубы» «Ак калфак» өчен үзенә күрә бер табыш иде! Төмәндә Бибинур апа «Ак калфак» газетасын чыгарды. Ивановода Мәстүрә ханым Ляпина татар теле дәресләре укытуны җайга салды. Без аңа гимназиядән, татар мәктәпләреннән кулланылыштан чыккан татарча дәреслекләр җибәрүне оештырдык... Эшчәнлегебездә икенче юнәлеш тә барлыкка килде. Гимназиянең музыка мәктәбендә эшли торган Диләрә ханым, төрек кешесенә кияүгә чыгып, Сан-Францискога яшәргә китәр алдыннан саубуллашырга керде. «Китсәм дә «Ак калфак»ка булышып торырмын, Камәрия ханым, яме», – ди. Берәр елдан соң болар гаиләсеннән хат килеп төште. Ире яза. «Әйдәгез, шундый проект башлыйбыз. Без татар мәктәпләренең инглиз теле укытучыларын үзебездә яшәтеп, инглиз теле курсларына стажировкага чакырабыз», – дигән. Укытучыларны җибәрдем башта, аннары балаларга да чират җитте. Андый игелекле җаннар шактый иде. Америкадагы Шәмсия Апакай, Төркиядәге Гөнүл Полтар, Гөлтан Ураллылар, Австралиядән Фирдәвес Садри, Франкфурттагы Җәмилә ханым, Башкортстаннан Кифая ханымнар... Әлмира апа Әдиатуллина болай да үзҗитеш кеше иде. Аның үз оешмасы, «Мөслимә» газетасы, «Сөембикә энеләре, сеңелләре» конкурсы бар. Әмма безнең бер җыелышны да калдырмады. «Әйдәгез, «Ак калфак» тирәсенә берләшәбез», – дип, беренче булып гариза да язды. Ул көчле шәхес иде! Колшәриф мәчете каршындагы сыра киоскын да алдыртты, мөселман хатын-кызларына паспортка яулыктан төшү хокукын да ул яулап бирде. 2003–2004 елларда милли мәгарифтә артка тәгәрәү башланды. 2008–2010 елларда исә имтиханны ана телендә тапшыру хокукы бетерелде. БДИны рус телендә генә тапшыру турында законнар кабул ителде. Ана телендә укыган балалар имтиханны үз телендә тапшырырга тиеш дип, ата-аналар исеменнән мәхкәмәгә гариза бирдем. Әлбәттә, Мәскәүдә суд Мәгариф министрлыгы ягында иде. Югары судка мөрәҗәгать иттек, Европа судына бирдек. Ләкин эшне алга таба күтәреп алып китүче булмады. Шәхси хатлар, ата-аналарның шушы карарны юкка чыгару турындагы фикерләре җитеп бетмәде. Без моны халыкның сүлпәнлеге, инертлыгы дип бәялидек инде. Татар телендә укыта торган гимназияләр бетте. Өйдә, гаиләдә өйрәтергә кирәк телгә, диделәр. Тукталып калмадык, эшне студент кызлар белән алып бару планы бөреләнә башлады. Казан–Татарстан–Россия–Дөнья. Менә шушы чылбырда интеллектуаль лидерлык потенциалы булган хатын-кыз катламын күрәсе килә. Бүгенге көндә хатын-кыз фикере җитми. Җәмгыятьне савыктыру өчен хатын-кыз фикере кирәк! Мөхлисә Бубыйлар, Сорбоннада укыган Сара Шакуловалар кимәлендәге хатын-кызларыбызны да «Ак калфак»ка тартып, эшчәнлекне гыйльми нигездә оештыру турында уйланасы бар, минемчә.



■ Камәрия Хәмидуллина, Роза Туфитуллова, Руфина Фәттахова, Флора Әхмәтова-Урманче «Ак калфак» кунаклары белән.



■ 2007 ел. Казан. Россия мөселман хатын-кызларының Мәскәүдә уздырылган I съездының 90 еллыгына багышланган Россиякүләм форумы. Түгәрәк өстәл утырышы президиумында – Россиянең Иҗтимагый палата әгъзасы Роза Туфитуллова. «Ак калфак» оешмасы рәисе Камәрия Хәмидуллина, Ливан кунагы Надә-эль-Аюби.



■ «Ак калфак» эшендә милли тәрбия – һәрчак үзәктә.



2011 ел. II Бөтендөнья татар галимнәре форумы. Казан, Татарстан Фәннәр академиясе.



Бөтендөнья татар галимнәре форумы кысаларында «Ак калфак» оешмасы уздырган секция утырышы.



Студент кызлар – булачак укытучылар: телне алар саклап калыр!



Резеда МӨХӘММӘТШИНА, педагогика фәннәре докторы, КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры

– 2011 елның гыйнварында узган отчет-сайлау җыелышында мине «Ак калфак» оешмасының җитәкчесе итеп сайладылар. Кызым 2 нче гимназиядә укыган елларда миңа ата-аналар белән эшләргә туры килде, шуннан «Ак калфак» берләшмәсе эшчәнлегенә дә кереп киттем. Камәрия Зиннуровна: «Оешмабызны яшәртергә кирәк. «Ак калфак» рәисе итеп мин сине күрәм», – диде. Эстафетаны шундый мөхтәрәм кеше тапшырып торганда ничек каршы киләсең? Безнең институтта, нигездә, туташлар укый бит. Шуны күздә тотып, Камәрия ханым: «Эшне студент кызлар белән алып барыйк. Чөнки ул кызлар, укып бетереп, районнарга, авылларга кайталар, мәктәпләрдә эшлиләр. Телне шунда саклап калып була», – дип, киңәшләрен дә бирде. Россия күләмендә телгә каршы бара торган сәясәт көчәя башлаган чорга туры килде ул еллар. Милләт өчен бер яктан – милли мәктәп, икенче яктан тел көнүзәк мәсьәлә иде. «Ак калфак» эшчәнлеген, татар хатын-кызлары алып барган проектларны яңа киңлеккә алып чыгасым килде. «Мәктәпләрдә әдәбият белемен укытканда рус һәм татар мәдәниятләре диалогы» дигән темага докторлык диссертациясе яклавым шуңа бер адым булды. Мәскәүдә Россия Фәннәр Академиясендә милли мәгариф темасын күтәреп, татар хатын-кызлары эшчәнлеген танытуга ирештем. Татар, рус, төрек, славян, ислам, христиан культураларын өйрәнергә туры килде. Россия Фәннәр Академиясе профессоры Меджи Черкезова фәнни консультантым иде. Меджи Валентиновна татар мәктәпләрен күрәсе килә дигәч, аны Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенә алып бардым. Башка мәдәниятләрне өйрәнеп, чагыштырып карап кына кеше үз мәдәниятен яхшырак белә бит! Бөтен нәрсә чагыштыруда ачыла! Мәскәү кунагы милли традицияләребез ничек саклануын күреп, укытучыларның да, укучыларның да рус телен, борынгы рус культурасы чорын камил белүенә сокланып, таң калып китте. Гимназияне «Татарстанның йөзек кашы» дип атады. Кайткач та әле безнең эшчәнлекне югары бәяләгән.

Татарстан Фәннәр академиясе ул елларда бөтен дөньядан татар галимнәрен Казанга җыйды – зур фәнни форум булды ул. Америка, Австралия, Европадан бик күп галимнәр катнашты. «Ак калфак» оешмасына галимәләребезне тарта алган идем. Форумда алар да чыгыш ясады. Дания Заһидуллина, Альта Мәхмүтова, Әлфия Йосыповалар... Үземнең чыгышым «Катнаш никахлар һәм культуралар диалогы» дигән бик четерекле темага багышланган иде. Монда инде ярамый дип тыеп кына, ачуланып кына булмый, бик нечкә әйбер. Фатих Әмирханның «Хәят», Иван Тургеневның «Ася» повестьлары мисалында кыз баланы нәрсә көтүен, катнаш никахлар һәр милләт өчен дә бәла икәнлеген аңлатырга тырыштым. Коръәннең рухын бирә алып тәрҗемә иткән Валерия Пороховалны да чакырдык без.

«Ак калфак»ның кыйбласы үзгәрми – милли җанлы зыялы балалар үстерүче милләт аналарын тәрбияли ул.



Кадрия ИДРИСОВА,
филология фәннәре кандидаты,
Бөтендөнья татар хатын-кызлары
форумы җитәкчесе, төбәкара
«Ак калфак» татар хатын-кызлары
иҗтимагый оешмасы рәисе

Татарлар гомер кичергән һәр шәһәр, авылда татар хатын-кызлары оешмасы булсын иде дип хыялландым. Районнарда, төбәкләрдә татар хатын-кызлары үзләре үк: «Бездә дә «Ак калфак» оешмасы булсын әле», – дип мөрәҗәгать итә башладылар. Бүгенге көндә 17 якын һәм ерак чит илләрдә, Россия Федерациясенең 36 субъектында, Татарстанның 44 район-шәһәрендә «Ак калфак» оешмалары һәм бүлекчәләре эшләп килә. Оешманың максаты – татар хатын-кызларының милли генофондын саклау, милли хәрәкәткә җәлеп итү, татар гаиләсе нигезләрен, халык гореф-гадәтләрен, йолаларын, туган телне, халык педагогикасын, аш-су мирасын һәм милли киемнәрне торгызу, киләчәктә милләт аналары булырдай татар кызларын тәрбияләү, сәләтле һәм шәхес хатын-кызларны барлау, гаилә һәм нәселне тәрбия кылу. Күбрәк эшләгән, әлеге проблемаларга тирәнрәк кергән саен, бер нәрсәне ачыклый барам – кешеләр үзләренең тарихына, гореф-гадәтләргә сусаган икән. Әгәр дә 99 төймәдән торган дисбе чәчелеп китсә, аның соңгысына хәтле җыярга тырышабыз. Милли асылыңны барлау да шулай. Самарага баргач, губернаторның беренче ярдәмчесе үзенә чакырып алды. Оешманың эшчәнлеге белән кызыксынды. Бала тәрбияләүдән башлап, милли яшәешнең һәр баскычы турында сөйләдем. Шуннан ул: «Бездә 157 милләт вәкиле яши, аларның иң актив хатын-кызларын җыеп, семинар үткәрсәгез иде», – дигән тәкъдим белән чыкты. Димәк, алар безнең эшне өлге итеп ала! Эшебезне гаилә тәрбиясе, рухи тәрбия, мәдәни тәрбия, экологик тәрбия юнәлешләрендә алып барабыз. Һәрбер җирлектә үзләренә генә хас булган йолаларның үзенчәлекләрен эзлибез. «Ак калфак» исеме астында психологлар, икътисадчылар, юристлар катнашында «Яшь әниләр» мәктәпләре, «Яшь гаиләләр», «Димчеләр», «Тарихи хәтер» клублары эшчәнлек алып бара. «Каюм Насыйри», «Шиһабетдин Мәрҗани», «Ялчыгол», «Ризаэтдин Фәхретдин» укулары аерым игътибарга лаек. Хатын-кызлар оешмасы каршында галимәләр һәм татар халык ашлары координацион советы төзелде. 2019 елның апрелендә, 102 елдан соң II Бөтендөнья татар хатын-кызлары съездын үткәрү дә олуг мәртәбә, минемчә. Бу чара – татар хатын-кызларының активлыгын, тарихи җепләрне торгызу, бүгенге көнгә кайтаруны күрсәтүче бер дәлил. Азнакайда – «Яшәештә димчеләр һәм яучыларның тоткан урыны», Актанышта – «Татар авыллары туризмы», Яшел Үзәндә – «Идел аръягы шәхесләре эзеннән», Арчада – «Арча төбәгеннән чыккан язучылар әсәрләрендәге йола, гореф-гадәтләрнең бүгенге көндә кулланылышы», Пермь краенда – «Ирән елгасы буена урнашкан татар авыллары тарихы», Оренбургта «Оренбург өлкәсе татарларының килеп урнашу тарихы» дигән күчмә утырышлар үткәрдек. «Җырлыйк әле» җыр һәм фольклор, «Шәҗәрә – киләчәккә тәрәзә» фестивальләре һәм «Саф сулы чишмәләр» проекты, Кирмән җыены гамәлгә куелды. Күптән түгел Сабада «Саф сулы ямьле Саба» проектында катнаштык. Авыл җаны белән яшибез шулай. Кая гына барсак та, сокланып кайтабыз. Татар хатын-кызларының күзләре янып тора! Эшлибез, булдырабыз дип торалар. Йола, гореф-гадәтләребезне, милли киемебезне сакларга тырышалар. Йола сакланса, милләт саклана, халык саклана.

Болар барысы да – «Ак калфак»лар күңелендә йөргән, алар күрергә теләгән, алар омтылган һәм ирешкән максатлар, уй-теләкләр, йөзләгән-меңләгән эшләр, мәшәкатьләр. «Ак калфак»ның үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Килер буыннар аны тагын да яңартып, баетып дәвам итсен, рухи кыйммәтләребезне яңа югарылыкка күтәрсен иде. Ак юллар телик «Ак калфак»ка!



■ 2014 ел. II Бөтендөнья татар хатын-кызлары форумы.



■ 2022 ел. Казанда узган «Татар кызчыгы, татар малае» бәйгесендә катнашучылар чәкчәк пешерә. Һәр елны дөнья буенча бу бәйгедә 27 меңнән артык бала катнаша.



■ 2019 ел. Халыкара «Татар кызы» бәйгесе. 15 ерак һәм якын чит илләрдән, Россия регионнарыннан кызларыбыз катнашты.

PRESSA



ДИҢГЕЗ КҮЗЛЕ УТ РӘЗИНӘ

«Рәзинә, син кем кызы? Син бит Рәис кызы! Сабыр, тыныч бул! Син барысын да булдырасың!» Бик авыр чакларында остазының шул сүзләрен исенә төшерә ул. Һәм янып бетеп, аннары көлдән яңадан ярала торган Феникс кошы кебек, яңа көч, яңа үҗәтлек белән кабат эшенә тотына. «Булдыра алырмынмы?» дип кенә тотынган эшендә – Буа картлар һәм инвалидлар интернат-йортында шулай яна-ярала эшләвенә дә алты ел булган инде Рәзинә ХИСАМЕТДИНОВАның.



Фәнзилә
МОСТАФИНА

Аның турында: «Усал түгел, таләпчән. Эшләгән кешене ярата, үзе дә күп эшли», – диләр.



Директорның эш бүлмәсе беренче катта. Ләкин интернатның биш катын бер итеп йөргән, әби-бабайларның бүлмәләренә кереп сөйләшеп утырган, ашыгыч чакырту буенча Казанга чыгып киткән көннәре еш була аның. «Кабинетта гына утырсаң, безнең эш бармый», – ди Рәзинә үзе дә, безне урамга ук чыгып каршы алып. Шул арада телефоннан кемгәдер эш кушарга, ярдәмчесе алып килгән документны имзаларга, Казанга машина җибәртергә дә өлгерә. Җәйнең иң матур вакыты. Әби-бабайлар урамга чыкканнар, интернатның яшеллеккә, гөлчәчәкләргә күмелгән ишегалдында кояшка иркәләнеп утыралар. Алар яныннан үткәндә, үзләренчә, Буа мишәрләречә: «Нәстә халь, Әминә апа?» – дип сорарга да өлгерә Рәзинә. «Танийсыңмы мине?» – дип тә өстәп куя. Танымаучылар да бар – картлык деменциясе. Ә директор үз интернатындагы 120 кешене дә таный, 120 сенең дә язмышын, бирегә килеп эләгү тарихын, холкын белә. Шуларга өстәп, кул астында эшләүче 75 хезмәткәрне дә белергә, һәрберсе белән уртак тел табарга кирәк әле.

«Ай-яй, безнең директор чибәр дә соң!» – дип елмаеп каршыга бер әби атлый. Надежда Николаевнаны Казаннан китергәннәр. Башта беркавым сайланган: Арча, Тәтештә булган, Буадан Тукай районы интернатына киткән. Хәзер менә яңадан үзе теләп Буага әйләнеп кайткан. «Монда яхшы», – ди икән. Узып барышлый: «Шушындый директор булганга кайттым», – дип куя.

Рәзинә үзе турында «бәбиләрдән әбиләргә күчтем», дип әйтергә ярата. Белгечлеге буенча педагог, кияүгә чыгып, бер-бер артлы ике ир бала – Ислам белән Ризванны тапканнан соң балалар бакчасына эшкә чыгарга карар бирә. Бераздан аны район мәгариф идарәсенә мәктәпкәчә учреждениеләр белән эшләүче методист итеп куялар. Тизлек җыеп, райондагы 42 бакча белән гөрләтеп эшли генә башлый, яшь белгечне район җитәкчелегенә чакыртып, яңа эш тәкъдим итәләр – картлар йортына директор. «Үзем Буа районыныкы булып, картлар йортына таба карап киткән кеше дә түгел идем», – дип искә ала Рәзинә. Эчтән ут янса да, ире Илдар, остазлары: «Син булдырасың аны», – дип торгач, тәкъдимне кабул итә. Ә алындымы, эшне ярты юлда ташламый инде ул – андый гадәте юк, ахырга кадәр һәм җиренә җиткереп эшли. Казанга Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әңгәмәгә барып кайткач, 30 яшь бусагасын яңарак кына атлап чыккан Рәзинәне 30 декабрьдә директор кабинетына кертеп тә утырталар.

«Ул Яңа ел минем исемдә дә калмаган. Шуннан соң алдыма максат куйдым да эшкә тотындым. Шушы вакыт эчендә бик зур үзгәрешләр булды. Алты ел узды, һаман бетми, һаман нindидер эш килеп чыгып тора әле», – дип елмая Рәзинә. Үзе дә яңарак кына Буа районы башлыгы итеп билгеләнгән Марат Азат улы Җаббаров 2018 елда интернатка юллар салдыруда, юыну комплексына капиталь ремонт ясатуда бик булыша. Бүген районның хәзерге башлыгы Ранис Рафис улы Камәртдинов белән тыгыз элемтәдә эшлиләр. Бюджеттан бүленгән акча бөтен нәрсәгә дә җитми, директорның үзенә хәйриячеләр эзләп табарга туры килә. Ярдәмгә килергә әзер торучы «Буа якташлыгы» җәмгыяте җитәкчесе Ирек Мөнир улы Закировны, Дәүләт Советы депутаты Ринат Рәүф улы Гайзатуллинны (ул Буа интернатының попечительләр советы рәисе дә) рәхмәт сүзләре белән телгә алды Рәзинә Хисаметдинова.

Беренче елларда авыр була, әлбәттә. Хуҗалыкта башлаган ремонт эшләрен дә төгәлләргә, көндәлек оештыру, финанс мәсьәләләрен дә хәл итәргә, бердәм коллектив та тупларга кирәк. Эшнең эмоциональ ягын да оны-

PRESSA

Әби-бабайларга күз яшен күрсәтергә ярамый. Елыйсы килсә, урамда елап бетерәбез, алар янына елмаеп керәбез.

тырга ярамый. «Мондагы әби-бабайларны күргәч, күзгә яшьләр килә иде. Хәзер дә шул ук әби-бабайлар, хәзер дә шул ук мохит, ләкин без үзебезне башкача тотарга өйрәндек. Аларга күз яшен күрсәтергә ярамый. Шуңа күрә елыйсы килсә, урамда елап бетерәбез, алар янына елмаеп керәбез», – ди Рәзинә.

Яралы язмышларга бүген дә битараф кала алмый ул (картлар йортында берәрсе вафат булса – көенеп, берәрсен туганнары үзебез карыйбыз дип алып китсә яки интернатта яңа пар туса, сөенеп иренә сөйләвеннән дә күп нәрсә аңларга була). Ләкин, үзе әйтмешли, урамда елап керергә өйрәнгән. Эшендә файдалы булырдай алымнар да кертеп җибәргән:

– Бүген менә Зәйтүнә апаның хәлен сорадым, мин аны исемдә калдырам. Үзем белеп торгач, җыелышта шәфкать туташы яки психологтан «ничек эшлисез?» дип, хисап сораганда да җиңелрәк. Әле кичә генә бер яңа бабайны китерделәр. Кызлардан характеристикасын сорыйм. Авыррак холыклы, диләр. Хәер, ике сәгать эчендә генә, бераз сөйләшеп тә утырмыйча кеше турында нәтиҗә чыгарып булмый бит. Йөрәгем түзмәде, кич белән – җиденче киткәч, күрмичә китмим әле, дип, янына мендем. Утырып сөйләштек. Бабай өйдә генә ябылып яткан, аның белән чынлап та эшләргә кирәк. Сөйләшәсе килә аның. Шуны белгәндә генә аларның һәрберсенә индивидуаль якын килә алабыз.

Бер йодрык булып эшли торган коллектив та туплаган директор. Шунысы күзгә ташланды: яшь белгечләр шактый. Коллективның 40 процентка якыны яшьләр икән. Әле 157 волонтер булышып торуын да әйтергә кирәк! Элекке замандагы картлар йортлары юк инде хәзер. Бүген алар да мәгълүмати технологияләрне актив куллана, социаль челтәрләрдә үз сәхифәләрен алып бара. Тел очына сорау килә: заманча технологияләр белән эшли белә торганнардыр да яшьләр, ә олы яшьтәге һәм мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр белән эшли беләләрме соң? «Кешенең эшли аламы, юкмы икәне беренче ике атнада күренә. Эшли алмыйча, бер атнадан китеп баручылар да бар. Заманында мәгариф системасында бергә эшләгән коллегамның эштән киткәнен белгәч, аны үзебезгә чакырдым. «Миннән булмас ул», – ди. «Була!» – дидем. Мин аның ничек эшләвен беләм бит. Ул балаларны ярата. Ә безнең эштә иң мөһиме – кешеләрне ярату. Чынлап та, бер атна эшләгәч үк миңа рәхмәтләр укый башлады, хәзер әйбәт кенә эшләп йөри. Ә бер белгеч ике тапкыр килеп карады, эшләргә теләге дә бар, коллективны да яратты, ләкин булмый инде менә, аныкы түгел», – ди Рәзинә.

Ул әби-бабайларның хәлләрен сорашкан арада, хезмәткәрләреннән: «Директорыгыз усалмы?» – дип сорашам. Кемнән сорасам да: «Усал түгел, таләпчән. Эшләгән кешене ярата, үзе дә күп эшли», – диделәр.

Социаль челтәрләр дигәннән... Министрлык төзегән рейтингта Буа картлар йорты республикадагы 26 интернат арасында беренче урында бара. Эшләгән эшне күрә торган һәм гадел итеп бәяли белгән Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Әмир кызы Зариповага рәхмәтле Рәзинә. Ә аларга әби-бабайларның көн дәвамында нәрсә белән шөгыльләнүен социаль челтәрләрдән күзәтеп барган туганнары рәхмәт әйтәләр икән. Әле бер бабайны шулай ерак туганы эзләп тапкан! Туганының картлар йортында булганын белмәгән дә, әллә ничә ел күрешмәгән булганнар, интернетта фотосына тап булгач, шалтыратып белешкән. Хәзер хәлен белергә килеп йөри ди. Ялгыз түгеллеген белгәч, бабайга да рәхәт.







Иртәнге сигездә башлана, кичке биштә өйгә кайтып киткәч бетә торган эш түгел картлар йорты директоры булу. Хәер, башка берәү булса, шулай җайлар да иде, бәлки. Тик Рәзинә бит ул (монысы да остазы – филология фәннәре кандидаты Әлфия Мотыйгуллинаның сүзе)! «Бездә шимбә, якшәмбеләр дә эштән шалтыратулардан башлана. Отпускта да дөньясын онытып ял иткәне юк. Син үз өстеңә бик күп аласың, эшне башкаларга да бүлеп бирергә кирәк, дип әйтеп карыйм. Тик бу сүзләр генә. Рәзинә алай булдыра алмый ул. Аңа барысын да үзенә контрольдә тотарга кирәк, шулай эшләсә генә күңеле тыныч була», – ди Рәзинәнең ире – үзе дә районда элемтә хезмәте җитәкчесе булып эшләүче Илдар.

«Мин Рәзинәгә хәйран калам, – дип дәвам итә ул сүзен, диңгез күзле хатынына яратып карап. – Эш белән гаиләне тигез итеп алып бара. Кайчан кайтсаң да, ашарга пешкән, өй җыештырылган була. Балаларны да карый. Ике малай бит әле». Исламга – 13, Ризванга – 11 яшь. Олысы – артист, кечкенәсе – спортчы. Бәлки киләчәктә кызыксынулары үзгәрер дә. Ата белән ана анысына әзер. Иң мөһиме – мәрхәмәтле, кешелекле, намуслы булып үссеннәр. «Кайвакыт Илдар белән, ничек кенә дөрес итеп тәрбияләргә икән, дип уйлашкан да бар. Махсус китаплар укып утырырга вакыт юк. Шулай үзеннән-үзе бара инде ул тәрбия. Үз әти-әниебездән күргәнне хәзер балаларга бирәбез. Мине әтинең әнисенә – Шакирә әбиемә охшаган, диләр. Килгән кешене торып басып ишек төбендә каршы алыгыз, кунак килүдән курыкмагыз, туганнарны яратыгыз, дип үстерде ул безне. 30 яшькә хәтле уйланмаган, ә хәзер әлеге сүзләр минем өчен – кагыйдә. Ишек кыңгыравына бассалар, Илдар белән икәү тизрәк ачарга чабабыз. Балалар чыбык очы туганнарга хәтле белә. Кечкенәсе үз яшендәге туганнарны туплап, ватсапта аралашу төркеме ясаган иде. Шаккаттык. Туган җанлы булып үсә икән, дип сөендек», – ди Рәзинә. Сүз яңадан картлар йортына барып ялгана. Балалар әнисенең кайда эшләгәнен белә. Аларның белүен, аңлавын тели дә инде ата белән ана. Картлыгың тыныч һәм рәхәт булсын дисәң, балаларга вакытында тәрбия бирергә кирәк – бу алты елның биргән сабагы шундый.

Үзе дә әти-әни, абый, энем, туганнар дип үлеп тора Рәзинә. «Күңеле төшенкерәк икәнен күрсәм, бар, авылыңа кайтып бушанып кил, дип әйтәм», – ди Илдар. Туган авылы Кырык Садак турында әйткәч, Рәзинәнең күзләре очкынлана: «Авылны бик яратам. Район үзәгеннән машинада 25 минутлык юл. Атнага бер тапкыр кайтып килмәсәм, мин инде мин түгел. Бер көн булса да ял ит инде, ди әниләр. Ә минем өчен ял – төп йортка кайту. Әти-әни янында йөрәккә тыныч». Физик һәм бигрәк тә рухи яктан арыгач, тагын ничек ял итә директор?

– Бер тәүлеккә булса да һава алыштырырга кирәк. Хәзер Татарстанда да матур җирләр күп. Шимбә-якшәмбе буш булса, йә Изге Болгарга, йә Зөягә чыгып китәбез. Илдар белән икебез дә театр-концертлар яратабыз. Кайвакыт эштә утырганда кәефем төшеп китә дә Казанга шалтыратам: фәлән концертка билетлар бармы? Бар дисәләр, тиз генә җыенып чыгып китәбез. Була шундый вакыт: кешеләрдән арыйсың. Андый вакытта берүзем өйдә калып, рәхәтләнеп җыештырам. Машинама утырып болынга чыгып китәм, кыр чәчәкләре җыеп кайтам.

Башкарылган эшләр күп, башкарасылары тагын да күбрәк. Бу урында булмаса, башкасында – Рәзинә тормышының хыялланыр, максатлар куяр чорында. Өйрәнәселәре дә күп. «Юк» дип әйтергә өйрәнергә кирәк әле миңа, – ди үзе. – Нинди дә булса проблема белән киләләр. Бөтен көнем, бөтен энергиям шуңа киткәнен дә аңлыйм. «Юк» дип әйтә белсәм...» Җөмләсен тәмамламый. «Юктыр, миннән алай булмастыр...» «Кешене яратыгыз», дип үстергән Шакирә әби, ике улын һәм кызын, кеше белән яшәргә кирәк, дип тәрбияләгән, 70 не узса да, үзе дә сораган бер кешегә ярдәмгә килергә әзер булган әти кызы бит ул Рәзинә.

Фото: Анна Арахамия







ТАТАР САМУРАЕ

Бизнес дигәч, кешеләр коммерция, акча сугу, төрле хәйләле схемаларны күз алдына китерә. Шуңа күрә дә үземне бизнесмен дип атамыйм, эшмәкәр мин. Дөньяга үзгәреш кертә торган кеше. **ЯГЪНИ НИНДИДЕР ПРОБЛЕМАНЫ КҮРӘСЕҢ, БУ ДӨНЬЯГА НӘРСӘДЕР ҖИТЕП БЕТМӘГӘНЕН АҢЛЫЙСЫҢ ҺӘМ ШУНЫ ХӘЛ ИТӘРГӘ АЛЫНАСЫҢ.**

Без көнбатыш культурасына мөкиббән. Киноларын карыйбыз, китапларын укыйбыз, аларча киенәбез, гомумән, аларча яшәргә тырышабыз. Шул рәвешле үз динебезне, тарихыбызны, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен онытып, яшәешебезнең асылын бозабыз. Максат куясың да, бернәрсәгә карамыйча үтәргә тырышасың. Бу да Америка системасы буенча эш итү. Безнең дингә, культурага якын булган көнчыгыш системасы бар. Ул рухи халәткә өстенлек бирә. Анда нәрсә диелә: максатка барган юл ул – үзе бәхет. **ҮЗЕБЕЗГӘ БИРЕЛГӘН ВӘКАЛӘТКӘ ИЛТКӘН ЮЛЫҢНЫ АҢЛАП, ЯРАТЫП, ҺӘР КӨНГӘ ХИСАП ТОТЫП, ҮЗЕҢНЕҢ ТРАДИЦИЯЛӘРЕҢНЕ БОЗМЫЙЧА БАРУ – БӘХЕТ!** Әмма аңа барып җитәсеңме, юкмы билгеле түгел. Ул хакта бер Аллаһы Тәгалә генә белә.

Мин дә башта көнбатыш системасы буенча яшәдем: укыдым, чит илгә киттем, анда укыдым, эшләдем, Татарстанга кайттым, «Түбәтәй» ачтык. Кайдадыр күңел тартканга эшләдем, кайдадыр максат куйдым һәм шуңа ирештем. **Ә ХӘЗЕР БЕЛӘМ: БЕЗНЕҢ БӨТЕН БАЙЛЫГЫБЫЗ – БҮГЕНГЕ КӨН.** Һәр көнгә мәгънә, игътибар биреп яшәсәк, иң зур максатларыбызга ирешербез дип уйлыйм.

«100 ПРОЦЕНТКА ЯШӘ» СИСТЕМАСЫ БУЕНЧА ЯШИМ. Үн тормыш кыйммәтеннән торган ул системаны үзем уйлап чыгардым. Ел саен бер мәртәбә тормышымны анализлыйм: 100 процентлы куәт белән яшимме, юкмы. Кайсы өлкәдә ныграк эшләргә кирәк, кайда бар да яхшы. Әлегә тулысынча 100 процент булганы юк. Тормышыма бәя бирәм һәм шуннан чыгып киләчәккә план корам.

Барыбызның да бер проблема – кеше фикеренә бик нык колак салабыз. Шуңа да буталып беттек бугай: кайда безнең ихтыяҗ, кайда кешеләрнең безгә карата ихтыяҗы? **Ә ТОРМЫШ КЫЙММӘТЛӘРЕ БАРЫ ТИК ҮЗЕҢ ӨЧЕН ГЕНӘ МӨҺИМ БУЛЫРГА ТИЕШ. КЕШЕ ӨЧЕН ТҮГЕЛ.**

ЕЛМАЮ ДА СӘДАКА. Кешегә елмайдыңмы, ул инде әҗер-савап булып бара. Чөнки ул – ихласлык. Миллионлап акча бирүең ихлас булмаска мөмкин, ә елмаюның кыйммәте күбрәк тә булырга ихтимал.

НИНДИДЕР ПРОЕКТ БАШЛЫЙСЫҢ ИКӘН, НӘРСӘ ГЕНӘ БУЛСА ДА, ҮЗ ИДЕЯЛӘРЕҢӘ ЫШАНЫЧ БЕТӘРГӘ ТИЕШ ТҮГЕЛ. Әгәр ышаныч бетә икән, синең белән бергә эшләгән кешеләрне ничек рухландырмак кирәк?!

ТОРМЫШТА ҮЗЕҢ ЯРАТКАН ҺӘМ БИК ЯХШЫ КИЛЕП ЧЫККАН ӘЙБЕРЛӘР БЕЛӘН ГЕНӘ ШӨГЫЛЬЛӘНЕРГӘ КИРӘК. Әлбәттә, бөтен кеше дә креатив була алмый, ә кемдер бик шәп итеп нидер эшли белә. Шуңа күрә идеяләрне тормышка ашырып, сокландыргыч эшләр башкарыр өчен кешеләргә берләшү зарур.

БЕЗНЕҢ БЕЛӘН НИ ГЕНӘ БУЛСА ДА, БАР ДА ЯХШЫГА ГЫНА, АНЫ АҢЛАП БЕТЕРӘ ГЕНӘ АЛМЫЙБЫЗ.

БЕЗНЕҢ КОМПАНИЯНЕҢ ТӨП ПРИНЦИБЫ – ХӘЛӘЛЛЕК. Бу ризыкка гына кагылмый. Бар яктан хәләл булу – мөнәсәбәтләрдә, кылган гамәлләрдә, сайлауда, карарларда. Тормышта да шулай: алдарга һәм урларга ярамый.

КУЛЫҢНАН КИЛГӘННЕҢ БАРЫСЫН ДА ЭШЛӘРГӘ ҺӘМ КАЛГАНЫНДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ЫШАНЫРГА. Башка эшмәкәрләр кебек үк, барысын да контрольдә тотарга теләү омтылышым бар. Әмма бу мөмкин түгел.

Без кинода уйныйбыз. Шушы кинода булган эпизодлар Аллаһы Тәгаләдән бирелә. Безнең рольләр бар: бала, ир, ата... **ДӨНЬЯНЫ АРТЫК КУМЫЙЧА ГЫНА, ЯКЫННАРЫБЫЗНЫҢ ХАКЫН ХАКЛАП ЯШӘРГӘ ТЫРЫШСАК, РУХИ ИРЕК ШУЛ ИНДЕ УЛ.**

КОНКУРЕНТЛАР КҮБӘЙГӘН САЕН, ШАТЛАНАМ ГЫНА. Без милли ризыкны заманча итеп күрсәтергә теләдек. Аннан соң башка проектлар булдырдык. Охшаш проектлар башка республикада да гамәлгә ашырыла башлады. Без шат кына! Изге эшкә юл күрсәтүнең дә әҗер-савабы бар. Димәк, син изге эш башкарасың.

«Түбәтәй» заманча хәләл туклану челтәренә нигез салучы эшмәкәр Солтан САФИНның тормыш кагыйдәләре



Фото: Анна Арахамия

PRESSA

ТАТАР МИЛЛИ АШЛАРЫНА МӘХӘББӘТНЕ ӘБИЛӘРЕМ ТӘРБИЯЛӘДЕ. Алар да эшмәкәр булган. Әни ягыннан Фәния әби гомере буе аш-су остасы булып эшләде. Пешекче булып, гап-гади пироглар пешереп басып торырга да, төрле бәйгеләрдә катнашырга да була. Әбинең эшмәкәрлек сыйфатлары булган инде. Ул Мәскәүгә ВДНХдагы ярминкәләргә кадәр тортлар пешереп алып барган. Әти ягыннан Сания әби рус теле укытучысы иде. Ул гомер буе кечкенә кибет тотты. Әби – миңа иң беренче телефон алып бирүче дә.

Әти ягыннан бабай – физика фәне буенча профессор. Тальян гармун остасы булган. Бабайның бер тальян гармуны миндә саклана. **ХӘЗЕР МИНӘ ТАЛЬЯН ГАРМУНДА УЙНАРГА ӨЙРӘНӘСЕМ КИЛӘ.**

«СИН БИТ САФИН!» ӘТИ МИҢА ГЕЛ ШУЛАЙ ӘЙТӘ. КӨЧ БИРӘ ТОРГАН СҮЗ БУ. ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛЛЕГЕҢНЕ АҢЛЫЙСЫҢ. Синең артыңда – династия. Аларның кодларын үзеңә алгансың. Бу бит җаваплылык та. Һәм ул кодларны киләчәккә син тапшырасың. Улыма: «Син – чемпион», – дим. Әле аңа 2 яшь кенә. Үсә төшкәч, «Син бит Сафин»ны да ишетер.

Әнигә догалары өчен рәхмәтлемен. Йоклар алдыннан дога укырга өйрәтте. **НИ ГЕНӘ БУЛСА ДА, ДОГА УКЫМЫЙЧА ЙОКЛАРГА ЯТМАДЫК БЕЗ.** Укыгач, тынычланып китә идек.

Бу эшне акча эшләү максаты белән башкармыйбыз. Андый максат булса, башлап та тормаган булыр идек. Ышаныгыз. Чөнки партнерларым Руслан Гыйльметдинов белән Согуд Гарәбстанында нефть тармагында эшләдек, Айнур Камалиев дәрәҗәле фитнес-инструктор иде. Без бу эшне Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешү, әз генә булса да дөньяны яхшырту өчен башладык. **НИНДИ НИЯТ БЕЛӘН БАШЛЫЙСЫҢ, ШУҢА ИРЕШӘСЕҢ БИТ УЛ...**

Геология факультетын тәмамламасам, Согуд Гарәбстанында булмасам, анда француз дусларым-коллегаларым минем презентациягә ышанмаса, «Түбәтәй» проекты беркайчан да барып чыкмас иде. **ТОРМЫШ ТУРЫ БЕР СЫЗЫКТАН ГЫНА БАРМЫЙ УЛ.**

Мин – Самара өлкәсе Камышлы авылында туып-үскән малай, 9 нчы класста укыганда Болгар җирлегендә дингә килдем. Шунда, дин әһелләрен тыңлагач, дөрес яшәмәгәнемне аңладым. **АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ЫШАНЫП ЯШӘҮ ЗУР ПЛЮС УЛ.**

Самарада туып-үскән татар егете буларак, Казанга татар мохитенә керәм дип килдем, әмма ул вакытта, кызганыч, минем төркемдә хәтта районнардан килгән студентлар татарча сөйләшми иде. Шаккаттым. Хәләл ризык эзләргә тотындым. Ә ул беркайда да юк. Тимер юл вокзалы янында целлофан пакетка салып өчпочмак һәм пластик стаканда чәй бирделәр. Ул өчпочмакның кыяфәте дә юк иде. **ТАТАРЛАР БАШКАЛАСЫНДА НИГӘ ХӘЛӘЛ РИЗЫК ЮК, НИГӘ ТАТАРЧА ЮНЬЛӘП СӨЙЛӘШМИБЕЗ? МЕНӘ ШУШЫ СОРАУЛАРГА ҖАВАП ТАБУДАН БАШЛАНДЫ ЭШМӘКӘРЛЕККӘ ЮЛЫМ.**

Традицияләрне сызып аттык. Имеш, моветон, авылча. Яңаны кабул иттек. Яңаның кыйммәте юк, материаль ягы гына бар. Шуңа бераз буталып беттек. Кыйбланы югалтырга да мөмкин бит. «Үткәнне онытканның киләчәге юк», – диләр. Хак бу сүзләр. **ҮТКӘННӘРНЕ КАБУЛ ИТӘ БЕЛЕРГӘ ҺӘМ САКЛАРГА, ЗАМАНЧА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ЯРДӘМЕНДӘ КЫЙММӘТЛӘРНЕ КИРЕДӘН АЧАРГА ӨЙРӘНЕРГӘ КИРӘК ӘЛЕ.**

Без үсәчәкбез. Компания үсәчәк. Ә максат шул ук калачак: татарларның мәдәниятен, гореф-гадәтләрен бар дөньяга күрсәтергә тиешбез. Һәр көнне. **ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ ОНЫТМЫЙЧА, БҮГЕН БЕЛӘН ЯШӘРГӘ КИРӘК. ИРТӘГӘ УЯНАБЫЗМЫ-ЮКМЫ – БЕЛМИБЕЗ БИТ.** Безгә аны беркем вәгъдә итми.

КИЧӘГЕ КӨН – НӘТИҖӘ ЯСАР ӨЧЕН, БҮГЕНГЕ КӨН – ЯШӘР ӨЧЕН, ИРТӘГӘГЕ КӨН – ХЫЯЛЛАНЫР ӨЧЕН.

Гаилә коргач, бер-беребезгә таләпләр куярга өйрәнгәнбез. Ул таләпләр үтәлсә, үзебезне бәхетлегә санап яшибез. Бу дөрес түгел икән бит. Бар бер кеше, бар икенче кеше. Хатын – үз бәхетен, ир үзенекен төзи, ягъни тормыш киносын төшерә. Әйе, син хатыныңның киносында роль уйныйсың, әмма ул синең кино түгел. Синең үзеңнең киноң. Балалар тугач, аларның үз тормыш сценарийлары. **БЕЗНЕҢ БУРЫЧ: БЕР-БЕРЕБЕЗНЕҢ КИНОСЫН КАМИЛ ИТЕП ТӨШЕРЕРГӘ ЯРДӘМ ИТҮ. АЛЛАҺЫ БИРГӘН КӨЧНЕ, ТАЛАНТЛАРНЫ АЧЫП, БӨТЕН НӘРСӘНЕҢ ХАКЫН ХАКЛАП ЯШӘҮ.** Әйе, бу фикерне кабул итү бик авыр. Ләкин кабул итәсең икән, гаилә тормышы күпкә җайлана һәм мөнәсәбәтләр икенче бер яссылыкка чыга.

КҮҢЕЛ БИРЕП ЯШӘ, ӨЙДӘГЕ КЕБЕК ТӘМЛЕ ИТЕП АШАТ, ТАТАР ТАМЫРЛАРЫҢНЫ ОНЫТМА, ЯХШЫЛАП УЙЛА, ТИЗ ЭШЛӘ, КОМАНДА КЕШЕСЕ БУЛ.

МОХИТ – ҮСЕШ ӨЧЕН БЕР ЭЛЕМЕНТ. Бу һәр көн синең белән аралашкан кешеләр генә түгел. Укыган, ишеткән, күргән теләсә нинди мәгълүмат – безнең мохит ул. Хатының белән иреңнән башлап, укыган китабың да, күзәтеп барган социаль челтәрләр дә – әлеге мохитне тудыручылар. Шуңа күрә бер яктан – ачык, икенче яктан – аралашу даирәсендә талымлы кеше мин.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.



Белгеч фикере

НАЧАР ҺӘМ ЯХШЫ КРЕДИТЛАР

Лэйсэн ХАЛИКОВА, финанс белгече

Кредит тормышыбызга ныклап үтеп керде. Шул ук вакытта аны начар һәм яхшыга бүлеп карарга кирәген белеп бетермәүчеләр дә бар.

Әгәр алган кредитыбыз нинди дә булса керем китерә икән, аны яхшы кредит дип карарга мөмкин. Ә юк-бар сатып алулар, күңел ачулар өчен алынган бурыч, киресенчә, начар дип атала.

Бер үк кредитны яхшы яктан да, начар яктан да карарга була. Әйтик, кредитка автомобиль алабыз, ди. Әгәр машинаны модада булганга яки кешегә күрсәтү өчен генә алабыз икән, андый кредитны начар дип карыйбыз. Ә инде яшәү урыныннан еракта әйбәт хезмәт хаклы эш тәкъдим итсәләр, бу очракта кредитка машина алсак, ул безгә керем китерергә ярдәм итә булып чыга. Шул автомобиль белән таксига эшкә урнашырга мөмкин, андый очракта да кредитны яхшы дип карый алабыз.

Фатир алуны да ике яклап карарга була. Бер яктан караганда, кредитка фатир алабыз икән, ул безгә ниндидер актив китерергә тиеш. Аны арендага биреп торырга уйласак, аннан кергән торган керем чыгымнарыбызны, амортизацияне (әйберләрнең тора-бара тузуын исәпкә алып санала торган бәя), инфляцияне капларлык булырга тиеш. Әгәр фатирны «ун елдан баламның шәһәргә укырга керәсе бар», дип кенә алып куясың, кулланмыйсың да, арендага да бирмисең икән, аның үзкыйммәте һаман төшеп барачак. Моны инде яхшы кредит дип карап булмый. Өченче очракны да әйтеп китик. Яшь гаиләнең яшәр урыны юк, ди. Фатирны арендага алып торуга күп акча кирәк. Ә инде ипотека алсаң, процентлар түлисе. Берәү, мин банкка 20 ел ипотека түләгәнче, иң яхшысы арендага алып торам, дияргә мөмкин. Ә кайберәүләр, кешегә аренда түләгәнче, үз өем өчен түләп барам, ди. Шулай дип уйлап, ипотекага фатир алсаң, ул турыдан-туры ниндидер керем китермәсә дә, яхшы кредит булып саналырга мөмкин. Мондый очракта ничек кулайрак буласын һәр кеше үзе хәл итә.

Ял итәргә бару өчен кредит алучылар күбәйде. Ял итеп кайттык, барысы да шәп, кәефләр күтәренке, ләкин кредитны түләргә кирәк бит. Отпускка барып кайтудан баерак булдыкмы, юкмы? Әлбәттә, рухи яктан баегансыз, күңелебез тынычланган, эшләргә дәрт кузгалгандыр. Ләкин анда барып кайтканнан матди яктан баемадык. Шуңа күрә мин моны начар кредитка кертәм. Икенче яктан караганда, ялдан ниндидер идеяләр алып кайтып, аларны шундук тормышка ашырып, акча эшли башласак, моны, әлбәттә, яхшы кредитка борып куярга мөмкин.

Шулай ук туй уздырырга кредит алалар. Аңлашыла инде, матур итеп оештырасы килә. Ләкин туй үткәреп әле берәү дә баемаган. Бүләккә килгән акча чыгымнарның бер өлешен генә капларга мөмкин. Бу очракта кредитлар алып зурлап туй үткәргәнче, аягыңны юрганыңа карап сузу хәерлерәк.

Сәламәтлек, әлбәттә, иң беренче урында торырга тиеш. Әгәр мөмкинлегебез бөтенләй юк икән, сәламәтлекне яхшырту өчен кредит алуны яхшы бурыч дип карарга була. Яки тышкы кыяфәттә күзгә бәрелеп торган кимчелек булып, ул эшләргә, ягъни керем алырга комачаулый икән, аны төзәтү өчен кредиттан файдаланырга була, билгеле. Ләкин мавыгып китмәскә кирәк. Хәзер күпчелек салоннар бушлай процедурага чакырып, кимчелекләрне тәртеп күрсәтеп, сезнең өчен уңай шартлы кредит, дип, бурычка ниндидер процедура алдыртырга ярата. Бу очракта да игътибарлы булырга кирәк. Сәламәтлек, тышкы кыяфәт белән бәйле очракларда ниндидер кредит алу яхшылап уйланган үз фикеребезме, әллә тыштан көчләп тагылган фикер генәме?

Зур процентлы кредитыбыз булып, башка банкта түбәнрәк ставка буенча акча алып, рефинанслау ясасак, ягъни беренче кредитны икенчесе белән капласак һәм анысының проценты кимрәк булса, моны да яхшы кредит дип карыйбыз.

Ә менә инвестициягә кертү өчен кредит алырга ярамый. Иң элек безнең «финанс мендәре»без, аннан тыш та күпмедер өстәмә акчабыз, иминиятләштерүебез булырга, башка бурычларыбыз калмаска тиеш – шуннан соң гына инвестиция турында уйланырга ярый. Икешәр-өчәр миллион сум кредит алып, аны берничә айда ике тапкырга күбрәк итеп кайтарырга ниятләүчеләр күп булды. Хәзерге көндә аларның кайберләре банкрот, кайберләре депрессиядә, ә кайберләре гомерләре белән үк хушлашты.

Финанс белгече буларак, гомумән, кредитлар белән бәйләнешкә керергә киңәш итмим. Алырга туры килгән очракта да, башта үзебез өчен билгеләргә кирәк: ул кредит яхшы, ягъни өстәмә актив китерә торганмы, әллә вакытлыча нәфес котыртуы гынамы.

Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде.



Лилия
ГӘРӘЕВА

Бу язма өмет турында. Язмыш каршысына басып: «Мин сине алышка чакырам!» – дип әйтергә үзләрендә көч табучылар турында.
Дөньяга килгәндә үк безгә эчәр су, сулар һава һәм сәламәтлек бүләк итеп бирелгән. Ә без аларны бүләккә санамыйбыз да. Югыйсә боларның берсеннән башка гына да яшәү үзе дә була алмас иде. Һавасыз яши алабызмы, сусызмы? Сәламәтлегебез какшаса, тормышыбызның нуры бөтенләй үк сүнә. Аны кире кайтарыр өчен әллә ниләр бирердәй булабыз. Ә балаң – йөрәк парәң авырса? Кашык тотып үзе ашый алмаса, беркайчан да аякларына басмаса, «әнием» димәсә? Әти-әни өчен моннан да зуррак хәсрәт бармы?! Андый язмышка дучар булучылар баласының бер авазы, бер хәрәкәте, бер адымы өчен нинди хак түләгәннәрен үзләре генә беләдер.

БЕРЕНЧЕ АДЫМ



Алабуга шәһәрендәге мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен «Астра» тернәкләндерү үзәгенең тарихы 2005 елдан башлана. 25 декабрьдә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев катнашында үзәкнең әүвәлге чираты – 2 гектар мәйданны биләгән участокта төп корпус, хуҗалык биналары кулланугa тапшырыла. Ләкин бу әле шул ук көнне беренче пациентларны кабул итә башлауны белдерми. Бер төркем энтузиастлар җиң сызганып эшкә керешә. Эш күп – төзелеш чүпләрен түгәсе, әйләнә-тирәне җыештырасы, җиһазларны урнаштырасы… Ниһаять, 2006 елның 13 мартында Татарстан Министрлар Кабинетының «Алабуга шәһәрендә мөмкинлеге чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен Реабилитация үзәге ачу турында»гы 97 нче карары имзалана. Бик күпләр күңелендә өмет уты кабызган көн бу.

Үзенчәлекле балаларга мөнәсәбәтнең дә, дәвалау алымнарының да үзенчәлеклесе кирәк. Моның өчен биредә заманча коррекция-реабилитация җиһазлары, тренажерлар, дәвалау костюмнары – барысы да бар. Иппотерапия, войта-терапия, мускулларның спазмын бетерүгә юнәлтелгән нокталы массаж, Сандаков методы белән рефлектор массаж, дәвалау физкультурасы, кинезио-механотера-

пия, җылы белән, кислород, тоз, су белән дәвалау, физиотерапия – кулланылган чараларның барысы да түгел әле болар. Социаль педагоглар, хезмәт инструкторлары, музыкаль җитәкче, логопед, дефектолог, психологлар, тәрбиячеләр, кулга-кул тотынышып, үзенчәлекле балаларны социаль көнкүрешкә яраклаштыру, социаль мохиткә иярләштерү өчен бар тырышлыгын куя.

– Максатыбыз – баланы социальләштерү, үзендә булган барлык кимчелекләр белән шушы җәмгыятьтә яшәргә өйрәтү, – ди «Астра» үзәгенең директор урынбасары Юлия Алексеевна Драничникова. – Без балаларны дәваламыйбыз, без аларны үз мөмкинлекләре белән тормышка яраклашырга өйрәтәбез, ахырдан алар бу кимчелекләрне хәтта тоймый да башлый.

«Астра» үзәгендә елына якынча 650 бала реабилитация уза. Болар – Даун синдромлы, акыл үсеше, сөйләме тоткарланган балалар, аутистик спектрда кимчелеге булганнар, соматиклар, бронхиаль астма, шикәр чире белән авыручылар, коляскада гына утыручылар.

Әмирә

Әмирәгә 5 яшь. «Мине фотога төшермәгез, теләмим!» – ди. Шундый катгый итеп әйтә, 5 яшьлек сабый таләбе димәссең дә. «Юк-юк, сине түгел, инструкторны гына төшерәбез», – дип юмалау да нәтиҗәсез. Аның матур коену костюмына, суда оста итеп йөзә белүенә соклануыбыз да бәләкәй йөрәген йомшартмый.

Әмирәгә табиблар куйган диагноз – миопатия. Әнисе әйтүенчә, бу – генетик чир, организмда аксым синтезы бозылу аркасында баланың нервларында һәм мускулларында үзгәрешләр башлана, үсеше тоткарлана.

– Сәламәтлегендә ниндидер проблема барлыгын тугач ук тойдым, – ди әнисе (ул үзенең исемен күрсәтмәүне үтенде. – *Авт*.). – Хәлсез, зәгыйфь иде ул. Югыйсә йөклелек әйбәт узды. Табиблар бар да яхшы дип ышандырса да, бала тудыру йортыннан чыгу белән хастаханәгә бардым. Ләкин анда бу хәлсезлекнең сәбәбен ачыклый алмадылар. Диагнозны безгә бары дүрт айдан гына куйдылар.

Кул кушырып утырып, вакытны уздырырга ярамавын шунда ук аңладык. Үз көчебез белән баланы ничек тә тернәкләндерү эшенә керештек. 1 яшендә ул корсагына яткан килеш үрмәли башлады. Бу безнең иң беренче зур җиңүебез булды.

Беренче тапкыр «Астра» үзәгенә килгәндә Әмирәгә яшь тә бер ай иде. Тагын бер-ике айдан кызыбыз тәпи йөреп китте. Дәвалау физкультурасы инструкторы Гөлия Рафаэлевна Колбасовага, массажист Фирая Маратовна Фәсхиевага рәхмәт. Алар безне аякка бастырды, күңелдә өмет уятты.

2 яшенә кадәр Әмирә бер аваз да чыгармады. Еламый да иде хәтта, гел йоклады да йоклады. Биредәге логопедлар ярдәме белән хәзер әнә ничек оста итеп сөйләшәбез. Йөрүебез дә ышанычлы. Баскычлардан да үзе төшеп, үзе менә, төсләрне, формаларны аера.



Галина КАЛАШНИКОВА, социология фәннәре кандидаты, Алабуга шәһәренең «Астра» мөмкинлеге чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәге» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе директоры

– Реабилитация үзәкләренең барысының да максаты – социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ кешенең яшәеш шартларын яхшырту һәм аның төп яшәеш ихтыяҗларын үзе башкара алу мөмкинлеген арттыру. «Астра» реабилитация үзәге туганнан алып 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшүсмерләргә социаль хезмәт күрсәтә. Миссиябез – балаларга һәм аларның әти-әниләренә «үз үзенчәлекләрен кабул итәргә» булышу, балаларның иҗади потенциалын ачу, булган ресурсларны тулы канлы яшәү өчен файдалану. «Без үзенчәлекле балаларга мөмкинлекләр ачабыз» – үзәкнең шигаре әнә шундый. Төп бурычыбыз: балаларны үзләрен тотарга, читләр ярдәменнән башка үзүзләрен карарга өйрәтү, сөйләмен, интеллектын һәм коммуникатив һөнәрләрен арттыру. Биредә гаҗәеп тәҗрибәле белгечләр эшли. Әмма иң авыры – реабилитацияләү процессына әти-әниләрне җәлеп итү, пассив кулланучылардан актив булышчы, фикердәшләр ясау. Белгечләр өчен бу юнәлештә акыл штурмнары һәм тренинглар уза. Шул рәвешле без балалар белән генә түгел, аларның гаиләләре белән дә эшләү өчен туры килә торган комплекслы эш алымнары булдырабыз. Үзәктә «Әти-әниләр мәктәбе» актив эшли. Монда әти-әниләрне бала белән өй шартларында шөгыльләнергә өйрәтәбез. Балалар һәм гаиләләрнең бергәләп ял итүен, күңел ачуын да оештыручылар әле без. Бу эштә партнерларыбыз ярдәм итә. Кино, театр, концертларга йөрибез, музейлар белән танышабыз. Болар хәйрия нигезендә бушка башкарыла.

Күп еллык тәҗрибәдән чыгып әйтәм, сәламәтлегендә үзенчәлеге булган балалар реабилитацияне никадәр иртәрәк узса, нәтиҗәсе дә шуның кадәр яхшырак булачак.

Узган ел безгә бер әни мөрәҗәгать итте. Тугыз айлык улында Даун синдромы. Бу ханым тәмам өметсезлеккә бирелгән. «Астра» үзәгендә ике курс реабилитация узуга, бала күз алдында үзгәрде: башын тота, үрмәли, аннары йөри башлады, теле ачылды. Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләре дә җайланды – алар үз балаларын кабул итәргә өйрәнде. Ә иң мөһиме: алар хәзер бергәләп бу авырлыкларны җиңәчәкләренә ышана һәм улларының уңышларына сөенә белә.

Профессиональ командабызның уңыш формуласы – күңел биреп эшләү, балаларны ярату, үз эшеңнең никадәр мөһим булуын аңлау. Күңелең чиста, йөрәгең миһербанлы булганда гына яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була.



Фото: Анна Арахамия



Зәлия

28 атналык кына булып туа ул. Реабилитация үзәгенә килгәндә Зәлиягә яшь тә дүрт ай була. Диагнозы – баш миенең хроник зарарлануы.

– Монда килгәндә без бары бер якка гына әйләнә ала идек, – ди Зәлиянең әнисе Зөлфия Җәлилова. – Массаж, дәвалау физкультурасы, войта-терапиянең нәтиҗәсе шунда ук сизелә башлады – кызыбыз үрмәләп китте, чәйнәп ашарга өйрәнде. Тагын бер айдан ул аякларына торып басты, аннары йөреп үк китте. Хәзер без кашык тотып үзебез ашыйбыз, чынаяктан эчәбез. Безнең өчен могҗизага тиң сөенеч бу. Шатлыгыбыз эчебезгә сыймый. Монда эшләүчеләрнең барысына да, аеруча инструкторыбыз Елена Александровна Ивановага рәхмәтебез чиксез. Без инде март аенда төзек җөмләләр белән сөйләшә башлаган идек, күзләренә операция ясаткач, Зәлиянең сөйләшүе әлегә кимеде. Наркоз йогынтысы, ди табиблар. Ләкин өметебезне өзмибез, Зәлияне аякка бастыру өчен бар тырышлыгыбызны куячакбыз.

Матвей

Карап торышка сәламәтлегендә ниндидер үзенчәлеге бар димәссең дә Матвейны. Бик игътибарлы кеше генә ике ботинкасының ике төрле икәнен күрергә мөмкин. Тумыштан бер аягы кыскарак булып туа ул. Хәзер аңа 8 яшь.

– Йөклелек яхшы узды, тудыруын гына авырдан тудырдым. Гәүдәсе зур иде. Әллә туганда берәр зәгыйфьлек килдеме, әллә башкасымы – башында гематома бар иде. Аны шунда ук суыртып алдылар, бар да җайланды кебек. Ике айдан планлы төстә невропатологка күрендек. Аяклардагы аерманы беренче булып ул ачыклады, – дип, үзләренең тарихын сөйли әнисе Елена Зуева. – Төгәл диагнозны Петербургта куйдылар. Ниндидер сәбәпләр аркасында Матвейның бер аягы начар үсә. Бот сөяге генә түгел, табан сөягенең дә үсеше калыша. Әлегә аерма 6 сантиметр тирәсе. Заказга тегелгән махсус аяк киемнәре белән без аякларны тигезлибез. Шулай да умырткалыгында сколиоз барлыкка килде. Оча сөягендә дә авышлык бар. Бирегә төп авыруыбызны дәвалар өчен түгел, ә шуның нәтиҗәләрен бетерер өчен йөрибез.

Кояш кебек якты бу малайны алда зур сынау көтә. Аяклардагы аерма җиде сантиметрга җиткәч, Илизаров аппараты белән сөяген озынайтачаклар. Өч айда берьюлы 7 сантиметрга кадәр сузарга мөмкинлек бирә бу ысул. Ә андый операция Матвейга икәү кирәк булачак әле.

Улының сәламәтлегендә тайпылышлар булса да, Елена үз эченә бикләнеп, күңел төшенкелегенә бирелмәгән. Үзлегеннән төрле техникаларны өйрәнеп, кызыклы мастер-класслар уздыра. Ул оештырган осталык дәресләренә әлеге үзәккә йөрүче әниләр дә бик теләп кушыла. Бу килүендә ул аларны балавыздан шәмнәр ясарга өйрәтмәкче. Алда ике операция торса да, Матвейның тулысынча савыгу мөмкинлеге аңа көч бирә.

Регина

– Туганда бернинди кимчелеге юк иде, – ди Регинаның әнисе Марина Минькашова. – Алты айга кадәр гадәти балалар кебек үсте. Алты айдан бер күзе кырыйгарак карый башлады. Республика балалар клиник хастаханәсендә бар да яхшы, дип, тынычландырып кайтардылар. Шулай да йөреп китүе бераз соңарды – яшь тә җиде айда гына беренче адымын атлады. Невролог күзәтүендә булгач, шулай тиештер, дип, моңа әллә ни борчылмадык та. Тик дәвалануның нәтиҗәсе күренмәгәч, Казандагы 8 нче хастаханәгә күренеп карарга булдык. Бары шунда гына безгә ДЦП диагнозы куйдылар. 2 яшьтә инде балалар җирдән иелеп уенчыкларын ала башлый, ә Регина иелгән җирдән торып китә алмый иде. «Астра»да дәвалана башлагач та иң беренче уңышыбыз шул булды – кызыбыз җирдән иелеп нәрсәнедер алды да торып китеп тә барды. Моңа хәтта үзе дә аптырады. Монда белгечләр бик яхшы. Инструкторыбыз Айдар Рәшитович Шәйгалләмов безне баскычтан йөрергә өйрәтте. Войта-терапия узгач, кызыбызның теле ачылды. Хәзер ул яхшы сөйләшә, тотрыклы йөри, үз-үзен карый ала. Беркайчан да ач калмаячак, шунысына җаным тыныч.





Үзәкнең төп бурычларының берсе – балаларны үз-үзләрен карарга өйрәтү. Моның өчен социаль көнкүреш ориентациясе кабинеты эшли. Педагог Наталья Александровна Митягина сигез-тугыз айдан ук балаларны элементар гигиена кагыйдәләренә өйрәтә. Сәламәт бала өчен бер авырлыгы да булмаган кул юу, теш чистарту, чүлмәккә утыру кебек эшләр дә – куллары буйсынмаган балалар өчен шактый катлаулы эш. Һәр әти-әни дә үзенчәлекле баланы моңа ничек итеп өйрәтәсен белми. Олыраклар үзләре киенергә, чишенергә, сәдәфләрен каптырып, шнурларын бәйләргә өйрәнә. Кул-аяклар бөгелмәгәндә бу эшләрне җайлаштырырга ярдәм итүче махсус чаралар булуын шулай ук күпләр беренче тапкыр биредә күрә.

Юынырга, киенергә генә түгел, үзләренә ризык әзерләргә дә өйрәнә үзәктә дәваланучылар. Килешәсездер, бөтен әти-әнинең дә моңа түземлеге җитмәскә мөмкин. Күргәнегезчә, реабилитация дигән бер сүз үз эченә күп төрле эшчәнлекне сыйдыра. Ул – сәламәтлекне ныгыту да, баланы социаль мохиткә яраклаштыру, үзенә бирелгән барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга, сәламәтлегендә булган барлык кимчелекләр белән яшәргә өйрәтү дә.

Татарстанда мөмкинлекләре чикле балаларны тернәкләндерү белән шөгыльләнүче үзәкләр саны – 12. Башкаларыннан аермалы буларак, 70 урынга исәпләнелгән «Астра» төзелгәндә үк реабилитация үзәге буларак төзелә. Ә бу – киң коридорлар, лифт, коляска белән узардай киң ишекләр, иркен бүлмәләр, ана белән баланың икесе өчен дә уңайлы шартлар тудырылган дигән сүз. «Без хәтта коридорларны да реабилитация максатларында кулланабыз – балаларыбыз махсус велосипедларда йөри», – ди Юлия Алексеевна.

Булат

Бу дөньяга ашыгып, 32 атналык булып аваз сала Булат.

– Башта үсеше әйбәт кенә барды, – дип сөйли әнисе Чулпан Хисмәтова. – Табибларның фаразы да өметле иде. 1 яшендә улымның сәламәтлегендә җитди проблемалар башланды, реанимациягә эләктек. Аннан чыкканда Булатыбыз бары ята торган гына булып калды. Күзләре начар күрә башлады, эндәшсәм, күзләре белән мине эзли – тапмый. Аңарчы күрә иде ул. 3 яшендә безгә инвалидлык бирделәр. Диагноз – балалар церебраль параличы.

Алар бу үзәккә инде 15 ел йөри. Булатка хәзер 16 яшь. Физик мөмкинлекләре чикле балалар өчен ачылган мәктәпнең 8 нче сыйныфын тәмамлаган. Яхшы укый, ике телне – русчаны да, татарчаны да камил белә. Музыка белән кызыксына, рус эстрадасының да, татар эстрадасының барлык артистларын таный, аларга кушылып үзе дә җырлый икән.

– Без килгәндә «Астра»ның ачылганына бер генә ел иде әле, – ди Чулпан ханым. – Биредә шөгыльләнә торгач, улым утыра башлады, үрмәләргә өйрәнде. Тотынырга әйбер булса, үзе йөри дә ала. Педиатр Асия Әбүзәровна Гыйләҗева, инструкторыбыз Ольга Евгеньевна Вәлиуллиналар үз эшенең чын осталары, безнең өчен бар көчләрен куялар.

Булатыбыз аралашучан. Аны 3 яшендә балалар бакчасына бирдем. Өйдә бикләнеп утыру, тышкы дөнья белән элемтә булмау мондый балаларның төп проблемасы бит. Менә шуның өчен, үземә авыр булса да, улымны көн саен иртән мәктәпкә илтәм, кич алып кайтам. Үзем дә шул ук мәктәптә эшлим. «Әни, мин сиңа булышырмын», – ди улым. Аның өйдә үрмәләп булса да йөри алуы, кашык тотып үзе ашавы да минем өчен зур уңыш инде, – дип, йөрәгеннән саркып чыккан күз яшьләрен сөртә Чулпан.

– Монда очраклы кешеләр эшли алмый, – ди педагог Лилия Кашапова. Үзәк ачылган көннән ул монда. – Биредә һәркем чын күңелен биреп эшли. «Яхшылыкка ышанасың килсә, аны үзең эшлә!» – дигән Лев Толстой. Төрле тарихлар бар, барысын да йөрәгең аша уздырасың. Ләкин Җир шарында бар кешене дә бәхетле итү мөмкин түгел. Шуларның берничәсенә генә булыша алсаң да, яшәвең юкка түгел, димәк.



«БАЛАНЫ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯЛИ»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – Балтач районы Башкарма комитеты җитәкчесе, халыкара класслы көрәшче, Татарстанның атказанган спорт остасы Айдар ХӘЙРЕТДИНОВ һәм аның улы АЯЗ.



Аяз, син быел Татарстан беренчелегендә өченче урын яуладың, Казан Сабан туенда 15 яшькә кадәрле үсмерләр арасында – абсолют батыр. Синең өчен көрәш – ... ?

– Балалар бакчасыннан ук әтинең энекәше Ринат абыйга тренировкаларга йөри башладым. Өченче сыйныфтан бирле ярышларда катнашам. Көрәш түгәрәгенә бару карарын әти кабул иткәндер, мөгаен. Барып чыкмаганда елаган чакларым да булды. Бик тырышып шөгыльләндем. Көрәш – минем өчен ярышлар, эмоцияләр, яңа танышулар, төрле җирләргә бару, үзеңне күрсәтү һәм җиңүләр. Җиңелгән очракта – үз өстеңдә эшләү, киләмдә тагын да ужәтләнү! Мин әле волейбол белән дә шөгыльләнәм. Әмма көрәш якынрак. Ул – үзебезнеке. Без бит көрәшчеләр нәселе!

Һәрвакыт көрәш белән шөгыльләнәсең килмидер. Андый чакларда үзеңне ничек рухландырасың?

– Бар инде андый вакытлар. «Әйдә, барып кайт әле», – дим үз-үземә. Әтинең тренировкаларга ачулана-ачулана җибәргәне юк. «Улым, сиңа файдага гына була ул», – ди. Шуннан барысы да аңлашыла инде.

Җиңгәч, әтиең нәрсә дип мактый?

– «Молодец, улым! Тагын да күбрәк булсын мондый җиңүләрең», – ди.

Ә киләмдә җиңелгән очракта иң беренче уең?

– (*Уйланып тора.*) Әти нәрсә дип әйтер микән дип уйлыйм бугай.

Андый чакта әтиең белән икегез арасында нинди сөйләшү була?

– Көрәшкәндә төшерелгән видеоны карый да көндәшемне ничек җиңәргә кирәклеген, нәрсәне дөрес эшләмәгәнемне аңлата. «Сиңа тагын да яхшырак шөгыльләнергә кирәк», – ди. Вакыты булганда, әти минем белән тренировкаларга йөри. Киләмдә бергә көрәшкән дә бар әле. Шул рәвешле үзе белгән көрәш алымнарын өйрәтә. Шуларны өйрәнеп кенә җиңәм инде мин.

Көрәш сиңа нинди тәрбия бирә дип уйлыйсың?

– Дисциплинага, нык булырга, үзеңне кулда тотарга өйрәтә. Көрәш бит инде ул Татарстанда иң популяр спорт төре. Һәр егет көрәшеп карарга, ошаса шөгыльләнергә тиештер, мөгаен. Миңа бик ошый инде!

Әйт әле, Аяз, әтиеңә карата курку күбрәкме, әллә хөрмәтме?

– Әлбәттә, хөрмәт. Әти-әнидән курку дигән нәрсә юк безнең гаиләдә, каршы эндәшү дә юк. Бу – язылмаган канун.

Ә үз позицияңне ничек белдерәсең соң?

– Тыныч кына үз фикеремне әйтәм. Йә әнигә әйтәм дә, ул әтигә җиткерә. Каршы эндәшмәү – фикерең булмау, сине ишетмиләр дигән сүз түгел әле ул. Ишетәләр. Әгәр ишетмиләр икән, бары үземчәрәк эшләргә тырышам. Әмма әти белән әйткәләшү гадәте бездә бөтенләй юк!

Әтиең белән, көрәштән кала, башка нәрсәләр хакында сөйләшәсезме?

– Сөйләшәбез. Әти элеккеге эше, кызык хәлләр турында сөйли. Эшкә дә өйрәтә. Атларны ничек карарга, печәнне ничек чабарга... Үз-үзеңне яклау алымнарын да күрсәтә. Әти күбрәк эштә инде, әмма ул өйдә булганда без гел бергә.

Нинди киңәше иң истә калганы?

– Ашар өчен яшәмәгез, яшәр өчен ашагыз!

Көрәшче егетнең телефонда утырырга вакыты юктыр инде ул?

– Бар инде әзрәк. Әни күрсә эндәшми әле, әти менә шелтәли. «Китап укы, йә, бар, урамга чык», – ди. Урамда дуслар белән аралашу рәхәтрәк инде анысы. Компьютерда уеннар бөтенләй уйнамыйм. Спорт кызыграк. Атнага өч тапкыр көрәш белән шөгыльләнәм. Буш вакытларымда да дуслар белән спорт комплексына барабыз әле.

Китапларга карашың ничек?

– Китап укыйм. Детективлар яратам. Әле менә көрәшче, атлет Иван Поддубный турында китап укыйм. Аны әти киңәш итте. Бик кызык! Китап уку безнең гаиләнең гадәте инде ул. Йокларга ятканчы әти белән әни дә укып ала.

Аяз, һәрвакыт әти-әни сүзен тыңларга кирәкме?

– Дөрес киңәшләрен тыңларга кирәк. Алар һәрвакыт безнең өчен борчыла. Әти белән әни беркайчанда начар киңәш бирми. Шулай булгач, алар сүзе һәрвакыт дөрес.

Айдар Фоатович, сез нинди үсмер идегез?

– Тәртип бозып үсмәдек. Безнең әти җитәкче булып эшләгәч, йөзенә кызыллык китермәдек. Авылда һәрвакыт кеше күз уңында яшисең бит. Суз дә юк, кыю да булдык, тәвәккәллек тә бар иде. Кечкенәдән эшләп үстек. Без өч бертуган хезмәт тәрбиясе алып үскән егетләр. Өстәвенә, спорт белән шөгыльләндек. Эш барыбызга да бүленде, аны башкармыйча уенга китү мөмкин түгел иде. Хезмәт белән үскән бала спортта да, тормышта да үзен таба ул. Ә кичебез мәктәп спортзалында узды. Абый келәмдә бил алыша башлагач, мин дә аңа иярдем, миннән күреп энем сөлге тотты.

Гаиләдә бала тәрбияләүдә кем төп роль уйный дип уйлыйсыз?

– Минемчә, бала тәрбияләү вазыйфасы күбесенчә әнигә йөкләнә. Без үскәндә әти иртән чыгып китә, төнлә генә кайта иде, әмма әтинең исеме һәрвакыт түр башында булды. «Әти нәрсә әйтер» дигән уй бервакытта да ташламады. Хәзер безнең гаиләдә дә мин өйдә булмаганда шулайдыр дип уйлыйм.

Балаларыгызга еш кабатлаган сүзегез?

– Эшләп үсегез, һөнәргә өйрәнегез, хәрәкәттә булыгыз, шул вакытта гына тормыш матур була, дим. Хәзерге балаларны тәрбияләү җиңел түгел. Без әти-әни кушканны эшләп, авыл мохитендә генә тәрбияләндек. Замана балалары өчен дөнья ачык. Кулларында телефон, анда – интернет. Аларга мәгълүмат алырга, яхшыны һәм начарны күреп үсәргә мөмкинлек зур. Ә кайсысын сайлыйлар: анысын үзләре хәл итә. «Эшнең нәтиҗәсе – Ходай Тәгаләдән. Ә шул нәтиҗәгә ирешү өчен нишлисең, анысы үзеңнән тора», – ди Җәлил хәзрәт. Бер әти-әни дә баласына начар киңәш бирми. Аны ничек кабул итә, тормышта ул киңәшне ничек итеп куллана – моны бала үзе билгели.

Сез – халыкара класслы көрәшче. Мондый әтигә балаларының спорт белән кызыксынуы мөһимме?

– Әти буларак, мөһим. Ләкин һәр кешенең үз физик мөмкинлекләре бар. Аяз да, Алмаз да көрәшне үзләре сайлады. Хуплыйм, кирәк чакта киңәш бирәм. Әзрәк ишегалдында да шөгыльләнеп алабыз. Әти дә безнең белән шулай әвәрә килә иде. Без – көрәшчеләр нәселе. Улларым моны дәвам итәргә тиеш дигән фикерем бар, әмма син көрәшергә, җиңәргә тиеш дигән бурыч куймыйм.

Балалар бакчасына йөргән бала келәмгә алып баруын үзе сорамагандыр шулай да...

– (*Көлә.*) Канда бар дигән нәрсә булгандыр инде. Нәрсәгә сәләтләре бар икәнен белер өчен балаларны сынап карарга кирәк. Сынап карамыйча гына яшерен сәләтләрне ачып булмый ул.

Улларыгыз өчен горурлану хисе кичлеме?

– Бервакыт балалар бакчасына көрәш, уңышларым турында сөйләргә чакырдылар. Бик хуплыйм мондый очрашуларны. Нәрсәгәдер ирешү өчен кемнәндер үрнәк алу бүген юк дәрәҗәсендә. Кумирлар юк. Очрашуга медальләремне, кубокларымны күтәреп бардым. Балаларны кызыктырырлык итеп үземчә сөйләргә тырышам. «Әйдәгез, малайларны көрәштереп карыйк әле», – диләр. Бер малайны һәм Аязны чыгардылар. Аяз әле тренировкаларга йөрми иде. Көрәшә башладылар да, Аяз җиңде. Менә шул вакытта сөенгәнем! (*Көлә.*) Улым җиңде бит! Шул күңелемә кереп калды. Әле дә менә күзләрдән яшьләр килде. Балалар белән горурлану башкачарак. Үзеңнең уңышларыңа караганда, аларныкы өчен ныграк сөенәсең шул.

Көрәшне һәр татар егете белергә тиеш дип саныйсызмы? Гомумән, көрәш шәхсән егет кешегә нинди тәрбия бирә?

– Көрәш белән кызыксынып үсәргә, аның асылын, кагыйдәсен белергә тиеш дип уйлыйм. Татарның бер милли традициясе бит ул. Әлбәттә, бөтен егет тә келәмгә чыгып батыр булып кала алмый. Батырлар күп булмый ул. Көрәш иң элек үз-үзеңә ышанычны арттыра. Тормышта үз урыныңны табарга өйрәтә. Көрәшеп үскән егетләрдә холык бар. Аннан соң аралашу мәйданы да бит әле ул. Бу аралашу тормышта нык ярдәм итә. Үземнән чыгып әйтәм.

Аязның келәмдә җиңелүен ничек кабул итәсез?

– Тормыш ул гел җиңүләрдән генә тормый. Җиңелгән икән, димәк, көндәше аңа караганда яхшырак әзерләнгән. Андый чакларда утырып киңәшләшәбез, сәбәпләрен эзлибез. Ә сәбәпне көндәштән, хөкемдардан түгел, үзебездән эзлибез. Алга таба ныграк эшләргә дигән бурыч куябыз.

Кызык, хәзер бит балаларны, син иң яхшысы, дип үстерү трендта. Сез андый әти түгел?

– Юк.

Уллар үстергән кеше буларак әйтегезче, малайлар белән ирләрчә кайчан сөйләшә башларга кирәк.

– Сөйләшә башлауга ук. Холык кечкенәдән формалаша. Бала елаган саен үчтеки-үчтеки килеп торсаң, булмый инде ул.

Ничек уйлыйсыз, улларыгыз сездән куркамы, әллә хөрмәт итәме?

– Хөрмәт итәләрдер дип уйлыйм. Бала куркып яши икән, күңелендә җыелган үпкәләр кайчан да булса начарлык булып бәреп чыгачак.

Улларыгызны үзегезнең дәвамчыларыгыз итеп кабул итәсезме?

– Әйе, Аллага шөкер. «Сөлгене сезгә тапшырдым, фамилиябезгә тап төшермәгез», – дип әйтәм инде аларга.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия





Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.

«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак, һәм аларның иң әчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

ГЫЙЛЬФАНОВЛАР КИЛЕНЕ МИН!

Нинди гаиләгә килен булып төшүемне бусагадан атлап керүгә үк аңладым: үзенә бер кояшлы утрау, сүнмәс учак шикелле тоелды ул миңа.

Фәнзилә
ГЫЙЛЬФАНОВА



Дистәләгән еллар үтеп тә, күңелдә җуелмас эз калдырган, гомергә сабак булырдай мәгънәгә ия булган бер дә онытылмас сүзләр була. Инде күптән бу якты дөнья белән саубуллашкан, ара-тирә төшләремә кереп, сискәндереп алган әбием Мәгъсүмәнең әйткәне һич исемнән чыкмый. Безне ул – ә без гаиләдә дүрт бала – «Олыларга каршы сүз әйтмәгез!» дип үстерде. Кырыс, әмма гадел, дөрес кеше иде. Таң ата, тәрәзәгә сизелер-сизелмәс яктылык төшә башлауга, яныбызга килер иде дә: «Торыгыз, нишләп ятасыз, әнә бәхетегез узып бара», – дип, йокыбыздан уятып, эшкә куа башлар иде. Авылда эш бетәрлекмени ул?! Кая барасың – торасың, әйткәнне эшлисең, карышырга, каршы әйтергә ярамый. Шулай үстек. Әнием Дилә дә әбием сүзләрен кабатлый иде. Шуңа да мин кечкенәдән каршы әйтү, сүз көрәштерү дигән нәрсәне белмәдем. Барысы да – яхшысы да, яманы да гаиләдән башлана дигән хикмәтле сүзләрнең мәгънәсенә мин тора-тора төшендем.

Мәктәпне тәмамлагач, авыл кибетенә сатучы булып эшкә урнаштым. Дус кызларым шикелле институтка керү теләге юк иде минем. Эшләп карыйм әле, аннан күз күрер, дидем. Бар иде хыялым... Профессиональ пешекче булу. Гомумән, кечкенәдән плитә янында кайнашырга ярата идем. Бәлкем, шул юнәлеш буенча китәрмен... Язмышыңа язылганы алдыңа килеп баса ул. Әбисе шулай ди бит әнә.

Һәм язылган дигәне көннәрдән бер көнне, чыннан да, алдыма килеп басты. Кибеткә таныш булмаган бер егет килеп керде. Керде дә озак кына кибет киштәләрендәге әйберләрне барлап торды. Күрепсизеп торам, күз кырые белән генә үзе мине күзәтә. Аннан кыймыйча гына сүз башлады. Үзем эчтән генә уйлыйм: минем сыман кыюсыз икән. Ялгыш уйлаганмын: кыюсыз егет булып чыкмады. Үз сүзен сүз итә торган, үзенекен эшли торган чын ир булып чыкты ул. Мин хәзер кайта-кайта шул хакта уйлыйм. Бераз сөйләшкәннән соң саубуллашып чыгып китте дә, кичен, мин эштән кайтканда капка төбебездә каршы алды. Шул чагында үҗәтлегенә хәйран калдым. Яшермим, үземә дә ошады егет. Килештермәгән егет белән сөйләшеп тора торган гадәт юк минем. «Килдем әле, ошаттым мин сине», – ди. Башта куркып киттем. Мондый сүзләрне әле беренче ишетүем. «Әти-әнидән рөхсәт сорыйм да, чыгам», – дидем. Өйгә йөгереп кердем дә, әти-әнидән рөхсәт сорадым. Шундый гадәт менә бездә. Барысын да иң элек әти-әни белергә тиеш! Аннары гына язмышыма каршы йөгердем. Танышып киттек, шактый вакыт сөйләшеп тордык. Миңа аның сөйләшүенә кадәр ошады. Үзе басынкы, үзе тыйнак, үзе шулкадәр гади. Бер ай да үтмәде, Айратым миңа тәкъдим ясады. Ул – Кукмара районының Вахит авылы егете, мин – Зур Кукмара кызы. Шулай итеп, ай дигәндә кавышып та куйдык. Тәкъдим ясаганны ишеткәч, әти белән әни: «Үзең кара», – дип кенә куйдылар. Әйе, мин аңлыйм, карарны мин кабул итәргә тиеш. Чөнки миңа аның белән яшисе! Барысы да яшен тизлегендә булды. Мине сорарга өчәүләп килделәр. Шунда беренче мәртәбә булачак кайнанам белән таныштым. Ул мине кочып алды. Ә мин аның кочагында эреп киттем. Якынлык, җылылык бөркелеп тора иде аннан. Без беренче күрүдә үк бер-беребезне ошатып, бер-беребездән канәгать калдык. Соңыннан да әле ул миңа шулай дип кат-кат әйтте. «Бер күрүдә үк якын иттем», – диде. Әйе, барысы да күз ачып йомганчы булды. 2001 елның февралендә таныштык, 7 март көнне никах булды. Ә инде 8-9 мартта – безнең туй! Өнемме бу, төшемме диярсең!

Килен булып төшкән ул көннәрне искә төшерәм дә хәйран калам. Мин үзем холкым белән тыйнак, басынкы дип әйтимме (мактанып әйтү түгел, шулай тәрбияләнгән)... Бераз куркак та. Кискен үзгәрешләрдән, көтелмәгән яңалыклардан куркып кала торган гадәт бар минем. Инде ничек яшәп китәрмен. Чит-ят җир, таныш-фәлән юк. Әнием Дилә дә шулай дип тора әнә. Ни гаҗәп, авылда иң эшчән, иң әдәпле дип саналган Гыйльфановлар гаиләсендә мин үземне беренче көннән – бусагадан аяк атлавымның беренче сәгатеннән үк үз итеп, бу дус-тату гаиләнең күптәнге һәм иң кирәкле кешесе итеп тойдым. Чөнки алар тудырган бу нәни дөньяда ясалмалык та, явызлык та юк иде. Һәр почмагыннан нур бөркелеп торган бу өйдә мин үземне шундый рәхәт, тыныч хис иттем. Әйтерсең гомер буе шушында яшәгәнмен. Дөрес, янә бераз курка калдым анысы. Янымда гел кайнана бит. Кухняга чыксам да, өй җыештыра башласам да... Гел артымнан күзәтәдер дә, хәзер, менә хәзер шелтә ясар сыман тоела иде. Ул чагында миңа 21 яшь. Күп нәрсәне белеп тә бетермәгәнмендер инде. Ә ул, пешерә башласам да, өй эшләренә тотынсам да, шулай ит, болай ит, дими, үзе яныма килеп баса да, минем белән бергә эшли башлый. Ә мин аңа карап, токмач кисәргә дә, тәмле ашлар, камыр ризыклары пешерергә дә өйрәндем. Бу кечкенә дәүләтнең үзе өчен генә булган какшамас кануннарын, тайпылышсыз үтәлә торган кагыйдәләрен мин бик тиз үзләштердем. Чөнки безнең гаиләдә дә шундый тәртип иде: таңнан торып, булдыра алганча, хәлеңнән килгәнчә йөгерәсең... Эшлисең, дип әйтүем. Авыл тормышы шундый, һәм ул башкача була да алмый. Эшләгәнең үзеңә бит. Шуны аңласаң, синнән дә бәхетлесе юк инде.

Мин килгәндә тавык-чебешләр, каз-үрдәкләрдән тыш, ике баш сыерлары бар иде. Башта әни мине сыер саварга өйрәтте. Аннары, сыерлар арта башлагач, аппарат алып бирделәр. Хәзер безнең үзенә күрә бер бәләкәй хуҗалыгыбыз бар: сөттән каймак, эремчек, катык, корт ише сөт азыклары җитештереп, Шәмәрдәнгә озатабыз. Күбрәк үзем эшләргә тырышам. Әнинең яше бара. Күп эшләтәсе килми. Аңа эш болай да җитәрлек. Әле генә 100 баш чебеш алдык. Ул аларны карый. Бик тырыш ул, бер дә тик тора белми.

Берәр җиргә барсам, әнигә булышасы бар, дип, тизрәк өйгә кайту ягын карыйм.

Ял ит бераз, дип тә карыйм. Башлаган эшен бетермичә туктамый. Булдыклы кайнана янында булдыксыз булып булмый. Гомумән, нинди генә эшкә керешсәм дә, аннан киңәш сорыйм. Кунаклар киләсе булса, нәрсә пешерим, өстәлгә нәрсә куйыйм... Егерме бер ел бергә... Аллага шөкер, бер генә мәртәбә дә сузгә килгәнебез, тавышланганыбыз юк. Ипидер менә... Юк! Бер-береңне аңлап, бер-береңә терәк булып яшәү нинди зур бәхет икән ул!

Кешенең кем икәнлеге авырлык килгәндә, кайгы-хәсрәт эчендә калганда беленә. Моннан берничә ел элек әнием Дилә үлеп китте. Һич уйламаганда-көтмәгәндә. Күзенә операция ясаганнар иде. Барысы да әйбәт, диделәр. Һәм кинәт шундый хәл. Бик еладым, бик кайгырдым. Зур югалту булды ул миңа. Шул чагында кайнанам да мине кочаклап елады. «Балам, мин сине ташламам», – диде. Без аның белән бергәләшеп әнинең өчесен, җидесен, кырыгын, елын үткәрдек. Ашарга үзебездә әзерлибез дә, төянеп Зур Кукмарага – әти янына китәбез. Икенче әни ул миңа. Балаларымның да яраткан дәү әниләре.



Айрат белән безнең биш балабыз бар: олысы Алинәгә хәзер 20 яшь, Гөлинәгә 19 яшь, Мәдинәгә 13 яшь, игезәкләрем Аяз белән Фаязга 7 яшь. Игезәкләр турында... УЗИдан игезәкләр туасын белгәч, Айрат та, мин дә телсез калдык. Шок булды, диимме. Көтмәгән идек. Юл буе машинада сөйләшмичә кайттык. Кайтып кердек. Ишек төбендә әни каршы алды. «Йә, нәрсә?» – дип сорый. «Игезәкләр, әни, игезәкләр...» – дим. Үзем чүт еламыйм. Әни мине кочып алды да: «Йә Раббым, теләгемне ишеттең, рәхмәтләр яусын. Мин бит игезәкләр турында хыяллана идем», – дип, сөенеченнән елап та җибәрде. Шул чагында бар икеләнүләр, борчылулар юып төшергәндәй юкка чыкты. Ходайның рәхмәте, әнинең шушы сүзләре генә кирәк булган миңа! Үсеп киләләр әнә. Гел әни янында. Үзләре шундый шук. Алар өйдә чагында өй эче умарта оясыдай гөжләп тора. Әни аларны кулында тота белә: узындырмаска, үз иркендә йөрмәскә өйрәтә. Өй җыештырганда минем белән бергә тузан сөртәләр. Кайчак идән юа башлыйлар. Аннары ишегалдын себерергә чыгып китәләр. Мал кайтканын шәрран ярып хәбәр итәләр. Эшләгән кыяфәт чыгаралар.

Мин әнигә бик рәхмәтлемен. Тиктормас ул малайларга кайчак үземнең дә ачу чыгып куя. Ә менә әнинең аларга тавышын күтәреп тә дәшкәнен белмим. Сабыр, тыныч, кирәк икән, каршысына утыртып төпле итеп аңлата белә. Аны тыңламыйча, ул әйткәнне эшләмичә мөмкин дә түгел. Дәлилли белә. Айратым да шундый минем. Малайлар эштән арып-талып кайткан әтиләренең башыннан йөри. Ә ул сүз әйтми: алар көен көйли.

Иремне бик яратам мин. Аның кулыннан килмәгән бер эш юк. Ул – төзүче. Хәтта өйдәге җиһазларга кадәр аның кулы белән эшләнгән. Бик булдыклы. Эштән азга гына соңга калса да, борчыла башлыйм. Нәрсә булды икән, нигә озаклады? Кайтканын сагынып көтеп алам.

Әни минем өчен үрнәк ул! Бу бик мөһим нәрсә. Арттырып та, ярарга тырышып та әйтмим: кайнанам шикелле буласым килә! Бөтен яктан да. Ике дистәдән артык ел бергә, бер түбә астында яшәп, минем әле аның күңелгә ошамаган, ятмаган якларын күргәнем юк. Ул үзе дә миңа карый да: «Малаемның бәхете булды», – дип шөкрана кыла. Адәм баласына бәхет дигән нәрсә кылган гамәлләренә карап киләдер ул. Ни өчен дигәндә, әнинең миңа әйткәне бар: кайнанасы соңгы сулышында аңа: «Үзең шикелле әйбәт килен килсә иде сиңа», – дигән. Әнидән: «Авылда беренче килен», – дигән сүзләрне ишетү, гомумән дә, Роза һәм Минневакыйф Гыйльфановлар килене булу минем өчен олы дәрәҗә, зур бәхет ул!

Мәдинә АВЗАЛОВА язып алды.
Фото: Фәнил Марсутдинов.



НАМАЗ

Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

?Күпләр намазга басмауларын: «Күрәсең, миңа әле вакыт җитмәгән», – дип аңлата. Мондый кешеләргә үз-үзләрен вакыт җиткәнгә ничек инандырырга? Гомумән, намазга басу-басмауның вакыты җиту кешенең үзенә генә бәйләнгәнме, әллә юкмы?

– Намаз ислам дине терәкләренең берсе булып санала. Кеше үзен мөселман дип саный икән, димәк, ул ислам динен таный һәм динебезне үтәүче булып тора дигән сүз. Ә ислам биш баганага нигезләнә: шәһадәт сүзләре («Әшһәдү ән лә иләһә илләллаһ вә әшһәду әннә Мөхәммәдәр рәсүлуллаһ»), намаз уку, ураза тоту, зәкят бирү һәм хаҗ кылу. Үзеңне мөселман дип атау өчен шушы биш әйберне үтәргә кирәк. «Мөселман» сүзенең тәрҗемәсе «буйсынган» дигән мәгънәне аңлата. Ягъни Аллаһы Тәгаләгә буйсынган, аның кануннарын, хөкемнәрен, биргән бөтен шәригатьләрен кабул иткән, шуңа риза булган һәм үтәгән кеше.

Ә кеше намазга басарга кайчан әзер була дип сорауга килсәк, әгәр үзен мөселман дип атый икән, димәк, әйткәнемчә, ул моңа инде әзер. Үзен мөселман дип атаган очракта да, намазга басарга әзер түгел икән, кеше үз-үзенә: «Мөселманмы соң мин? Һәм ислам диненә нинди катнашым бар? Ислам дине мин аңлаганчамы икән соң ул?» – дип сорау бирергә тиеш. Хәзер халыкта: «Күңел һәм йөрәк белән ышансаң, кешегә зыян китермәсәң, яхшы уйлар белән йөрсәң, ризыкны дөрес тапсаң, калганын үтәмәсәң дә була», дигән ышану бар. Күпләр үзләрен шулай тынычландыра. Ләкин дин ул Аллаһы Тәгалә белән турыдан-туры бәйле. Әгәр син: «Болай эшләсәм – болай дөрес була, тегеләй эшләсәм – тегеләй дөрес була», – дип фикер йөртәсең икән, ялгышасың. Монысы инде аның Аллаһы Тәгалә белән бәйле дин түгел – үзеңә үзең уйлап чыгарган дин була. Аллаһы Тәгаләнең боларга бер катнашы юк. Әгәр инде Аллаһы Тәгалә биргән динне танысаң, бу очракта аның кушканнарын үтәми хәлең юк. Менә ни өчен намаз – мөселман кешесе өчен, динне таныганнар өчен мәҗбүри гамәл булып санала.

Инде үзеңне намазга басарга ничек әзерләргә? Кеше намазны балигълык яшенә җиткәч укый башларга тиеш. Димәк, 10–12 яшьтә ул инде намаз укырга әзер дигән сүз. Аллаһы Тәгалә шулай куша. Бу очракта әзерметүгелме икәнеңне сорап тормыйлар. Чөнки без бу дөньяда «мин әле әзер түгел» дип яшәмибез. Әйтик, мәсәлән, сиңа 7 яшь тулды, ди. «Мәктәпкә барырга әзерме?» – дип берәүдән дә сорамыйлар бит – җитәкләп баралар да парта артына утырталар. Ярый, 18 яшең тулды, ди. «Мәктәпне тәмамларга, тормышка аяк басарга әзерме әле?» – дип сораучы да юк синнән. 20–22 яшь тула – инде эшкә керергә кирәк: телисеңме-теләмисеңме дип кызыксынмыйлар. Сиңа 45 яшь: иртән будильник шалтырагач, торасың да, эшкә чыгып чабасың. Кәефең юклыгы, арып китүең исәпкә алынмый. Менә намаз да шундый әйбер. «Мин әле аңа әзер түгел, башта чистарынырга, күңелне әзерләргә кирәк», – диюләр урынсыз. Тормыш ачы бер хакыйкать белән бара. Аны кабул итсәң, тормышың җиңелрәк барачак. Киресенчә булса, интегеп яшисең. Әммә бит барыбер яшәргә кирәк! Диндә дә шулай – намазсыз яшәп булмый.

Намазга басарга әзерләнү өчен бер нәрсәне аңларга кирәк: ул – Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтү, шөкрана кылуның бер ысулы. Аллаһы Тәгалә: «Минем колым бары тик фарыз гамәлләр аша гына миңа якыная», – ди. Үзе уйлап чыгарган әйберләр белән кеше аңа якыная алмый. Бары Аллаһы Тәгалә таләп иткәннәрне үтәп кенә якынаеп була. Ә нәрсә өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтергә соң? Биргән нигъмәтләре өчен! Намаз укымасак та, нигъмәтләрен каерып-каерып алабыз лабаса. Акчасын да тотабыз, сәламәтлеген дә кулланабыз, өйләнәбез, кияүгә чыгабыз, балаларны сөеп-яратып үстерәбез... Шуңа күрә намаз укыйсың, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтәсең килмәсә, аның биргән нигъмәтләрен дә кулланма.

Намазга әзер булу өчен тагын бер нәрсәне аңларга кирәк: кыямәт көнне кешедән сорала торган иң мөһим нәрсә – намаз. Пәйгамбәребез: «Әгәр дә кеше үлсә, аңардан иң беренче намазы соралачак. Намазы үтәлгән булса, кешенең калган изге гамәлләрен карыйлар, ә намазы үтәлмәгән булса, калган изге гамәлләрен карап та тормыйлар», – ди. Менә нинди хикмәт. Намаз укымыйча, «Мин яхшы кеше, берәүгә дә начарлык эшләмим, игелек кылып, ярдәм итеп кенә торам», – дип уйлап йөрүең хакыйкатькә әле туры да килмәскә мөмкин икән.

Намаз ул – дәва, җанның шифасы. Әгәр дә тәнебез авырта икән, аны бит дәваларга кирәк. Әйтик, авырганда хастаханәгә барасыз һәм сезгә: «Ашыгыч рәвештә операциягә ятарга кирәк! Хәзер үк!» – диләр. Ә сез: «Гафу итегез, мин әле моңа әзер түгел. Азрак вакыт бирегез. Бер ел, ике, ун... Юк, егерме ел!» – дисез. Ә табиб ни дип җавап бирә? «Нинди ун ел? Әгәр хәзер үк операция ясамасак, бер ай да вакытыгыз юк сезнең», – ди. Менә безнең җаныбыз да шулай. Ул авырый, сыкрый, намазсыз тилмерә – инде тәмугка керергә әзерләнә. Ә сез һаман: «Мин әзер түгел, тагын бераз көтим әле», – дисез. Ә ихтыяҗга әзер булу соралмый – аны берсүзсез үтәргә генә кирәк.

PRESSA



ӘХ, КҮҢЕЛЛЕ ӨМӘСЕ!

Лилия
ГӘРӘЕВА

Өмә ул – бердәмлек, дуслык, ярдәмләшү. Ул – безнең борынгы йолаларыбызның берсе. Күп көч һәм вакыт сорый торган эшләрне халкыбыз гомер-гомергә күмәкләшеп, өмә ясап башкарган. Киндер өмәсе, сүс өмәсе, тула басу, орчык өмәләре... Алар күп. Халкым хәтта өйне дә күмәкләп, өмә белән күтәргән. Җиту кызлар өмә белән киндер тукыган, тула баскан... Өмәләр – әле бүген дә тормышыбызның күркәм бер бизәге. Авылдашлар өмә белән чишмәләрне ача, зират чистарта, мәчетләрне юа.

Утын өмәсе

Пенза өлкәсендә үзгә бер өмә бар. Утын өмәсе ул. Әлеге төбәкнең Качкар (рәсми атамасы Кутеево) авылында туып-үскән Фирдәвес Тумеркина безгә шул йола турында сөйләде.

– Элек, өйләргә газ кергәнче, утынны күрше-күлән өмә белән әзерлиләр иде. Кечерәк чакта андый өмәләргә без дә катнаштык, – ди ул. – Урман ачасы бар, дип, олылар алдан ук хәстәрен күрә башлый. Урманчы белән сөйләшеп, делянкалар билгеләнә. Делянкадагы һәр агачны кисәргә ярамый – яшь чыбык, корыган, чирле агачлар гына киселә. Бу ике як өчен дә файдалы, авыл халкы да кышка утынлы була, урман да чистарып кала. Урманны, гадәттә, җәй башында ачалар. Бәрәңге (Пенза ягында аны картюк диләр) чүпләре инде уталып, төбенә өелгән, печәнгә төшәргә әле иртәрәк... Менә шул вакытта күрше-күлән, берләшеп, кышкылыкка дип утын әзерләп кала. Ир-атлар, яшьрәк хатын-кызлар балта белән нечкә агачларны чабып, кисеп бара, без, бала-чага, аларны юлга якынрак җиргә ташып, өя барабыз. Һәр өем янына казык кагып, кайсы гаиләнеке икәне языла.

Урман ачарга бару үзе бер күңелле вакыйга. Һәркем өеннән ашарга-эчәргә алып килә: йомырка, якмыш, җәймә, шешә белән сөт... Аерым ашау-эчү юк, чистартылган аланга ашъяулык җәеп, һәркем үз ризыгын уртага куя.

Игеннәр җыелып беткәч, ул утыннарны трактор арбаларына төяп, кабак (капка шулай атала) алдына алып кайтып бушаталар. Монда да күмәклек сорала, чөнки ул авыр эш, вакытны күп сорый. Ә бергә-бергә эшләгәч, арырга өлгермисең дә. Көз көне исә шул утыннарны кисеп, өеп куябыз. Гаиләсе ишле булганнар бу эшне үзләре башкара, ялгызларныкын, карт-карчыкларныкын кисеп бирергә кабат өмәгә җыелабыз. Монысында инде башлыча яшьләр – 15–17 яшьлек егет-кызлар катнаша. Нечкә чыбыклар, тапамага куеп, балта белән чабыла. Юанракларын, өчаякка салып, ике куллы пычкы белән кисәбез. Киселгән утынны бер төркем әрдәнәгә өя бара. Утын киселеп беткәч, барыбызны мул табын көтә. Безнең якта өмәчеләргә эшти

пешерәләр. Эшти – итле шулпага салма (токмач) салып пешерелгән аш. Итен исә турап, картюк белән аерым чыгаралар. Тамакларны туйдыргач, теләгән кеше мунчага кереп, юынып чыга. Утын киселгән көнне мунча ягу – өмәнең мәҗбүри өлеше. Аннары өйләргә таралышабыз. Ләкин бу өмә бетте дигән сүз түгел әле. Хуҗалар безне кичен уенга чакырып кала. Кичке эшләрне карагач, киенеп-ясанып, уенга киләбез. Анысы өй эчендә була торган иде. Яшьләр түгәрәкләнеп утырып, төрле уеннар уйныйбыз – йөзек салыш, прәшкәдән... Җырлыйбыз, биибез. Прәшкәдән уены турында әйтеп китим әле. Урындыклар алып, түгәрәкләнеп утырабыз. Берәү, кулына солдат каешын икегә бөкләп тотып, уртага баса да берәрсе янына килеп, сорау бирә: «Тәп-тәп Зарифы (авылда һәр нәселнең кушаматы бар, исемгә дә шул кушаматны өстәп сөйләшәләр) кем янына йөри?» Тегесе әйтми торса, ботына каеш прәшкәсе эләгәсен көт тә тор! Кемнең сыктырып торасы килсен, серне чишәргә туры килә, билгеле.

Фирдәвес апа узган ел утын кисү өмәсен үзе оештырып, аны яшьләргә дә күрсәткән.

– Гореф-гадәтләр белән яшьтән үк кызыксынам, – ди ул. – Өемдә бер бүлмәне музей итеп, балаларыма тарихи мирас калдыру хыялым бар. Анда саклanырлык экспонатларым да җыелган. 1876 елда туган карт әбием Айникамалның, 1894 елгы Фатыйма әбиемнең, әниемнең күлмәкләре әле дә исән. Карт әбиемнең күлмәгенә инде 150 ел.

Печән өсте

Җәй челләсе. Көндез хәтта болындагы чикерткәләр дә тынып калган кебек. Күк йөзендә кульяулык кадәр дә болыт әсәре юк. Авылның эшкә яраклы бар кешесе болында – печән әзерләүдә. Хәзер печәнне мотоблоклар, бензин белән эшли торган триммерлар, тракторлар белән чабалар. Ә бит әле кайчан гына печән әзерләүдә төп эш коралы чалгы иде. Бишле, алтылы, җиделе, сигезле чалгылар... Бишлесе – кыска чалгы, капка-койма тирәләрен чабар өчен кулай, җиделесе, сигезлесе – зур, болында печәнне киң колач белән алдырып чаба торган чалгылар.

Яшел Үзән районының Бакырчы авылыннан Рәйханә апа Зәйнуллина балачакта колхозчылар белән печән өмәсенә төшкән көннәрен әле дә яхшы хәтерли.

– Печән өсте дисәң дә печән өсте иде шул, – ди ул. – Олысы-кечесе иртә таңнан кырда. Авылның кайсы очыннан нинди юл, сукмак булса, барысының да тузанында арба эзе ярылып ята. Кая күз салсаң да – таптакыр, берәр җирдә ник бер уч печән калсын?! Анда-санда шайтан таягы белән әрем генә тырпаеп тора. Чөгендер чүбенең бер каты инде уталган, икенчесе әле өлгермәгән чак. Колхозның люцернасы өлгергән, шуны чабарга чыгачаклар. Яхшы каралган чалгы булса, печән үзеннән-үзе чабылган кебек, артык ардырмый. Чалгыны бөтен кеше дә кайрый белми, аны тапаучы аерым осталар була. Сандалга – бүкәнгә беркетелгән тимер шакмакка салып, чүкеч белән тапыйлар аны. Алдан ук су мичкәләрен дә карап куялар. Анысын инде бабайлар башкара – ат арбасына куеп, кырдагыларга эчәргә су алып киләләр. Үзем дә алтынчы классны тәмамлагач, колхозчы хатын-кызлар белән печән чаптым. Чапкан печән кибүгә сәнәк-тырмалар белән печән җыярга чыгалар. Аннары аны ат арбасына олаулап төйиләр, яшьрәкләр юллаган печәнне тырмалый бара. Шул олауларны кибәннәргә ташыйлар. Кибән салуның да үз осталары бар. Матур, җыйнак итеп кибән сала белүчеләр – өлкән бабайлар. Печән өстендә олысы да, кечесе дә мәш килә. Авылда бала-чага караучы әбиләр генә калыр иде. Алар тирә-күрше балаларына да күз-колак булып тора. «Бер сыер, өч баш сарык асрап, кыш чыгарга 56 арба печән-курмы кирәк», – дия иде әни. Ничә арба кирәкләген дә санаганнар бит әле! Алар төяп кайта торган арбадагы печән зур карават озынлыгында, метрга якын биеклектә, ныклап, тыгызлап бәйләнгән олау була иде.

Печәнгә барганда-кайтканда җыр лый торган җырлары да булган әле.

Җитен генә күлмәк җилфердидер
Болыннарда печән чапканда.
Күкләр дә күкерәр, җир тетерәр,
Печәнчеләр җырлап кайтканда...

Нократ ягында авылга быел гына килгән яшь килен, печәнгә төшкәч, болында оннан боламык пешереп, печәнчеләрне сыйлаган. «Болом саламат» дип аталган ул. Яшь киленнең әнисе печән чапканда пешерер өчен ак он биреп җибәргән. Шуннан куе гына боламык болгатып, сыер мае белән ашаганнар. Ул якларда «болым затма» дип аталган йола да башкарылган. Печән өстенең соңгы көнендә тәмле ризыклар пешереп уздырганнар аны. «Болом затмага» дип, яшь киленнең әнисе тавык тутырган.

Борынгыдан калган тагын бер шаян йола – яшь киленне суга салу гадәте. Шушы төбәкнең су ияләре белән таныштыру өчен башкарылган дип аңлаталар аны. Елга янынннан узганда яшь киленне күтәреп алып суга ыргытканнар. Аның артыннан яшь кызлар да суга чумган. Йоласы шулай булгач, үпкә-сапка тотучы булмаган.

Печән өстенә дип, элек берәр сарык чалганнар, күп итеп катык оеткannar. Әче катык әйрән ясар өчен әйбәт. Катыкны салкын чишмә суына туглап, тәменчә генә тоз салып ясалган әйрән сусауны да яхшы баса, тамакны да туйдыра. Көне буена кояшта җылынмасын өчен, әйрәнле савытны якындагы чишмәгә батырганнар яки җиргә күмгәннәр. Печән өмәләре, бераз үзгәрәк булса да, авылда әле дә яши. Болында үзең чабып киптергән печәнне хәзер дә туган-тумача, күрше-тирә белән бергәләп төяү, кертеп урнаштыру гадәте бүген дә бар.

Урак өмәсе

Печәннәр җыелып беткәч, урак өсте башлана. Уракны җиңел куллы кешедән башлатырга тырышканнар. Беренче учманы җиңел куллы кеше урса, урак җәйлы бара дигәннәр. Пермь ягында урак өмәсе «урак пумич» дип йөртелгән. Өмәгә беренче булып килгән кеше «пумич башлык» булган. Аңа атап өч бүлемле шаңгә

Өмәләр авылда әле дә яши. Болындагы печәнне туган-тумача, күрше-тирә белән бергәләп төяү, кертеп урнаштыру гадәте бүген дә бар.

пешергәннәр – бер бүлеменә кишер, икенчесенә бәрәңге, өченчесенә эремчек салганнар.

Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» повестенда урак өмәсе шулкадәр матур тасвирлана. «Урак өмәсе – үзе бер бәйрәм ул. Көне буе янып-пешеп эшлиләр дә кичен ихата тутырып табынга җыелалар. Ит согынналар, шулпа чөмерәләр. Олырак ир-ат, чаярак бичә-чәчә шау-шу килеп бал эчә. Егет-җилән белән кыз-кыркын табыны болай да, бал эчми дә кызмача була. ...Өмәгә сайлап кына, көндез кулыннан эш килер, кичен табын кадерен белер кешеләрне генә чакыралар. Анда эләгү мәртәбәгә санала. Дөрес, кайбер әрсезрәк адәмнәр чакырганны да көтеп тормый.

...Кояш чыгуга, безнең капка төбендә мәхшәр кайный иде. Кулбашларына уракларын салып, бөтенесе дә килгәннәр... Якынрак кардәш-ыру, алдан әйтеп куелганча, атын җигеп килгән. Быел арыш басуы ерак. Җәяүләп озак барырга кирәк булачак. Аннан да болай, өмә урагына җәяү йөрү үзе үк килешә торган эш түгел. Яме китә.

...Кыз-кыркын белән килен-кишттә, чыр-чу килеп, әле теге арбага, әле бу арбага барып сугылды. Берсе ахирәте, икенчесе кардәше, өченчесе күршесе янына эләгергә тырышты... Олырак хатыннар белән ир-ат тегеләрдән калган арбаларны тутырды.

...Төшкелеккә баллы катык белән юача булды. Өмә ашы үзе бер тамаша ул. Һәр табынга зур-зур табаклар куелган, тау-тау итеп юача киселгән. Табак тирәли утырган өмәчеләр кашыкларны биетә генә. Оялып, юанып утырсаң, ач калуыңны көт тә тор. Туя биргәчрәк шаяру, көлешү дә башланды. Йә берәүнең кулындагы кашыгын кинәт табакка бәреп төшерәләр, йә икенчесенең кулыннан, инде каптым дигәндә, калачын тартып алалар. Теге ачык авызлардан бөтенесе дә гөж килеп көлә шуннан...»

Өй салу өмәсе

Мишәрләр аны «диңгез кору», «нигез салу» дип тә атый. Өйнең нигезен корган көнне пешерелгән ботканы да «диңгез боткасы» дип йөртәләр.
Бу көнне өй янына миләш агачы утырту гадәте дә булган. Печән өстенә бәйле хатирәләрен уртаклашкан Рәйханә апаларның өе дә 1973 елда өмә белән күтәрелә. Ул көннәр матур бер истәлек булып әле дә хәтерендә яши аның.

– Абый бүрәнәләрне Айшә урманнарыннан кисеп алып кайткан иде. Осталар яллап, аны бураттык, – дип искә ала Рәйханә апа яңа өй салып чыккан чакларын. – Иртәгә өй күтәрәбез дигән көнне бөтен туган-тумачага, күршеләргә, авылдашларга, балта осталарына әйтеп чыктык. «Киләбез, киләбез!» – дип калдылар. Өмәгә дәшсәләр, ничек тә килергә тырышалар иде. Хәтта эштән сорап ук калалар. Кырыктан да кимрәк кеше җыелмый. Аллаһының рәхмәтедер, өмә узасы көнне көне дә матур, кояшлы була торган иде бит. Һәрхәлдә, өмә вакытында яңгыр яуганын хәтерләмим.

Бүрәнә арасына кыстырасы мунчалаларны, саламнарны алдан ук барлап куйган буласың. Безнең якта мүкле күлләр юк, мүк урынына мунчала кулланалар. Өмә көнне хатын-кызлар иртүк көянтә-чиләк белән су ташырга керешә. Бездә ул вакытта суны тау астыннан, ерактан ташыйсы. Саламны чылату өчен су күп кирәк. Бабайлар озын тактага йөз иллеле кадак кагып, «тарак» ясый. Монысы – мунчала тарау өчен. Бу эшне бала-чага башкара.

Иң беренче эш итеп булачак өйнең дүрт почмагына дүрт имән бүкән куела. Дога укып, һәр чатлыкка (почмакка) догалык куеп калдыралар. Осталар отвес белән бүрәнәләрнең тигезлеген карап кына тора. Кузлалар тезеп, 12 бүрәнәгә кадәр күтәрәләр өйне. 12 нче бүрәнәне салгач, матча куела. Матчаны күтәрү – иң җаваплы һәм авыр эшләрдән. Матча күтәргәндә дә дога укыла.

Рәйханә апаның сүзен бүлеп әйтик, Сергач якларында матчаны күтәргәндә осталарга сөлге бүләк итү гадәте бар икән. Сөлгегә бер бөтен ипи дә бәйлиләр. Бер матча булса – бер сөлге, икәү икән – икене. Шулай ук матча астында бер тавык чалу йоласы да булган. Пенза өлкәсендә яшәүче татарлар тавыкны мич урынын ясаган вакытта чалган. Ләмберә татарларында исә мичне беренче тапкыр якканда корбан канын чыгару гадәте билгеле.

– Өмә көнне табынга хәрам кертмиләр, бу көнне барысының да күңелендә бары изге теләк кенә – салган йортларының игелеген күреп, исәнимин яшәсеннәр, – дип дәвам итә Рәйханә апа. – Ул көнне бөтен туган-тумача ризык алып килә. Кем – аш, кем – йомырка, май, сөт, ипи...
Су ташыган хатын-кызлар тиз-тиз генә йомычкаларны себереп алып, җиргә зур палас җәеп, шушы ризыклардан табын кора. Кайда нинди табак, тәлинкә, кашык бар – шулар белән ашыйбыз. Ызба ашы дип атала ул. Олылар тамакларын туйдырып кузгалуга, урамда нинди бала-чага бар – табынга аларны чакыралар. Алар да иртәдән бирле тырышып эшләде бит өмәдә! Күмәк эшләгәч, шулкадәр тиз күтәрәләр иде ызбаны.

Бүген дә, Аллаһка шөкер, шушы өемдә яшим. Кичә генә салып кергән шикелле әле дә. Бүрәнә арасына кыстырган мунчалалары да шул килеш. Рафаэль, Нурулла, Нуретдин абыйлар бу эшнең чын осталары иде шул. Өйнең мүген кыстыру өчен зур осталык кирәк.

Мондый өмәләр бүген дә уза бездә. Дөрес, өй үк салмыйлар, гараж, мунчаларны өмә белән күтәрәләр. Өмәдә бит савап өчен генә катнашасың, бер тиен дә акча алмыйсың. Өмәдә катнашу – изге эш.

Кадерле укучыларыбыз, өмәләр турында язып та, каз өмәсен телгә алмаганнар, димәгез. Бу хакта алдагы саннарыбызда укый алырсыз.

Язманы әзерләгәндә галимә Флера Баязитова хезмәтләре файдаланылды.



« Видео: Фирдәвес Тумеркина. Фотода Арча районы Кышкар авылыннан Харис Вәлиев, Фәрит Галиев, Нәзир Гайнетдинов (сулдан-уңга).



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

ӘКИЯТ

Бу дөньяда бернәрсәне дә: «Юк, әкият сөйләмә! Мондый хәл беркайчан да була алмый!» – дип әйтергә ярамыйдыр. Чөнки адым саен төрле хәлләр булып тора. Менә ниндидер күренеш... Ул физиканың да, химиянең дә, арифметиканың да, гомумән, тормышның бер канунына да туры килми, андый хәлнең булуы мөмкин түгел. Бу мөмкин түгеллек әллә нинди формулалар белән исбатланган. Әмма теге күренеш... Ул бар!

Мин сөйләячәк вакыйга да шул көтелмәгән күренешкә бәйле инде. Ир белән хатын мәктәптә укыганда ук бик яратышып йөриләр, озатышалар, өйләнешәләр. Балалар үстерәләр. Бөтен тирә-як аларны үрнәк итеп куя. Менә, ичмасам, яхшы гаилә, бер-берсе өчен өзелеп торалар. Һәм иң гаҗәбе – бу чынлап та шулай. Болар бер-берсе өчен өтәләнеп торалар, яратулары һәрберсенең хәрәкәтеннән, сулышыннан сизелеп тора. Юк инде... Бер-берсен яраткан булып кыланучылар да бар, әлбәттә... Тик андыйларның сизелеп тора ул... Ну, күнегелмәгән чөнки, табигый түгел. Ә боларныкы – чыпчын. Хәтта үзара мөнәсәбәтләрен энәсеннән җебенә кадәр тикшереп утырсаң да алардан да табигыйрәк булу мөмкин түгеллеген аңлыйсың. Болар бер-берсен чынлап та ярата. Берсүзсез.

Һәм менә шушы искиткеч бәхетле һәм мәхәббәтле пар көннәрнең берендә хисләренең суына башлавын сизеп кала. Учакта сызып барган куз сыман, боларның да тойгылары сүрелеп бара. Бер карасаң, гаҗәп тә түгел инде. Өйләнешеп озак яшәгәннәр, балалар табып үстергәннәр: табигать алдында да, җәмгыять алдында да вазыйфалары үтәлгән. Хәзер дөртләп торган мәхәббәтнең артык кирәге дә юк кебек. Рәхәтләнеп, үз эгоизмыңа чумып яшәргә дә ярыйдыр шикелле. Ләкин яратышып яшәүгә бер күнеккәч, аннан тиз генә аерыласы да килми икән. Әчләре поша инде боларның, тик бер-берсенә әйтергә йөрәкләре җитми. Беренче булып ир тәвәккәлли. Озак кына уйланып йөри дә бу, берәр атнага ял йортына элдертергә уйлый. Әмма хатынына турыдан-туры әйтми, командировкага киттем, дип алдаша. Ялганлау бик матур гамәл түгел, әлбәттә, ләкин эшләрне көйләп, элекке мөнәсәбәтләрне балкытып җибәрүгә сәләтле икән, аны да кулланырга мөмкин. Вакытын һәм микъдарын белеп кенә инде, ашка тоз салган кебек кенә.

Хатын бик карышып тормый:

– Ярый, бик яхшы, мине дә җибәрүләре мөмкин әле, – дип елмая. – Икебезнең командировка бер вакытка туры килү бик уңайлы да әле.

Шулай итеп, болар икесе дөньяның ике тарафына командировкага чыгып китә. Ир бер кичне моңаеп кына диңгез буеннан китеп бара. Табигать матур инде монда, хатын-кызларның да ягымлысы бик күп. Тик күңелендәге сагыну хисен бернинди матурлык та алдыралмый: күңеле өенә, хатыны янына тартыла. Аның белән урам әйләнүләр дә, кара-каршы утырып чәй эчүләр дә бик зур бәхет булган икән лабаса. Бернинди диңгез-фәләнең дә, ял йортың да кирәкмәгән...

Ир шулай ары-бире йөрени дә, аптырап, бер кафега кереп утыра. Боек инде күңеле. Тамагына аш та үтми, уй-хисләре дә балкып китми. Үзен ялгыз итеп тоя. Утыра бу шулай башын иеп. Бер мәлне күтәрелеп караса, кафеның теге яктарак урнашкан бер өстәлендә моңаеп кына утырган ханымны күреп кала да дертләп китә. Үзенең хатыны лабаса!

Ир күзләрен ачып-йомып ала, үз-үзен чеметеп карый. Һәм әлеге хәлләрнең чынбарлык икәненә тәмам ышангач, урыныннан сикереп тора да теге өстәл ягына атлый.

– Сез мине көтеп утырасызмы, ханым?

Хатын да бер мизгелгә югалып кала һәм иренең куенына ташлана. Гадәти «нормаль» гаилә, әлбәттә, бераз тәрткәләшеп, үпкәләшеп алыр иде. Болар тиргәшеп тормыйча гына хәлне бер-берсенә аңлатып бирәләр дә бергә булуларына сөенеп туялмыйлар. Бергәләп шәфәкъны күзәтәләр... Ай йөзгәнен... Таң атканын... Шушы хәлдән соң сүрәнләнә башлаган мәхәббәт кабат яңарып китә.

Бер карасаң, әкияттәге кебек, әйеме. Ә икенче карасаң... Һәркем үз әкиятен үзе төзи инде...

«ЕРЫП БАРЫРГА ЯРАТАМ!»



Алсу ШАКИРОВА

– Мактауга кайтып калмасын, – дип кисәтте ул әңгәмә барышында. «Яхшылык эшлә дә, суга сал», дип яшәүчеләрдән, чөнки... Аның кебекләр үзе турында үзе сөйләми. Аның кебекләр турында халык сөйли: «Безнең Фәнир!» – дип горурлана, яхшылыкларын искә алып, көн саен рәхмәт укый, гамәлләрен хәтер китабына уеп калдыра... Килештек. Ничек бар – шулай язабыз. Россиянең мактаулы энергетигы, «Россиянең татар авыллары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы советы рәисе, Татарстанның атказанган артисты, Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия төбәкләрен электрлаштыручы «Ильфа» җәмгыяте җитәкчесе, композитор, җырчы, шагыйрь Фәнир ГАЛИМОВ гап-гади авыл егете дип башлыйк...



ТАМЫРЛАР Балта осталары нәселеннән мин. Җиде буын бабаларым да – балтачылар. Авылдагы мәчетне дә алар төзегән. Балтачылык – минем канда. Әтеки Гыйльметдин исемле. Шофёр булып эшләде, колхозда терлек карады. Безгә бер тапкыр кул күтәрү түгел, авыр сүз әйткәне дә булмады. Тавык та суймады ул хәтта. Сугышка китеп, дүрт ел буе әсирлектә булган, күпне күргән кеше иде шул... Шунда булып та, бер тапкыр да тәмәке тартмаган, хәмер эчмәгән. Хәзер яши торган йортымны әтеки, туганнарым белән бергә күтәреп, салып чыктык. Авылда безне Әсәмәй дип йөртәләр иде. Сабит бабакай – бик динле кеше – нык кызу сөйләшкән. «Әссәламегаләйкем»не, кызулап, «әсәсмәй» дип кенә җибәрә торган булган. Шуннан кушамат та ияреп калган. Үскәнче Әсәмәй булдык без.

Инәки ягыннан да әбекәй-бабакайлар шулай ук гади эшчеләр. Инәки Бибинур исемле. Ул вакытта безне үчтекиләп, иркәләп утырмадылар. Сугышып, елап кайтып керсәм дә, үзегез хәл итегез, дип, кире борып чыгара иде инәкәй. Колхозда эшләп үстек. Бездән: «Дәресеңне әзерләдеңме?» – дип кызыксынучы юк иде. «Шул эшеңне эшләдеңме?» – дип кенә сорадылар. Әтеки-инәки икесе дә бик матур җырлыйлар иде. Урамның теге башында тальянчы Закир абый яшәгән. Безнең йорт белән арасы бер чакрымдыр. Тальянчы Закир белән Гыйльметдин урамның уртасында очрашалар, дип сөйлиләр иде авылда.



БАЛАЧАК Бәләкәй генә йортта җиде бала үстек – биш малай, ике кыз. Әбекәй дә безнең белән яшәде, 100 яшен тутырып күчте бакыйлыкка. Йорт уртасында мич тора иде, аның артына кайчак бәкәй дә, бозау да керә. Кыш көне сыерны алып кереп сауган чаклар да булды. Ун җан яшәдек шулай. Мал карап, көтү көтеп, фермада эшләп үстек. Балачак су буенда үтте. Эшне тәмамлыйбыз да уйнарга йөгерәбез. Җәен бигрәк тә, чыгып сыпырырга гына торабыз. Элек буаны үз кулларыбыз белән буа идек, тракторлар юк бит. Чирәмне шакмаклап кисәбез дә, шуны аска таба каплап өябез. Кәс дип атыйлар иде аны. Олырак егетләр чирәм кисеп тора, без – бәләкәйрәк балалар ташып торабыз. Бер кәсне төшереп ватсаң, яңадан өчне алып килергә тиеш буласың. Кәс ташымасаң, булышмасаң, сине буаның иң сай җиренә генә кертәләр. Тәртибең начар булса, йә йөзә белмәсәң, тотып суга да аталар әле. Шар-шар киләсең дә йөзәргә дә өйрәнәсең шунда. Зур малайлар шулай өйрәтәләр, тәрбиялиләр иде безне. Тәмәке тартырга да, сүгенергә дә, беренче тапкыр эчеп карарга да...

Кыш көне дә урамнан керми идек. Су юк – малга эчерергә, мунча ягарга көянтә-чиләк йә фләге белән чишмәдән су ташыйбыз. Безгә әйтәсе дә юк: малларның асларын тазартабыз, чистартабыз, печәнен салабыз, суын эчерәбез. Утынны кисеп яру да – әйтмичә дә белеп эшли торган эшебез иде. Аллага шөкер, балачагым эш белән үтте.

Инәки фермада эшләгәч, без дә бәләкәйдән бозаулар карадык. Иртән мәктәпкә киткәнче 35–40 баш бозау эчерә идек. Аны бидрә белән, саклап эчерәсе бит әле. Чөнки тотып тормасаң, бозау башы белән төртә дә аудара чиләкне. Аннары фермадан кайтып чәй эчәбез дә мәктәпкә китәбез. Кайткач, тагын эш. Бервакытта да эшләп үскәннән кимсенмәдек. Хезмәт тәрбияләде безне. Мәктәптә дә «син кем баласы» дип аеру юк иде, бөтен кеше тигез. Абыйлардан калган киемне киеп үстек, безнекен энекәшләр киде.

Класста унбер малайдан сигезебез гармунда уйнадык, бер-беребездән күреп өйрәндек. Ул елларны капка төбе саен диярлек бүрәнәләр ята иде. Кичен



Фото: Анна Арахамия

көтү сакларга күрше-тирә безнең капка төбенә җыела. Гармун уйнаучылар күп – моңланып, җырлап көтү кайтканын көтәбез... Безнең өйдә гармун уйнаучы юк иде. Ә туганым Фазылга әти-әнисе гармун алып бирде. Фазыл үзе уйный, бирми бит гармунын!.. Шуннан, үзе югында гармунны мунчаларына алып чыгып китәм дә качып уйныйм. «Умырзая» җырын шулай өйрәндем. Шулкадәр тансык булган, уйныйсы килгән, күрәсең. Миннән башка гармунда уйнаучы булмаса да, олы абый бик матур җырлый иде. Урамның арткы ягыннан җырлап кайтса, тавышы, һаваны яңгыратып, ярты чакрымнан ярылып ишетелә.



УКУ Гади эшчеләр гаиләсендә үстек, институтка керәбез дип хыялланмадык. Уку уртача барды. 11 классны кечке мәктәптә бетердем. Ветеринарлыкка укырга китәргә җыенам... «Чыгып китмә, улым, фермада гына эшлә. Әзрәк онын, силосын алып кайтырсың. Шул җитә. Дуга кергән йортка дога керә, диләр», – ди әбекәй, мәрхүмкәй. Читтә йөрүнең кирәге юк, үскән җиреңдә яшәргә кирәк дигән фикердә булганнар элек.

Әле авыл турында китап чыгарыр өчен 1950 нче елгы укучыларның фотоларын эзләдек. Шул елгы кызларның бөтенесе дә – 17 кеше булган алар – фермага эшкә кергән. Вакыты шундый иде. Белем алырга дип атлыгып тормадык.

Кечке мәктәпне тәмамалагач, армия хезмәтенә киттем. Радиотелеграфист итеп алдылар. Морзе әлифбасын өйрәнеп, аэродромда хезмәт иттем. Армиядән кайткан елларда КамАЗ төзелеше, Чаллы шәһәре дип хыяллана иде яшьләр. Минем дә бөтен уем – Татарстанга китеп җырчы булу. Чаллыда укырга урнаштым да, ун көн ял биргәннәр иде, авылга кайттым. Инәкиләр пенсиягә чыгып килә, абый укырга киткән, энекәш – армиядә, калганнары бәләкәй. «Улым, монда гына кайт, безне кем карар», – диделәр. Шулай итеп, авылда төпләндем. Олыгайгач кына Уфаның авыл хуҗалыгы институтында читтән торып югары белем алдым.



УҢЫШ Авылда төпләнеп, берничә ел шофер булып эшләгәч, «Мехколонна 11» дигән предприятиегә механик булып урнаштым. 90 нчы еллар бу: предприятиеләр банкротка чыга, тарала башлады. Хезмәт хакы юк. Йә он, йә ит, йә суыткыч белән түлиләр. Безнең предприятиене дә кемнәрдер сатып алырга теләгәнен белдек. Концертлар куеп йөри башлагач, «Ильфа» дигән оешма ачкан идек. Баянистыбыз Илшат Мирзагалиев һәм Фән Вәлиәхмәтов исемнәрен кушып ясалган атама ул. Коллектив белән сөйләштек тә, предприятиене үзебез сатып алып «Ильфа»га рәсмиләштереп куйдык. Бер миллион кредит алдым. 2000 нче ел өчен бик зур акчалар иде ул. Бер исем астында предприятие дә, концертлар да эшләде. Оешманы җитәкләгәнгә 21 ел булды инде менә, электрика юнәлешендә уңышлы гына эшлибез. Коллективсыз мондый күләмне колачлап булмас иде. Шул вакытта тупланган җигелеп тартучы коллектив – әле дә төп әйдәп баручыларыбыз. Предприятиене, коллективны саклап калуны төп уңышым дип саныйм. Улым Илдар – минем урынбасар, кызым Айгөл – хисапчы, кияү-киленебез дә бездә эшлиләр. Алар да бик зур горурлыгым. Балаларың белән бергә эшли алу иң кыйммәтле әйбердер. Эштә дә, өйдә дә, ялда да бергә без.

Иҗатка килгәндә, мин аңа чын итеп карамадым да кебек. Әмма иҗат эштә бик күп ярдәм итте. Мал караучымы, президентмы, директормы – барыбыз да шул бер үк җырны яратабыз. Шуның аркасында күп эшләрем уңышлы булгандыр да.



ДУСЛАР Фән белән дуслыгыбызга 30 ел... Бер-беребезне очраклы гына тапкан кешеләр булсак та, тормыш юлында гаиләләр белән бергә атлыйбыз. Балалар да, оныклар да аралаша. Бик уңышлы дуслык булды ул! Мине тыңлап караганнан соң: «Әйдәле, тимер-томыр арасында гына ятма», – дип, ияртеп чыгып киткән иде Фән. Ул вакытта механик булып эшли идем әле. Фән аркасында иҗат дөньясына барып кергән кеше мин. Бераз гына үземдә дә бардыр инде... Җыр тормышта бөтен яклап ярдәм итте. Дуслар табарга, хәтта дошманнар да... Аларны аера белергә өйрәтте. Көнләшкән кешеләр дә җитәрлек. Алар миңа көч бирә! Әйткән саен, тагын да үҗәтләнеп эшлим. Рәхмәт дими, ни дисең? Ә Фән, чыннан да, иң якын дустым. Серләребез дә, моңнарыбыз да килешә. «Бер ыштанның ике баласы», дип йөртәләр безне Казанда. Кеше арасына шулай кергәнбез инде... Бик рәхмәтлемен аңа. Эш башлаганда иң авыр вакытта Башнефтьнең генераль директорына алып кереп, юллар ачып җибәрде... Предприятиенең почетлы кешесе ул. Шулай да башка җирдә Фән Гафисович дисәләр, бездә Фән дип кенә эндәшәләр аңа. Аның кебек туганнар да сирәк.

Татарстан буйлап кына түгел, башка төбәкләрдә дә күп йөрергә туры килде безгә. Кая гына алып бармады, кем белән генә таныштырмады мине дустым. Татар язмышына, моңга мөкиббән кешеләр белән очрашырга туры килде. Минтимер Шәрипович һәм Сәкинә ханым белән аерым гына утырып чәйләр эчкән бар. Шаһинур абый Мостафин белән танышкач, мондый да кеше була икән дип уйлаганымны әле дә онытмыйм. Вагыйз Минһаҗев Арча районын җитәкләгәндә авыл хуҗалыгы эшчәннәре концертына чакырды безне. Бүләкләү башланды. Вагыйз Василович иң беренче итеп унбиш колхоз рәисенә, аннары комбайнчыларга машина бүләк итте. Аннары: «Улым, укып бетергәч безгә кайтырсың», – дип, әтисе белән бергә комбайнда эшләгән 11 нче класста укучы егеткә «Урал» мотоциклы ачкычын тоттырды. Ә мин залда... елап утырам. Хезмәт кешесен шулкадәр олылауны күреп күңелем тулды шулчак... Әнә шундый өлге итеп алырлык шәхесләр үрнәге йокмый калмый ул...



МАВЫГУ Элек бөтен мавыгуым җыр иде. Гомер барган саен, үземнән соң нәрсәдер эшләп калдырасым килә. Коръәндә дә малның өчтән бере белән бүлешергә кушылган бит. Хәзер төп мавыгуым дип, ачык һавада урнашкан «Бабай утары» этнографик музеен атарга буладыр.

Утар урнашкан хуҗалыкны арендага алдым. Анысы да йомшаклыгым аркасында. Колхоз ашламага дип акча сорап торды, аннары тагын сорадылар, тагын ярдәм иттем... Акчаны кире бирә алмадылар – колхоз банкротка чыкты. Шуннан соң хуҗалыкны арендага алырга мәҗбүр булдым. Сәгать дүрттә хуҗалыкны алу буенча җыелыш булырга тиеш иде, сәгать өчтә инәки үлеп китте... Алмаска дип кисәткән кебек... Ул хуҗалык миңа кирәк тә түгел иде, чыгымнары күп бит! Атларын кызгандым... Аларны да тараткан булырлар иде.

Буада – балык, умартада бал кортлары тоту өчен уйланылган җир иде бу утар. Шул вакыт мине «Россиянең татар авыллары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы советы рәисе итеп сайладылар. Төрле авылларда йөри башладым. Яшел Үзәндә Исәк авылында Минедамир исемле егеттә кунакта булдым. Ул анда «Татар авылы» музеена нигез салган. Шул йортларны күреп, мин дә «котырып» кайттым. Бер-ике ел күңелдә йөрткәннән соң, төзи дә башладым...

Дөресен әйткәндә, утар төзү уе аңарчы да бар иде. Оныклар авылга кайткач, әкият сөйлисе урынга, элек болай иде, әби-бабаларыгыз шулай яшиләр иде дип сөйлим. Ә алар күз алдына китерә алмыйлар. Йөз кат сөйләгәнче, бер кат күрүең яхшырак, дибез бит. Эшкә бергәләп тотындык: предприятие эшчеләре, авылдашлар, ике олы оныгым – Динар белән Минтимер дә безгә кушылды. Балчык белән салам изеп, саман кирпеч ясыйбыз да, шулардан йорт күтәрәбез. Балчыклы читәннәрне дә малайлар үзләре ясады. Бу утарга оныкларымның кулы да керде шулай. Хәзер монда балалар килеп, ерак бабалары ничек яшәгән, ничек он тарткан, мичтә ризык пешергән, нинди

табак-савыт кулланган, нинди йортларда яшәгәнлеген күрә ала. Олыларның, йортларга кереп, күз яшьләрен тыя алмый елаган чаклары да була... Әти-әниле балачакка кайтып килгән кебек хис итәләр үзләрен. Аларга кушылып минем дә күзгә яшь килә.

Монда миллиардлар салынгандыр, диләр. Юк, экспонатларның күбесен үзебез җыйдык. Китереп тә бирәләр. 150 еллык тегерменне Чуашстаннан алып кайттык. Эшли торган тегермән әле ул. Осталар табып, көйләп җибәрәсе генә бар. Утар бизәге булып әллә кайдан күренеп тора ул хәзер. Тора-бара утарга башка төзелешләр өстәлде. Өч ел буе балалар өчен татар лагере оештырабыз монда. Агуландым инде бу эш белән... Хәзер менә спорт залы төзүгә керештек.



МӘХӘББӘТ Хатыным Тәнзилә белән танышып та тормадык. Бер сыйныфта укыдык чөнки. Армиягә киткәнче бераз озаткалаган булды инде анысы. Тәнзилә мәктәптә яхшы укый иде. Без иртән фермага барып кайткан кеше бит инде, өйдә дәрес карамыйбыз. Мәктәпкә иртәрәк – сигез тулганчы төшәбез. Яхшырак укучы кайсы классташ беренче килә, шуннан күчерергә сорыйбыз. Тәнзилә күчерттерми! Әллә шуннан ачу килеп калган, армиягә кадәр күз төшмәде дә кебек. Кайткач, онытылгандыр, күрәсең: очрашып йөри башладык... Хәзер кайтып уйласам, ничек килеп чыкканын да хәтерләмим. Мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңлата белмим. Күренә торган әйбер түгел ул. «Яратам, синнән дә яхшырак кеше юк», дип, төчеләнеп йөри торганнардан түгел мин. Үз гомеремдә бер-ике тапкыр гына әйткәнмендер мин ул сүзне. 47 ел бергә яшәп, ике балаң, биш оныгың булу, йортыңда матур итеп яшәү мәхәббәт түгелмени? Минем туганнар белән миңа караганда да якынрак мөнәсәбәттә Тәнзилә. Бу да мәхәббәтнең бер билгесе! Үз инәсен бик тәрбияләп соңгы юлга озатты. Минем инәкәйгә инсульт булгач, аны башта хастаханәдә карады, аннары өйдә тәрбияләде. Эшеннән йөгереп кайта иде.

Тәнзилә дә җырны бик ярата. Барган һәр җирдә табын түрендә утырдык без. Сәхнә кешесе булгач, минем хакта төрле сүзләр дә ишетергә туры килгәндер Тәнзиләгә. Башта без Фәрит Шәйхетдинов, Мәгариф Әхмәдиевләр белән концерт куеп йөрдек. Ул вакытта бер дә җибәрәсе килми иде. Ә менә Фән белән йөри башлагач, берни сиздергәне булмады. Башкортстанның Яңавыл районында Илдар абый Юзеевның юбилейларын өч атна буе уздырдык, һәр авыл саен йөрдек. Мамадышта җәй көне бер ай буе концерт куйдык. Эш вакыты бит! Тәнзилә каршы булса, шулкадәр йөреп кайта алмас идем. Киресенчә, мин үзем көнләшүчән кеше. Бәләкәйдән шундый. Сеңелләрем янына егетләрне капка төбенә китертми идем. Әтекәй дә, инәкәй дә түгел, мин контрольдә тоттым моны. Апайларга чалбар да киерттермәдем. «Сөрмәләр кулланырга кушмый идең, өйдән чыгып, синнән качып сөртәбез дә, кайтканда чистартып керәбез», – дип, сеңелләрем әле дә искә төшерә. Хатынга карата да шулай таләпчән мин, тәртип яратам.

Мин һәр эшне ерып барырга яратам. Тәнзилә белә моны. «Моны эшләп булмый», – ди ул. Ә миңа шул сүз җитә! Эшләп булганын исбатламыйча туктамыйм.



АКЧА Акча җыя белмим. «Син ыштансыз», – диләр. Ыштансыз булмаган кеше мондый әйбер төзиме инде ул? («Бабай утары» турында. – *авт.*) Ә мин төзим. Югыйсә миңа моннан бернинди табыш та керми, ә төзелеш үзе акча сорый. Акчаны саный белмим, кесәдә артыгын йөртмим. Кассага акча салганым юк хәтта. Булганны тиз таратам. Танышлардан: «Фәнирнең өен күрсәтегез әле, фотосы бармы?» – дип сорыйлар икән. Күргәч, ышанмыйлар ди. 1977 елда салган йортта яшибез әле дә. Кайтып аш бүлмәсендә ашасаң, залга кереп телевизор карасаң, йокы бүлмәсенә кереп ял итсәң, артыгы нигә кирәк?! Байлыкка кызыкмыйм да... Бер чалбарны атна-ун көн киеп йөри алам. Әйе, акча бүген өчен мөһим әйбер. Әмма аны җыюны кирәксенмим. Диңгезгә дә барганым юк дияр идем, 1988 елда «Москвич» машинасы алгач, балаларны утыртып бер барып кайттык. Австралиягә баргач океанда ике тапкыр су кердем, шуның белән шул. Әлбәттә, бу үземә, гаиләгә, тормышка кагылганда шулай. Оешма җитәкчесе буларак, бөтен финанс ягын үзем контрольдә тотам, юк-барга сарыф итмим.

Хәзер мин авылга, кешеләргә нәрсәдер эшләп калдырырга кызыгам. Бер начар гадәтем бар – кешене кызганам... Күңелемә тисә, бер белмәгән чит кешегә дә ярдәм кулы сузам... Ел саен балалар Сабан туе үтә бездә. Бүләкләр алам, батырга тәкә куям. Чын атлар булмаса да, таяк атка атланып ярыша балалар. Бүләк ясаудан, яхшылык эшләүдән күңелемә аңлатып булмаслык бер рәхәтлек иңә. Чын байлык малга бәйле түгел ул...



КУРКУ Курку дигән әйбер миндә бик юк, ахрысы. Зиратка керергә дә курыкмыйм, түрәләр сүзеннән дә курыкмыйм... Үз сүземне, фикеремне җиткерергә тырышам. Шулай булмаса, эшләп тә булмый. Үз тормышыбызны үзебез карый алгач, әтеки-инәкиләрне хөрмәт итеп, тәрбияләп соңгы юлга озата алгач, балаларны үстерә алгач, калганы – вак-төяк... Ә менә кешене рәнҗетүдән куркам. Эш буенча да кайчак тавыш күтәрергә, кычкырып эндәшергә туры килгәли. Элек бер дә сүгенми идем. Соңгы вакытта авыздан шундый сүзләр чыга башлаганын сиздем. Чама хисен югалтырга ярамый. Кешене кимсетүгә барып җитмәс өчен үземне тыеп калам.

Башка әйбердән курыкмыйм да кебек... Яшәргә кирәк! Яшәгәндә нәрсәдер эшләп калырга була. Гомер кыскара, әмма кыскарганга үкенмим, эшләнгән эшләр бар артта. Йорт төзелгән, агач утыртылган, балалар үскән. Ходай биргәнчә саулыкта яшәргә язсын. Дөньялар тыныч булсын!



«ИҢ БӘХЕТЛЕ КӨНЕМ...»

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Кайтканда миңа 5 яшь иде. Кыш иде... Гаиләнең нәрсә икәнен белми идем әле, ишеткәнем генә бар иде. Аннары аңладым... Әнинең кем икәнен дә белми идем. Хәзер беләм! Ул гаиләдә иң кирәкле кеше! Әни сиңа булыша, кәефең булмаганда килә дә: «Нәрсә булды, кызым?» – дип сорый.
Кайтканда татарча да белми идем. Балалар бакчасына йөри башлагач кына өйрәндем. Берсендә әни: «Кызым, миңа чынаяк алып кил әле», – дип сорады. Мин шунда: «Мә, әнием!» – дип илтеп бирдем... Приютта чак, йокларга ятканда тәрәзәгә карый идем дә гел: «Моннан тизрәк китәсе иде... Тизрәк китәсе иде!» – дип кабатлый идем. «Әти белән әни килсен иде дә, мине моннан алсын иде», – дип хыяллана идем. Аннары, авырып, больницага эләктем. Ангина иде минем. Шунда беренче тапкыр әти белән әни минем янга килделәр. Бик сөендем! «Алар сине үзләренә алачаклар», – дип алдан әйтеп куйганнар иде. Әниләр күчтәнәчләр калдырдылар: сок, печенье, кекс... Мин терелеп чыкканда, тагын килделәр. Яңа куртка, яңа башлык кидерделәр. Алсу апа белән Лиана апа миңа уенчыклар биреп җибәргәннәр иде... Өйгә кайткач, иң беренче Лилияне күрдем. Ул әниләр белән минем янга приютка да килгән иде. Без аның белән дуслар. Лилия әтине күбрәк ярата, мин әнине... Башта әнигә «мама» дип дәштем. Хәзер мин дә, апайларым да «әнием», дибез. Кечкенә апаема – Арсланга 8 генә яшь әле...













Риана белән икәү аның иң бәхетле көнен искә төшерәбез.

– Иң бәхетлесе – гаиләгә кайткан көнем! – дип тәмамлый ул сүзен. Аннан өстәп куя: – Конкурста җиңгән көн дә – иң бәхетле көн! Безнең өчен шундый көтелмәгән булды бит ул!

Әйе, аларда әле барысы да әлеге бәйге тәэсирендә: олысы да, кечесе дә. Сүзләр гел шул тирәдә әйләнә. Күптән түгел Чуашстанда ел саен уза торган «Идел буенның уңышлы гаиләсе» конкурсы тәмамланды. Аның финалында регионнардан 14 гаилә катнашты. Актаныш районы Киров авылында яшәүче Сабитовлар анда Татарстан данын яклап чыгыш ясады һәм өченче урынны яулады. Зур җиңү! Шулай булгач, нәкъ бәхет турында сөйләшә торган көннәр! Венера ханымга да мин иң элек шушы сорауны бирәм. «Балачактагы иң бәхетле бер көнегез турында сөйләгез әле», – дим.

– Яңа курчаклы булган көндер ул... Мин бик хыялланырга ярата идем. Алар чынбарлык булып тоелганчы хыялланам, ачык, якты төсләренә кадәр күрә идем. Ун курчагым бар иде минем. Әти шофер булгач, барган бер җиреннән алып кайта иде аларны. Ун курчагымның ун өе! Берсенеке – караваты, икенчесе – урындык астында, өченчесе – бер почмакта... Мин аларны балалар бакчасына илтәм, алып кайтам. Нәрсәгәдер өйрәтәм... Хәтта шырык-шырык көлгән тавышларын да ишетәм. Ә бүген бит тормышымда шулар кабатлана! Могҗиза кебек бу! Әкият кебек... Гаиләдә иң зур бәхет – бала!
Яшь чакта бала табасы килми инде ул, авыр, дибез. Ә бит һәрбер бала үз ризыгы белән туа... Шул темага киноларны үлеп ярата торган идем. Төп рольдә Наталья Гундарева уйнаган «Однажды двадцать лет спустя» фильмын хәтерлисездер. Ун бала әнисе Надежда Круглова классташлар очрашуына килә. Сабакташларының һәркайсы тормышта нәрсәгәдер ирешкән, ә ул гап-гади хуҗабикә – әни... Фильмда героиня үзенең туй күлмәген сүтеп, бер баласына Кар кызы күлмәге тегә. Төн чыкканчы! Мин дә боларның барысы аша уздым! Үз күлмәгемне кисеп, мин дә кызларның берсенә чыршы бәйрәменә костюм тектем. Һәм ул иң матуры булды! Әйе, ятим бала карасам, мин шулай эшләр идем, болай дип тә хыялландым... Ул чакта андый күренеш тә юк иде бит әле.

Ятим бала... 13 яшендә әнисез кала Венера. Авыр балачакның, ә аннан ятимлек ачысының ни икәнен дә аңа аңлатырга кирәкми... Гөрләп торган йортлары бушый: мал-туарны саталар, өч баланы әтиләренең абыйлары ала. Ә аларның үзләрендә дә алты бала. Абый белән җиңгәләре дә якын итә, билгеле – чит кешеләр түгел бит. Әмма...

– Әни сыер сава иде. Ул иртәнге җидедә эштән кайта да, алар әти белән кече якта сөйләшә-сөйләшә чәй эчәләр. Нәрсә хакында сөйләшкәннәре аңлашылмый, әмма

Кешедән ким-хур итәсем килми – аларга хәтта кара төсле кием дә кидертмәскә тырышам, андыйны алмыйм.

аларны тыңлап яту шундый рәхәт... Берсендә шул гөрелдәүгә уянып киттем. Йөгереп чыксам, Зөлфирә апа белән Шамил абый чәй эчәләр. Катып калдым. Әни дип талпынган идем бит... Ятимлегемне, мөгаен, шул көнне тулысынча аңлаганмындыр. Әни гел җитми! Мәктәптә узган бәйрәмнәрдә күзең белән гел аны эзлисең. Ул юк! Әмма күңелең белән аны барыбер бер почмакка утыртып куясың. Класста нинди начарлык эшләнсә дә, аны бик җиңел генә сиңа сылтарга мөмкиннәр – яклаучың юк... Ятим бала көчле булып үсә – аңа тормышта үз юлын табарга, үз-үзен якларга кирәк. Тезегезне беркайчан да чүкмәгез дип өйрәтәм шуңа күрә үземнекеләрне. Аларны бик бәхетле итәсем килә. Һәрберсен яратам!

Алмас белән Венерага бүген 13 бала әти-әни дип дәшә. Өчесе – үзләре табып-үстергәне. Калганнар... Алар да үзләренеке! Кәгазьдә генә башкача атап йөртелә. Иң беренчеләре – Алинә белән Руслан икесе дә Сабитовлар фамилиясендә: хөкүмәт каршында аларның улы һәм кызы дип санала. Гаиләгә 2 һәм 4 яшендә килгән балалардан моны күптән сер итеп сакламыйлар. Алинәгә ул серне балалар бакчасында төркемдәшләре үк «чишкән». Ә Руслан күп нәрсәне үзе дә хәтерли:

– Без монда машина белән кайттык. Машинадан төшү белән этне күрдем. Ак төстә, Тарас исемле. Этнең нәрсә икәнен дә белми идем әле... Миңа ул көнне пультлы машина бүләк иттеләр. Аннары әти белән әни безгә йомшак уенчыклар бүләк иттеләр. Үзебезнең беренче уенчыклар иде ул. Аларны бик озак сакладык – хәзер дә каядыр яталар. Иң бәхетле көн шушыдыр... Ә приютны хәтерләмим: аннан чыгып киткәнне һәм монда килгәнне генә беләм.

Тагын бер кечкенә бала тәрбиягә алабыз дип торганда, күрше авылда йортка кергән күрше егетенең хатыны үлеп китә. Игезәкләрен әтиләре үзенә алып кайта, ә беренче ирдән булган кызы кала. 13 яшьлек кызы. Венера ятим калган яшьтә... «Туганнарың да янәшәдә генә булыр, аралашып үсәрсез. Син зур кыз инде, үзе хәл ит», – ди аңа Венера. Бер атнадан Лиана: «Килеп алыгыз», – дип шалтырата... Мәктәптән соң ул техникумда укый, аннан университет тәмамлый. Фатир биргәннәр, Чаллыда яши. «Өйгә кайтам», – дип, Венера апасы белән Алмас абыйсы янына кайтып йөри.

«Бер бала ала башласаң, туктап булмый икән», – дип көлә Венера. Ул елны августта Лианалы булалар, ә ноябрьдә Казаннан сигез айлык Лилияне алып кайталар. Лилия инде тәмам өй баласы булып үсә.

– Өйдә һәм балалар йортында үскән балалар арасында җир белән күк аермасы. Йөзләп баланы бутап бастырсалар да, балалар йортындагыларын шунда ук таныйм. Максим менә кайткан мәлләрдә кочаклап алсаң, үзеннән этә иде. Кулга берничек ияләндереп булмый. Кыргый! «Баланы ничек куенга кертергә?» – дип, әллә никадәр психологларга яздым. «Яныннан үткән саен, аз гына, сизелер-сизелмәс кенә кагылыгыз», – дип җавап бирде берсе. Хәзер әнә үзе, «әнием», дип, кочаклап ала. Рәхәт! Гомумән, һәр баланы, аның холкын өйрәнеп бетерергә ким дигәндә ике ел кирәк...

Сибгатуллинар да, Бутаковлар да өчәү-өчәү килеп кушыла Сабитовларга. Һәм бөтенесе бер гаиләгә әйләнә! Бер-берсе өчен кыя булып баса торган гаиләгә. (Быел шундый хәл була: авыл клубында «Созвездие-Йолдызлык» фестивале узганда Артем алдарак, калганнар арттарак утыра. Кемдер шунда Артемны кыерсыта: моны күреп, Сабитовларның тәрбиягә алган калган җиде баласы шунда ук аның янына килеп баса. Укытучылар гаҗәпләнеп сөйлиләр, ә Венера сөенә: балаларының, димәк, тормышта таянырлык туганнары булачак.)

Гаиләне бер йодрыкка ничек туплап торырга соң? «Эш белән!» – ди Венера.

Аларның бакчалары тагын әллә ничә бакчага бүленгән: Индира белән Лилиянеке, Артем белән Альфредныкы, Риянаныкы, Алинәнеке. Яшелчәне, чәчәкләрне утыртуын әниләре белән бергә утыртсалар да, калганына үзләре җаваплы: суын сибәләр, чүпләрен утыйлар.

Абзар тулы мал-туар: сыер, тана, бозау, сарыклар, тавыклар... Кайсының алдына нәрсә саласы, кайчан саласы – беркемгә бернәрсә дә өйрәтәсе, исенә төшерәсе юк, беләләр.

Өйне кем җыярга, идәнне кем юарга, кухняда кайсы көнне кем җаваплы икәне дә бер атна алдан билгеле: кемдер пешереп алга китереп куйганны гына көтмиләр. («Безнең Индира тортларны бик тәмле пешерә. Чәкчәк тә ясый беләбез – әни өйрәтте. Камыр да куябыз, токмач та басабыз. Элек әниләрнең рецептлар яза торган аерым блокнотлары булган. Минем дә бар шундый блокнотым. Төрле печенье, торт рецептлары җыям», – ди Риана.)

Малайлар күбрәк, әлбәттә, әтиләре янында бөтерелә. Бигрәк тә – Максим. Машиналар ремонтлау белән шөгыльләнүче Алмасның ул инде күптән уң кулы: аңа нинди корал кирәк – һәрберсен алып биреп тора. Машина тәгәрмәчен инде үзе сүтеп җыя белә! Иске техниканы сүтеп, әтисе белән бергә беренче квадроциклын җыйган. Вертолет, самолет җыю турында хыяллана! («Ир-ат башкача бит ул... Кеше баласын ярата алырмы дип борчылдым. Әкренләп өйрәттем: йә балаларның берсен алдына утыртып куям, йә тотып тор, йә башына кигез әле, дим... Безнең балалар өчен иң әйбәт әти – ул. Алмас бер төчкерсә, тугыз яктан тугызы: «Әтием, сәламәт бул!» – дип кабатлый. Өйне күтәрәләр дип көләм».)

– Үзебезнекеләргә бу кадәр игътибар эләкмәде, – ди Венера. – Мин ул чакта сыер саудым, этиләре комбайнер иде. Балаларның ни белән яшәвен белергә теләсәң, гел яннарында булырга кирәк икән... Монда җаваплылык тагын да зуррак. «Теге кайткан балалар» димәсеннәр. Кыңгыраулылар, дим алар турында – аз гына кыек эшләре булса да еракка ишетелә. Чын кеше итәсем килә һәрберсен!

Ул гел алар белән! Тау шуарга әниләре балалар белән бергә йөри: һәрберсенең чаңгысы бар. Чаңгыга басарга теләмәгән кечкенә Арсланны бау белән аркасына аса ул. Тимераякта да шулай чыгалар. Балык тотарга яратмый Венера, әмма барыбер бара. Видеога төшереп кайту өчен хәтта кыш көне дә алардан калмый. Ә балалар этиләре белән балыкка барырга кыш көне чират торалар!

Сабитовлар урманнан кайтып керми: әле гөмбә, әле дару үләннәре җыярга чыгып китәләр («Үләннәрне инде үзләре белеп җыя. Без гел үлән чәйләре генә эчәбез. Шуңа авырганнары юк та минекеләрнең – больница, даруханә юлында йөрмибез».), әле имән чикләвеге җыеп тапшырырга, әле питомникта чүп утарга... Әниләре мотоблок руле артына утыра, аның әрҗәсенә ашарга төйиләр, Арслан да шунда урнаша, калганнар велосипедта арттан ияреә...

– Алар яшендәге бала-чага компьютердан, телефоннан аерыла алмый. Ә бездә тәртипләр кырыс: кесә телефонын аларга 14 яшь тулгач кына алабыз. Әйе, классларында безнекеләрнең генә юк... Аның каравы, алар башка нәрсәне – кирәгрәген үз күзләре белән күрә: үләннәр шытканын, бөреләр ачылганын, гөлләр чәчәк атканын... Руслан кайтканда 4 яшьлек иде. Кар яуганын күреп: «Һавадан нәрсә төшә бу?» – дип шаккаттырды. Белмәгән... Аларга күп нәрсәне аңлатырга, күрсәтергә туры килә – интернетта утырырга вакыт юк безнең...

Әйе, мавыгулары башка Сабитовларның. Алар ялгыз әбиләргә булышырга йөриләр. Намаз укыйлар. Чәчү чәчүчеләр, комбайнерлар янына барып, концертлар куеп кайталар. (Үзләре теләп!) Бәйрәмнәрдә үз куллары белән кечкенә бүләкләр ясыйлар да, урамда очраган һәркемгә шуларны бүләк итәләр. («Елмай» дип язылган йөрәк рәсемен күкрәгенә беркетеп куйгач, кем елмаймас!) Елга бер тапкыр бөтен Актаныш чишмәләрен йөреп чыгалар – суларын авыз итәләр. Кая килеп туктасалар да, иң элек ул тирәне җыештыралар: нинди генә походка чыксалар да иң элек чүпкә дип пакет алалар. Алар «Африкада сусыз тилмерүчеләр», «Альбиносларга ярдәм итү» фондларына акча күчерәләр. Әниләре аларны: «Үзегез башкаларга күпме бирәсез, күпме игелек кыласыз – шуның кадәр кире әйләнеп кайтыр», – дип өйрәтә. «Дөньяны үзгәртергә телисез икән – үзегездән башлагыз», – ди.

Алар җай чыккан саен «этләр приюты»на барып кайталар. («Ул көнне безнең Лилиядән дә бәхетле кеше булмый инде!») «Көмеш кыңгырау» газетасын, «Ялкын», «Салават күпере» журналларын укыйлар. Алар һәр көнне кич йоклар алдыннан әниләре белән бергә урам әйләнә. Һәр шимбәне гаилә җыелышы үткәрәләр: бөтен проблеманы уртага салып сөйләшәләр. «Әйтер сүзем бар» дигән банкага теләк-үтенечләрен, мөрәҗәгатьләрен, хыялларын язып салалар. Алар хәтта әләкләшә дә ала. (Приюттан, балалар йортыннан ияреп кайткан ул гадәттән тиз генә аерылып булмый шул... Ә әниләре андый чакта көзге каршына утырта һәм: «Әнә андагы кеше белән сөйләш әле: сиңа нәрсә өчен әләкте икән?» – ди.) Алар гел нинди дә булса бәрәр бәйгегә әзерләнәләр һәм җиңәләр! Әниләре төшергән видеороликларның төп геройлары да алар. Кировтан 50 чакрым ераклыктагы Такталачык авылында урнашкан коррекцион интернат-мәктәптә укучы Арсланны һәр җомга кичендә көтеп алалар һәм дүшәмбегә кадәр кочактан чыгармыйлар. Алар Актанышның үзенә – Алсу апаларына кунакка барырга яраталар. Ә Азат абыйлары кайтуы алар өчен, гомумән, бәйрәмгә әйләнә.

Һәр иртәне алар: «Хәерле иртә, әнием!», «Хәерле иртә, этием!» – дип башлыйлар, «Тыныч йокы!» – дип тәмамлыйлар. «Әнием», «этием», диләр...

– Күрәсездер, ишегалды тулы песи. Аксагы да бар, сукыры да... Берара уникегә җыелдылар. «Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәне юлыбызга безне сынар өчен чыгара», – дип аңлатканым булды балаларга. Урамдагы хуҗасыз бер песи яныннан да узып китмиләр хәзер. «Әнием, син үзең әйттең... Бәлки Аллаһы Тәгалә аны безгә сынау итеп җибәргәндер», – диләр. Кайчак миннән яшерә-яшерә алып кайтып карыйлар... Әйе, һәр сүзең күңелләре түренә кереп урнаша. Әйткәнемчә, җаваплылык бик зур. Әмма яңадан башлыйсы булса, мин бу эшкә тагын да иртәрәк тотынып идем. Быел менә Руслан китә, киләсе елга Индира белән Алинә, аннан Максим... Без инде өйдәге тынлыкка ияләшә алмыйбыз хәзер...

Күрше Сәфәр авылындагы бер чишмәгә еш йөриләр алар. Ул чишмә янына ике нарат та утыртканнар: берсе – әниләре, икенчесе – этиләре. Һәм сүз биргәннәр: киләчәктә берберсен беркайчан онытмаячаклар, һәр елны Яңа елга шушында җыелачаклар. Эти белән әниләрен, алар янында уздырган елларны искә төшерәчәкләр... Һәр очрашудан әниләре кебек видео ясаячаклар...

Ә иң бәхетле көн... Ул әлегә бөтенесенең дә бертөслерәк.

– Исемем Индира. Килгәндә 9 яшь иде, хәзер – 15. Иң бәхетле көнем шул булгандыр... Мине Түбән Камадан килеп алдылар. Детдом дигән җирдән. Артем, Максим бергә кайттык. Детдомда күңелсез иде, чөнки анда әни юк иде...

– Мин – Максим. Приютта үзеңне ялгыз итеп хис итәсең. Туганнар белән анда төрлебезне төрле группаларга таратканнар иде. Аннары эти белән әни килеп алдылар. Бәхетле көн иде ул... Без кайтканда өйдән бөтенесе чыгып каршы алдылар. Без «әнием» дип дәшкәч, әнинең үзенә дә рәхәт...

Фото: Анна Арахамия



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. »



Энҗе ХӨСӘЕНОВА

Энҗе – Әтнә районы Бахтачы авылы кызы. Әтисенең – урманчы, әнисенең укытучы булуы да, Сибгат Хәким исемендәге Күлле Киме мәктәбендә укуы да, Фатих Әмирхан, Әмирхан Еники, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә үсүе дә Энҗене туган тел, әдәбият, шигърият дөньясына әзерләгәндер. Туган як табигатен, авылын, туган телен яраткан кыз КФУның татар теле бүлегендә укып, тирәнтен татар һәм кытай телләрен үзләштереп чыга. Үзе белән: «Мин – иҗатка гашыйк гади бер авыл баласы!» – дип таныштыра һәрчак. Шигырьләреннән исә ихласлык, яктылык, мәхәббәт бөркелә.

КЕРФЕК ЧЫЛАНГАН МӘЛ

Мин кияүгә чыгам...

Мин кияүгә чыгам.
Ә янымда һич син түгел,
башка берәү, бөтенләй чит.
Әллә каян колагыма тавыш керә:
«Юләрләнмә! Ташла да кит!»

Бу әрнүдән тилерердәй булам...
Күңелемдә уйлар икеләнә...
Саф сөюем өчен газап белән
җавап бирер көнем җитте мәллә?!.

«Ташла да кит...» Шулай җиңелмени...
Ярату юк, ансын яшермим...
Мин генәме? Җирдә бик күп парлар
яратусыз гына яши бит...

Ә син кайда?.. Бар йөрәгем биреп
гомер буе сөям дигән кешем?!.
Үз сөйгәнен җиде ятка биргән
бармы икән тагын синең ише?..

Туй күлмәгем буйлап «ярам ага»...
Шул ят берәү суза балдагын...
Карулашам... һәм кабатлыйм мең кат:
«Үзем теләп аңа бармадым!»

Артка юл юк... күңәм...
язмыш шулдыр...
Тау ишелә минем өстемә...
Һәм... кинәттән җиңел сулап куям:
өнем түгел икән, төш кенә!..

* * *

Сагынмыйм, дисәм дә, сагынам.
Син һаман күңелнең түрендә.
Һәр көнне, һәр төнне, һәр төштә
югалмас яктылык күренә.

Казансуда гел парлылар эзе...
Тик минеке генә ялгызак.
Синсез көннәрем дә айларга тиң...
гомер ахырына бик озак.

Бүген менә керфек чыланган мәл...
күрмәсәм дә үзең... син елмай...
Күтәрелеп күккә кара... сүзсез...
күзен кыса безгә тулган ай...

Уйлар ташый кабат... чиге дә юк...
күңел тулы сиңа әйтер сүз...
Чытырдатып күзләремне йомам:
«Син сыгылма, йөрәк! Зинһар, түз!..

* * *

Бу шигырем укуыңны телим
(язып салыр идем,
килсә көчемнән...).
Беләм, синең күзләр
һаман (минеке дә!)
кабатланмас сөю төсендә.

Бу арада күңел сине сорый
(оныткандыр инде дигән идем...).
Исеңдәме, соңгы күрешүдә
алсу төсле күлмәк кигән идем.

Мин ул кичне оныталмам төсле
(искә төшерүгә – күзләрдә яшь...).
Шалтырат та бер елмаю өстә:
«Мин дә синең хәлдә!..» – дип дәш...

Казансуның язгы суын
тагын бер кат өскә сибим.
Беләсеңме, ихлас ярату да
юләрлек тә безне бизи.

Минем истә (сине белмим...)
ул кичтәге һәрбер мизгел.
Оныткандыр дигән идем...
кабат сине эзли күңел...

* * *

Иң авыр, газаплы мизгелдә
ник нәкъ син төшәсең исемә?..
Күңелгә үелгән салкыннан
тетрәнеп урталай киселәм.

Туктамый уйларым ташыса,
түзалмый, мин җитсәм чигенә...
Гел синең тавышың ишетәм:
«Ялгыш та бер адым чигенмә!»

Ялгызлык җәйгәндә колачын,
саташсам төннәрен төшемдә,
күз ачып йомуга шунда ук
нәкъ синең күзләрең күренә.

Син – бер көч, аяктан екмаган
(һичкайчан!) көчле җил исүгә.
Әйт әле, иң авыр чагыңда
нәкъ үзем төшәмме исеңә?..



Татар теле һәм рус теле буенча олимпиадаларда район күләмендә беренче урыннарны яулап килгән Дания мәктәп елларыннан ук шигырьләр дә яза. Алар республика матбугатында басылып килә. Вазыйх Фатыйхов, Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ кебек шагыйрьләр Югары Тегермәнлек кызы иҗатына хәер-фатыйхаларын бирәләр. Казан сәүдә-икътисад техникумын һәм Казан кооперация институтын тәмамлый ул. «Идел» яшьләр үзәгендә яшьләр эшләре буенча белгеч, «Шәһри Казан» редакциясендә журналист булып эшли. «Иделем акчарлагы» конкурсында Гран-прига лаек була. Идел–Урал төбәге студентларының «Шигъри Сабантуй» конкурсында «Сабантуй батыры» исемен яулый. «Галәм агачының яфрагы мин» шигырьләр җыентыгы, хәрабәләр астында калган блогер Рөстәм Нәбиев тормышына багышланган «Бөртекләп җыелган гомер» китабы авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Дания НӘГЫЙМ

КАРАШЫҢ – СӨЮДӘН ТӨНӘТМӘ

Мин бары хыялың синең

Мин – хыялың синең!..
Сагынганда,
Күзләреңә сагыш булырмын.
Рифат Сәлах

Мин бары хыялың синең,
Чынбарлык – ялган кыйссам.
Мин үләрмен күбәләктәй,
Учларыңны син кыссаң.

Мин – йолдызлар җыелмасы,
Күзләреңне өтүче.
Мин төшләрнең үзе булам,
Син – өнеңнән өркүче.

Мин рәшәдәй якын сиңа
Һәм рәшәдәй еракмын.
Мин кояштай көләч йөзле
Һәм болыттай елакмын.

Мин мәдхияң иясемен,
Җырларыңның моңымын.
Куллар түгел, хыялларың
Үрә минем толымым.

Чык тамчысы мин идем ул
Син сусаудан көйгәндә.
Эчәргә тик базмадың син
Өзелеп-өзелеп сөйгәнгә.

Мин бары хыялың синең,
Чынбарлык – тирән яраң.
Җиргә яшең коелганда
Галәмгә аша барам.

Мин язларда калам

Язлар белән тулы күңелемә
Кыш өймәкче була көртләрен.
Дуласа да, янаса да буран,
Ишегемне ачып кертмәдем.

Мин язлардан челтәр үреп элдем,
Тәрәзәмнән кошлар көнләшсен!
Мин язларны җырым итеп оттым –
Бәхет миңа сөеп эндәшсен.

Мин язларда туган – язда калам,
Җиләк исе җанга тулса да.
Мин кояшны җаннан җибәрмәдем,
Көзләр килеп, көннәр уңса да.

Мин язлардан сөю эзләп таптым,
Ташуларга салдым сагышым.
Язгы кояш – игезәгем белән
Хәятемнән атлап барышым.

Син бербөтен кирәк миңа

Син тоташ ялкыннан, ахры –
Сулышларың көйдерә.
Син сандугач җыры, ахры –
Йөрәгемдә көй генә.

Син фәрештә догасыдыр
Күкләрдән пышылдаган.
Син җәйләрнең үзе, ахры –
Үткәндә кышым калган.

Син тылсымчы, сихерчедер,
Мин исерәм әфсеннән.
Син бербөтен кирәк миңа!..
Читенсенмим нәфсемнән.

Син минем татлы ширбәтем,
Җәннәттән агызылган.
Соңгы тамчы каным да син,
Йөрәктән тамызылган.

Йолдызга әйләним

Күкләргә коела күз яшем,
Галәмгә юл ала боз булып.
Киек каз юлына ымсынам,
Яшимен йолдызга кызыгып.

Йолдыздай балкысам төннәрен,
Карашың төбәлер мизгелгә.
Карашың – сөюдән төнәтмә,
Исерткеч, дәвалы, изге дә...

Йолдызга әйләнсәм әгәр дә,
Тәрәзәң булыр иң яктысы...
Августта йолдызлар яңгыры
Сиңа дип аталган, ахрысы.

Төннәрнең карасы йогалмас
Йөрәккә яшергән хисләргә.
Йолдызга әйләним. Очрашсын
Карашлар ягымлы кичләрдә.





Гөл МИРҺАДИ

Гөл Мирһади. Гөлнара Шәймөхәммәтованың әдәби тәхәллүсе ул. 1971 елда Башкортстанның Балтач районы Түбән Карыш авылында туган. Мәктәпне көмеш медальгә тәмамлап, Башкорт дәүләт педагогика институтында укыган, туган мәктәбендә башлангыч сыйныфлар укытучысы булып эшләгән. Мәгариф отличнигы. «Балтач таңнары» газетасында – журналист, район хакимиятенең мәдәният бүлегендә – җитәкче, Балалар йортында – патронат тәрбияче, мәдәният сараенда – директор, мөмкинлекләре чикле балалар һәм үсмерләр өчен тернәкләндерү үзәге җитәкчесе, популяр язучы. Ул үзе исә «мин тәрбияче» дияргә ярата.

Дүрт балага гомер бүләк итеп, язмыш кыерсыткан тагын тугыз баланы ире Филүс белән үзләренә сыендырып, гаилә, тәрбия, иҗат дөньясында янып яши. Укучылар аны «Килмешәк», «Чүплек иләндә», «Куян күчтәнәче», «Адашкан сер», «Иманнәр көче» повестьлары аша беләләр, һәр язган әсәрен көтеп алалар.

НӘНӘЙ ДОГАСЫ

(Хикәя)

Әниемнең әнисе – минем нәнәем ялгызы яши иде. Авылның үзәк урамында, мәктәп каршында бик бәләкәй дүртпочмаклы йорт. Ул аны үзе салган. Мунчасы да, абзары да юк. Чишмә буена түбән таба төшә торган бәрәңге бакчасы гына бар. Нәнәйнең иң зур куанычы: минем әтки (мин шулай «әтки», «әнки» дип сөйләшәм) – нәнәйнең бердәнбер кияве ясап куйган олы капка. Дөресен генә әйткәндә, ул нәнәйгә кирәкми дә: арба-арба печәннәр кайтарасы юк бит. Ел әйләнәсенә аның бердәнбер кирәге – утын китереп, шуны кисеп ярдырасы гына бар. Утынны, зур капкадан кертеп, ямь-яшел чирәмгә бушаталар. Яллап ярдыра. Тупыллар үскән бакчаның буеннан-буена тезеп өеп куябыз. Беткәнче ягылмаса да, утын ел саен өстәлеп торырга тиеш. Нәнәй кышны ничек чыгармын дип көенмәсен өчен. Әрдәнәнең бер очы чери башлаган. Утын алган саен кызыл бөҗәкләр йөгерешә. Яратмыйм шуларны! «Черек кортлары»ның аркаларына кара белән күзләр «ясалган». Гел бертөрле карашлары куркытып җибәрә. Ә нәнәйнең иң курыкканы – шул бакчадагы тупыл агачы. «Аның эче куыш. Яшен яшьнәгәндә, авып, ызбамны гына харап итмәсә ярар иде», – дип хафалана ул. Аннары, авыр сулап: «Әтәңнең вакыты юк шул», – дип өсти. Бердәнбер киявенә ул беркайчан да сүз тидертми, бик хөрмәт итә, горурлана аның белән. Әтки – авыл советы рәисе. Халыкның бөтен аһ-зары аңа төбәлгән. Урамнан узганда, туктап, нәнәйгә сүз сөйләүчеләр дә аз түгел. Нәнәй аларны яратмый, әткине яклап кабына да китә. Беләм, яңа капка алдындагы эскәмиягә утырырга шуның өчен чыкмый ул. Мин анда икәүләп утырырга бик яратам, нәнәйне чыгарга кыстыйм. «Син яшьсең, өшемисең, ә минем аркама киртә ярыгыннан җил өрә», – ди ул. Баштарак тактасы тактага терәп эшләнгән киртәнең кайсы төшеннән җил үтәргә мөмкин дип аптырый идем. Хәзер эндәшмим. Урамнан гел яхшы күңелле кешеләр генә үтми бит. Гайбәтчеләрнең барысының да кушаматы бар. Һич тә булмаса, әллә кайчан үлгән иренең исемен булса да кушып әйтә нәнәй. «Ревматизлы» аякларында йөри алмый, эскәмиядә дә чак кына утырган нәнәйнең алдына басып, ләчтит саталар. Нәнәй, туктатып, кереп китмәсә, кичкә кадәр дә кузгалмыйлар. Ә әйбәт кешеләр гел каядыр ашыга: нәнәйгә кычкырып сәлам биреп кенә узып китәләр. «Юлның теге ягыннан ишетелерлек булсын!» – дип, нәнәй мине дә кешеләр белән кычкырып исәнләшергә өйрәтте.

Мин нәнәй белән кунакка барырга ярытам. Кунак дигәнең шул урамнан ерак китми инде ул. Урам очында торган ялгыз апага йомырка алырга барабыз. Озак барабыз, озак кайтабыз. Нәнәй киртәләргә тотынып, эскәмияләрдә ял итә-итә атлый. Алдына – биш чыгып, артына биш узып, тирәли сикергәләп арып бетәм. Ул апа телсез, нәнәй аның белән ишаралап сөйләшә. «Бер дистә йомырка кирәк иде», – ди дә нәнәй ун бармагын күрсәтә. Йомыркаларны базында саклый Телсез. Сөйләшә алмагач, ниндидер куркыныч сере бар кебек аның. Мин анда нәнәйсез барырга шүрлим. Ераграклардан тагын бер ялгыз

әби бар. Аның балалары булмаган, нәнәйнең бертуган абыйсының хатыны ул. Аңа шомырт оны алырга барабыз. Кайтканда, нәнәйгә бигрәк тә авыр, түбән таба атларга кирәк. Кайтып җиткәч, чәй куябыз. Шомырт онын су белән бутыйбыз. Тәмлелеге! Хуш исе! Нәнәй, чәйнектәге су кайнап чыккач, тиз генә электрдан өзмәскә куша. «Озак кайнаса, тәмлерәк була чәй», – ди. Аннары өй алдында үскән карагат куагыннан яфрак алып керергә чыгарып җибәрә.

Якынга кунакка еш барабыз: күршеләр күп. Алар үзләре дә еш керә. Бер өй аша торган Фатыйма әби саңгырау, күп сөйләшми. Барыбер кереп чыгабыз. Хәл белеп. Мин аның ят фамилияле авыру оныгы белән уйныйм. Роберт бик ачык күңелле, гел елмаеп тора. Буе бәләкәй аның, үсми кебек. Аның әнисе бик чибәр. Ят халыкка кияүгә чыгып торган дип ычкындырган иде нәнәй бер тапкыр. Бик шәпләнгән чакта, Фатыйма әбиләрнең аяк очында гына яшәгән Сания апага да баргалыйбыз. Ул бик ачык инде, рәхәтләнеп сөйләшә. Гөлләре чәчәк атып утырган тәрәзәләреннән елга, чишмә буйлары күренә. Нәнәйләр сөйләшкән арада, мин шуннан карап торырга яратам.

Фатыйма әбиләрне узып, Фәһимә әби бар. Ул балалары белән яши. Аларда тыныч түгел, өй эче шаулап тора. Фәһимә әби үзе дә һич тик тормый: пешерә, кемнедер тирги, мактый, йөгерә. Ярып пешергән бәрәңгесе ашап туйгысыз. «Ярмалы аның бәрәңгесе», – ди нәнәй. Аннан соң чишмәгә суга төшә торган тыкрык аша Җәннәт әбиләр тора. Аның бабае бар, бик җитди, йортта гел нәрсәдер эшләп кенә йөри. Аларның өе дә биегрәк, яшел төскә буялган. «Дөньялары җитеш», – ди нәнәй. Җәннәт әбинең үзен бик яратсак та, бабае ачуланыр дип, куркып, озак җәелеп утырмыйбыз, йомышны йомышлыйбыз да ары китәбез. Тәскирә әбиләргә. Бердәнбер кызының балалары белән мәш килә ул. Кулыннан бәйләме төшми. Энәләренә күз иярми. Кайчакта дөньямны онытып, авызымны ачып Тәскирә әбинең тиз-тиз йөргән куллары астыннан озынайган оекбашына карап катам. Ул үзе туктаусыз сөйли, үзе бәйли. Бер ялгышмый. Тәскирә әби үзе усал да түгел кебек. Нигәдер телендә, йөзендә ачу күп. Бер чәчә башласа, өйдән чыгып качасы килә. Нәнәй барыбер бара. «Нужаны күп күрдек Тәскирә белән», – ди.

«Нужа» дигәне авырлык була, беләм. Күргән нужалары турында әбиләр кич утырганда сөйли. Ачлык заманында күрше Начар авылында хәер сорашып йөргәннәрен искә ала башласалар, әкият тыңлаган кебек, оеп, арып йоклап китәм.

Юл аша кыйгач каршы яшәгән Әкълимә апага еш керәбез. Ул да ялгыз. Әй сабыр да апа. Мин аның тик утырып торганын күргәнем юк. Эшли дә эшли. Өстендәге кара-көрән күлмәге белән шундый ук төстәге кофтасын алыштырганы бар микән? Әкълимә апа гади пыяла банкага акча җыя да базына күмеп куя. Минем үз күзем белән күргәнем бар. Ни өчен җыядыр инде? Акчасын тотып беркая бармый, бер матур әйбер сатып алмый. Бервакыт шәфкать туташы булып эшкә килгән ике яшь кыз Әкълимә апага фатирга урнашты. Күңелле булды бу минем өчен. Нәнәй янында бертөрле үткән көннәремә үзгәреш керде. Юк, мин алар янында чуалып, бимазалап йөрмәдем. Күзәттем генә. Алар озак тормады, авылның иң чибәр, булдыклы егетләрен, нәнәй әйтмешли, «эләктереп», бер-бер артлы кияүгә чыктылар.

Бервакыт нәнәй шул кызларның берсе – Гадилә апага кергән дә: «Бу баланың берәр нәрсәсе җитми микән, гел чи суган ашый?» – дигән. Башлы суганны әрчеп, әпи (бездә шулай сөйләшәләр) белән ашарга яратам шул, аннан чүмеч белән салкын су эчеп куям. Нәнәй курка, бу кадәр күп итеп суган ашау зыянлыдыр, ди. Гадилә апа күп уйлап тормаган: «Ашасын, башлы булыр кызың», – дигән. Шуннан нәнәй кешеләргә минем турыда «башлы бала бу», дип сөйли торган булып китте. Бераздан бу сүзләргә үзем дә ышана башладым, ахры. Әйбәтрәк укырга тырыштым, китапханәгә баруны ешайттым. Ләкин нәнәй минем китапханәгә барганымны яратмый. Көнен ничек уздырырга белми мине көтеп ала. Гел тәрәзәдән карап утыра, ахры, чөнки капкадан кайчан гына килеп керсәм дә, күз карашы миндә була. Әй шатлана инде шул вакытта! Бер генә тешле авызын зур ачып көлеп җибәргәндә, аннан да матур кеше юктыр кебек тоела миңа. Ул бит көннәр буе бары тик мине, мине генә көтеп тора!

Нәнәйгә аена бер тапкыр пенсия китерәләр. Ул укый-яза белми. Имза урынына кайчакта, карага манып, бармак очын баса. Почтальонка ашыкмаганда, озак итеп кәкре-бөкре хәрефләр белән «Зәйтүнә» дип яза. Исеме шундый матур аның! 28 сум акчасына бик куана нәнәй. Сөйләве буенча, гомере буена калхуз эшеннән башы чыкмаган: ашлыгын да урган, печәнен дә чапкан, плугарь да булган, тавык фермасында да эшләгән. Бу кадәр эшкә карата акчасы азрак булуын бәләкәй булсам да, чамалыйм. Аякларына «ревматиз» булуын мин башта шул «калхуз эше»ннән күрә идем. Сәбәбе башка икән. Нәнәй бер кызган чагында сөйләп ташлады. Яшь вакытында ул бик усал булган. Гаиләдә әллә сигез, әллә тугыз бала булганнар. Начар яшәмәгәннәрдер: аның әтисе Әбрар, әнисе Фәхерниса сыерларын саугач, артык калган сөтне бер зур гына савытка салып, янына кружкасын куеп, йорт алларында калдыра торган булганнар. Фәкыйрь кешеләр тамак ялгасын өчен. Моны нәнәй түгел, аның белән бергә яшьлекләрен искә алган әбиләр сөйли. Соңыннан ниләр булганын аңлатмыйлар, нәнәйнең өенә карасаң, гел бай булмаганнары күренеп тора бит инде. Сугыш башлангач, ашарларына булмаганлыгын беләм. Нәнәй басудан урлаган (урлаган да түгел инде, ачка түзәлмәгәч алган) бер уч бодай өчен абыйсы Кадимне сугышка, туп-туры штрафбатка алып киткәннәр. Сеңлесенең гаебен үз өстенә алган ул. Штрафной батальонда хезмәт итүчеләрне фронтның иң ачы сызыгына, передовойга «бәргәннәр». Ул хәбәрсез югалган, кайта алмаган. Бервакыт, тагын шулай ачлыктан колхоз мөлкәтенә кул сузды микән инде, нәнәйне район үзәгенә алып киткәннәр. 25 чакрым ара, ди. «Кыш башы. Җир бозланып туңган. Мине җәяү атлата әнә теге хәшәрәт, үзе – ат башында. Камчы белән аркама сугып, куалап бара. Бәдрәфкә туктатырга сорыйм. Рөхсәт итми. Чыдап буламыни, өшегәч... Шунда гына бозланып катты аякларым. Шунда гына чир эләктердем», – дип, әрнеп-әрнеп сөйли нәнәй. «Әнә теге хәшәрәт» тә безнең белән бер урамда яши. Аның өе турысыннан төкереп үтә нәнәй. Нәнәйнең аяклары бөгелми, каткан. Чүгәли алмый интеккән чакларында, сызлавына түзә алмаганда, ул тубык башларын йодрыгы белән тукмый... Кайчакта, икәү генә булган караңгы төннәрдә чирләп уяна. Йөрәге ябыша. Даруын салып эчерә беләм мин. Тик дарудан соң аны бәд-



рәфкә – тимер бидрәгә утыртуы, кирегә кузгатып, сиртмәле караватка алып салуы бигрәк авыр. Көчәнеп хәлем бетә. Миңа әле 9 гына яшь бит. Андый чаклар турында әнкигә сөйләмибез: нәнәйнең бердәнбер кызын борчыйсы килмидер, мине кунарга мендермәсләр (нәнәй авылның югары очында тора) дип куркам.

Һәр кичне, йокларга яткач, нәнәй бер теләк тели. Бер көн дә калмый. Башта дога укый: «Әлпи, диси, җәмгый, әхәт, алдал, рәҗи, шәмсам, бикуф, каплам, миңнум ам алфия». Бер сүзен дә аңламыйм. Араларында кеше исемнәре барлыгын гына беләм. Нәнәй мине дә ятлата. Ни ишетсәм, шуны истә калдырдым. Гомер буе оныта торган түгел. Көн дә сөйләтә. Азагында һәр көнне: «Аллакаем, кеше кулына калдырма. Баламны интектермәсәм ярар иде. Өч көннән артык яткырма мине», – дип өсти. Нәнәй йоклап китә. Ә мин аның пульсын тотам да нәнәй үлмәсә ярар иде дип теләп ятам. Аннары, ул үлгәч нәрсә буласын күз алдыма китереп, үземне үзем жәлләп елый башлыйм. Нәнәй үлсә, миңа әнкиләр торган йортка кайтырга кирәк булачак. Миңа анда кыен. Ике атнага бер тапкыр әтки безне мунча керергә менеп ала. «Малыш» кушаматлы «силсәвит аты» – дуамал холыклы күк айгырның чанасына утырып өлгерүе бик авыр, чаптырып алып китә. Карлы юлда чана әле бер, әле икенче якка салулый – тотынып кына өлгер. Мин Малыш белән җилдереп йөрергә яратам. Чанага сикереп менеп утыру да, сикереп төшеп калу да берни тормый. Нәнәй янында әтки гел көләч йөзле. Аның шундый чагында бергәләп ат чанасында кышкы юлдан җилдерүе рәхәт, сүз дә юк. Ә менә өйләрендә кыен. Нәнәй белән икәү, төн йокламыйча, кайчан үзебезгә кайтабыз дип уйлап, уфылдап ятабыз.

...Мин йокламыйм. Кулым – нәнәйнең пульсында. Күзем – тәрәзәдә. Кыска ак пәрдәне тартып куйдым. Күктәге айның якты йөзе миңа карый кебек. Тәрәзәнең пыяласы бер катлы гына, аның да чәнти бармак сыярлык ярыгы бар. Аны боз каплаган. Нәнәйнең бәләкәй генә өе барыбер җып-җылы. «Май кебек ызбам», – ди ул. Әткиләрнең өе зур. Суык. Нигәдер караңгы булып тоела...

Кибеткә баруым турында сөйләп бетермәдем бит әле. Нәнәй өч әйберне нык ярата. Карбыз, «Завтрак туриста» консервасы һәм кукуруз таякчыклары. Карбыз, билгеле, җәй генә кайта «лавкага» (нәнәй сүзе бу). Консерваны алып кайткач та әпиләп «бөгеп» куябыз. Әпине нәнәй үзе сала. Бик ялынсам, мине дә өйрәтә: «...бер чүмеч җылымса су сал, бер калак тоз, он, хәзер тугла әйбәт итеп», – дип сөйләп тора. Кичтән шулай әпи изеп куябыз. Иртән торгач, камырны нәнәй үзе баса, аннан мичкә ягып җибәрә дә әпине пешерә. Мин мич әпиенең тәмле исенә генә уянам. Әтки килсә, әй мактарга керешә инде мине: «Менә, кызың салган әпи, белеп аша!» – дигән була. Тегесе дә кушылып мактый. Үзләренчә бу да тәрбияләү дип уйлыйлар, беләм мин аларны. Ләкин бала гына булсам да, әпине изүгә караганда, басу авыррак икәнен аңлыйм бит, күргәнем бар. Бушка мактаулары эчемне пошыра, яратмыйм шулай кыланганнарын. Нәнәйнең түземлеге җитми, бераз ярылып киткән түмтүгәрәк зур әпиен уратып кисеп ала да бөрткән дөге ярмасына балык исле томат соусы кушылган «консерваны» бер шәптә сыптырып куябыз. Ә йокларга яткач, утны сүндергәч, икәүләп тәртип бозабыз. Әнкиләр торган йортта моны рөхсәт итмәсләр иде, беләм мин! Юрганны ияккә кадәр мендереп куябыз да кукуруз таякчыкларын ашыйбыз. Аның тәмлелеге! Аннан стенага эленгән радионы ачарга куша. Вакытын белеп ачтың исә төнгелеккә концерт биргән чакка туры киләсең. Нәнәй белә, хәзер Фәридә җырлый, ди. Башта Фәридә Кудашевага кушылып җырлыйбыз: Уфаларга барган чакта, / Кара урманнар үтәм. / Сабыр итәм, / Сине көтәм, / Кирәкми миңа бүтән...

Радио туктагач, үзебез генә җырлыйбыз. Клубта кара төнгә кадәр домино сугып кайткан Газнәви абый икенче көнне безне мактап уза. «Туктап тыңлап тордым, ну җырлыйсыз, малай!» – ди. Ярык тәрәзәдән ишетелә инде, нәнәйнең тавышы көр, белгән җырлары да чамасыз.

Әнки сельпода эшли. Ара-тирә «индийский» чәй алып килә безгә. Нәнәй тышына фил төшерелгән бәләкәй генә каплы чәйне ике куллап тотып, исләрен иснәп, җыерчыклы битләренә куеп куана. Такта чәй биздерә шул.

Иң рәхәте – җәй көннәре. Иртән кызган май исенә уянып китәм. Нәнәй карават читенә утырган килеш кенә урындык өстенә җәймә тактасын куеп, маяш ясый. Чәкчәк, бавырсак, кош теле – безнең авылда «маяш» дип атала. Йомырка белән тозга гына басылган сап-сары камырны бик нечкә «баулар» итеп тәгәрәтеп тезеп куя. Аннары бик вак итеп кисә. Оны коелсын өчен иләккә салып селкетеп ала да электр плитәсенә куелган табада кыздыра. Шуларны сөтле, шикәрле чәйгә салсаң, хуш исенә егыласың инде менә!

Рәхәт озакка бармый. Иртә яздан өйдә утырып бәбкәләр чыгарган инә каз ишегалдыннан тавыш бирә. Шунда иске карават астына төнгелеккә ябабыз аларны, башка урын юк. Ысылдавы үзәккә үткән, чәй эчәргә дә ирек бирми. Нәнәйне тыңламый булмый: яшел чирәм җыелынган, бәбкәләрне шунда чыгарабыз башта. Ул иртәнге җиләс һаваның рәхәтлеге!.. Төштән соң казларны чишмә буена алып төшеп менәбез. Араларында бер имгәк бәбкә булды быел. Нәнәй дә аксап йөри, күршем Робертның да аягы авырта, артта калудан туктаусыз пипелдәгән бәбкәнеке дә. Аны тагын да ныграк тырышып карыйм. Бәбкәне исән-имин үстерәлсәм, нәнәй дә, авыру дустым да озак яшәрләр кебек. Әллә нинди, кешегә сөйләп булмас уйлар күп ул минем башта. Әллә чи суганны күп ашаганнан...

Ысылдаган инә каз артыннан гарип баласын җәй буена күтәреп йөрдем. Бераз гына исәйде дә бит. Калган казларны суйганда, әтки бәләкәй бәбкәне дә чалып ташлады. Эчемдә нәрсәдер өзелгән кебек булганын да әйтергә кыенсындым.

Кышларын авыррак. Аяксыз нәнәйне урамга алып чыгып та, күршеләргә алып барып та булмый. Барыбер аның янында рәхәт. Кич җитә башласа, нәнәй янына кунарга китәргә дип ашыга башлыйм. Беркөнне дуамал буран чыкты. «Бу тискәре буранда менеп йөрмә инде», – ди әнки. Мин турсаям, үземнекен сөйлим. Нәнәй янында кунасы килә шул. Олы урамга кадәр озатып чыкты. Аннан, каршы җилгә иелеп, үзем генә киттем. Куркыныч буран булды бу. Көчкә барып җиттем. Көндәгедәй иртәрәк икәүләп кычкырып доганы укыдык та, нәнәй өстәп үзенең теләген теләгәч, йокларга яттык. Озак үрсәләнде ул бу төнне. Чирләдем димәгәч, даруын бирмәдем. Бераздан теләген дә тагын

бер тапкыр кабатлады: «Өч көннән дә артык яткырма мине, Ходаем. Бердәнбер баламны интектерергә язмасын...» Иртән иртүк әнки килеп керде. Мин аның елавын беренче тапкыр шунда күргәнмендер. «Төнлә абзар янды. Янып бетте. Ут төрткәннәр. Бер мал да калмады», – дип, әнки өзек-өзек сүзләр белән куркыныч хәлне сөйләде. Кычкырып елау да, җәлләтү дә юк. Күз яшьләре генә тәгәри. Нәнәй эндәшәлми утырып калды. Әнки мине киендереп, кайтырга чыкты. Кар тәрәзәнең яртысыннан өйгән. Нәнәйгә борылып карадым. «Сөтсез калдык, бала-ам», – дип елап җибәрде. Аның да яшьләре нәкъ әнкинеке кебек ага...

Салам башлы зур гына абзарыбыздан чүп өеме генә торып калган. Өемнән ерак түгел бәләкәй генә мунча. Аның эченнән эт чыйнап елаган тавыш ишетелә. Абзар тулы малдан бер бәләкәй генә эт – Лайкабыз исән калган икән. Әтки йөгереп чыгып абзар ишеген ачуга, ут аны аягыннан еккан. Ничектер, ушы җитеп, абзарның арткы ягында бәйләнгән Лайканы ычкындырган...

Кешеләр җыелып чүп өемен түгә башлагач, кирмәсеннәр, дип, энем белән икебезне мәктәпкә җибәрделәр. Әзер түгел идек бит, сумкасыз гына бардык. Без елга аша урнашкан урыс авылында – Анновкада – башлангыч мәктәптә укыйбыз. Урыс апалары мине дәрестән чакырып чыгарып, буялган күкәйләр, «Пусть мама печеньки купит», – дип, акчалар бирделәр. Алар миңа таныш түгел иде. Әмма мин шул күкәйләрне ашаганда, аларның минем кайгымны якын итеп, әрнеп кабул итүләрен аңладым. Мәктәптән ашыгып кайттык. Милиция зур эт белән ут төртүче кеше эзеннән йөрде. Пимасының бәләкәйлеге буенча, хатын-кыздыр, дип, эзнең югары очтагы туй барган йортка кереп югалуы турында сөйләнделәр. Энем Рөстәм белән барын да ишетеп тордык.

Милицияләр киткәч, мунчаны ачып Лайканы ирекккә чыгардык. Без дә энем белән теге эз буйлап йөреп килдек. Яңгын чыккач та буран туктагандыр инде, эзләр ярылып ята иде. Гомерлеккә күз алдында калдылар...

Мин әнкинең тик утырганын, нәрсәнедер эшләми иртәгәгә калдырганын белмим. Эштән кайта да, төнгә кадәр өйдә йөгерә. Гел нәрсәдер эшләп өлгерергә тырыша, елмаюын, утырып ял итүен сирәк күрәсең. Абзар янганнан соң ул тагын да ачулыракка әйләнде. Гел кемнедер тирги, әрни, гел канәгать түгел. Туганнан башлап бер-береңне белгән авылдашларында шикләнү әнкигә генә түгел, әткигә дә авыр. Ул бит гел халык арасында. «Бар кешегә дә ярап булмый, дошманнарым да булгандыр», – ди. Абзарсыз, малсыз калгач, булышу йөзеннәндер, әткинең бертуганы энем белән икебезгә курткалар китерде. Яратмадым шул киемне. Биле бил урынында түгел, җайсыз. Әтки белән әнки мактап-мактап кидерергә тырыштылар. Салам башлы абзар урынына менә дигәнен, өр-яңа агач исе килеп торганын салып куйдылар. Әтки, әлеге дә баягы гел канәгатьсез әнкидән мең тапкыр тиргәлеп, фермадан өч имчәкле сыер алып кайтты. Марта – матур йөзле сыер, без аны яраттык, фотоларга төшердек. Көтү көткәндә башка сыерлар белән чагыштырабыз, чынлап ямьсезләр бит чибәр Мартабыз янында. Авыл ирләре абзарны җыелышып эшләгәне истә калган. Төшке ашка кергәндә безнең өйнең буялмаган биек күтәрмәсеннән эшчеләр менә тора, кадакка эленгән каклаган казны кисеп алып ашый тора. Авыз суларын китерә шул каз... Аның тәмлелеге! Энем белән ничек эләктерергә белми азапланабыз. Безгә тиеш түгел бит абзар төзүчеләр ризыгы. Араларында көләч йөзле, шаян сүзле Хәниф абый бар, ул өләшә безгә казны. Урманчы булып эшләгән шул Хәниф абыйга бирде әтки безнең исән калган Лайканы. Энем белән мине көнләштереп, урманчы утырган арба артыннан иртән дә, кич тә, койрыгын болгап, безнең алдан узды Лайкабыз. Аның урынына әтки овчарка алып кайтты. Яңа абзардан өйгә кадәр тимер чыбык сузып, этне чабып йөрергә шуңа эләктереп куйды. Мунча керергә төшкәндә, туймас ерткычка нәнәй «хәер итеп» бер буханка кара икмәк алып төшәр булды. Бер кабуда йота... Ә без үсми торган, койрыгын болгап күзгә карый торган, өрмәгән, өрсә дә куркытмаган, карашында бер усаллык булмаган Лайканы сагынабыз. Аның чит кеше арбасына ияреп йөрүеннән көнләшәбез... Өрми торган этне чылбырга тагып, тыныч йоклаулар бетте шул абзар янгач. Гомерлек шикләнү, курку, кешеләргә ышанмау калды.



Рәсем: Наталья Васильева



Бу куркыныч вакыйгадан соң әнкиләргә минем бөтенләй барасым килми башлады. Мунча кергәч, нәнәй дә, мин дә йокысыз төн уздырабыз. Алай гына да түгел, нәнәйнең өендә дә тәрәзә чаршавын ачып йоклар булдым. Нәнәй суык керә буыннарыма дип тирги тора, мин ача торам. Биек киртәдән ут төртүче сикереп төшәр кебек. Шуны күзәтеп озак ятам, тәмам бәлтерәгәч кенә йокыга талам. Онытып торам: яңа абзар төзегәндә күрше Әкълимә апаның банкасыннан акча алып тордык без. Шунда күрдем дә инде аларның баз эргәсенә, туфракка күмелеп сакланганын.

Куркыныч вакыйгалар дигәннән... Чалт аяз май көне исемдә калган. Укымаган чак булгандыр, йокыдан торгач, әнкиләргә төшеп бара идем кебек. Капканы ачарга үрелдем генә – теге куш кәүсәле тупылның иң очында кара карга каркылдый башлады. Мине озатырга чыккан нәнәй «шул эчен пошырган» агач башына карады.

– Үлем була инде, балам, бүген. Авылда үлем булса шулай кычкыра ул. Хәшәрәт! Көш-ш! Кит минем йортымнан!

Нәнәйнең йөзе караңгыланды, куркуы күзенә чыккан. Күреп торам: үзем үләрмен микәнни дип курка ул. Кара каргага бик ышанып бетмәсәм дә, нәнәй жәл. Әнкиләрдә озак тормадым. Әйләнеп менүемә, нәнәй хәбәр әйтеп тора:

– Җамал үлгән. Малае үтергән...

Җамал апа да ятим хатын, нәнәйнең дусты. Урам башында яшәүче телсез әби – Җамал апаның бертуганы. Авыл бу көннәрдә гөж килеп торды. Без дә энем белән елганың каршы ярына чыгып кердек. Җамал апаның зәңгәргә буялган өе янына халык күп җыелган иде. Барысы да аптырашкан хәлдә басып каткан. Кешеләр ара-тирә генә пышылдап, берберсенә эндәшеп куялар. Аптырамаслыкмыни: авылымның тыныч тормышына сыймас хәл бит бу. Милиция килгән. Без якын барырга курыктык. Әнисенең «тәнендә чәнечмәгән, кыгәрмәгән урын калдырмаган» егет урам башындагы телсез апага бигрәк еш килә иде. Мине куркыта торган шомлы апа белән әнисен үтерүче арасына әллә нинди «җепләр» ялгап, бик озак уйланып йөрдем. Минем баш шундый ул. Суганнан түгел икәнен беләм инде. Башым уйлаганнарны кычкырып сөйләп булмый. Хәтта нәнәйгә дә. Телсезгә бара башласа, чата-карман килеп туктатам нәнәйне хәзер. Шул үтерүчене базында саклап тотадыр кебек...

Ара-тирә рәхәт хәлләр дә булгалый. Коеп яуган яңгырлы бер караңгы кичтә этки килеп керде. Киң елмаюы бәләкәй генә өйгә сыймый, тәрәзә ярыкларыннан тышка да чыга кебек. Зәңгәр костюм алып килгән этки. Чалбар белән замоклы жимпер (джемперны шулай дибез без). Аны кигәч, башым күккә тиде. Үземә килешкәнен, гәүдәмне тагын да озынайтып матур итеп күрсәткәнен бөтен күңелем белән тойдым. Этки үзенә куана: кайсыдыр авыл сельпосыннан «астан» гына алган икән. Дөресме-түгелме: аңлавымча, ул аны үзе сөйләшеп эләктергән. Әнкисез. Шуңа бигрәк куана бугай. Чөнки безнең гаиләдә әйбер табу эшләрен гел әнки эшли. Шуңа үзен «Аллаһдай» хис итә: ул гына барын да булдыра, калганнар юньсез. Кычкырып тиргәшмәсәләр дә, түбән очтагы өйдә менә шул халәтне гел сизәм. Шуңа төнге кап-кара пычракны ярып, нәнәй белән минем янга кергән эткинең үз-үзенә куанып утыруы күңелемә бик якын. Эткинең шатлыгы өчен дә, үземнең киемем өчен дә куаным ул онытылмас кичтә. Бәләкәйләнеп, чалбарымның – тезләре, жимперемнең терсәкләре тишелеп беткәнче яратып кидем шул киемне! Үземә килешкәнен белеп: «Синең инәң сельпода эшләгәч, дефицит әйбер киясең инде, безгә – калхузник баласына юк», дигән энәле төрттерүләргә дә карамый («силсәвит персидәтеле кызы булгач, куялар инде «бишле!» дигән урынсыз гаепләүләр, нинди чарада катнашсам да, «активистка», дип җан үртәүләр сыйныфташларымны, мәктәпне күралмас хәлгә җиткергән иде), чын хатынкыз итеп хис итеп үземне, башымны югары тотып кидем шул костюмны. Юк, этки алып биргән өчен түгел, матурлыгымны сизгән өчен. Бәхетнең нинди булуын шунда белдем.

Без энем белән Анновка авылына укырга йөрибез. Анда – мәктәп директорының өе белән янәшәдә ике сыйныф укый торган башлангыч мәктәп бар. Бер сыйныфны, энем укыганын – урыс директорның хатыны, икенчесен бигрәкләр дә чибәр татар хатыны укыта. Энемнең укытучысы усал һәм кызу: тактага яза торган акбурлар тәк кенә оча дәрестә. Минем укытучым искиткеч әйбәт укыта. Ул рус теленә шәп, ул математикага! Безгә бер дә рәхәт түгел таңнан торып елга аша укырга йөрү. Бер башлангыч сыйныф авылдагы мәктәптә укый бит, безгә нәрсә калган? Алар татарча җырлый, татарча сөйләшә... Иртән энем – эткиләрдән, мин нәнәйдән килеп, авыл уртасындагы «быткомбинат йорты» алдында очрашабыз. Без тар сукмактан мәктәпкә йөгергәндә яктырта башлаган була инде. Иң үзәккә үткәне – дәрес әзерләтергә мәҗбүри калдыру һәм, ач тормасыннар дип, күл суыннан чәй йә кесәл кайнатып эчерү. Тәмсезлеге шуның! Дүртенче класска күчкәч кенә котылдык шул Анновка мәктәбеннән. Нәнәй мәктәп каршында гына яши. Хәзер инде мин тулы хокук белән нәнәйгә кунарга менәм. Миннән бәхетле кеше юк. Дәрес арасында да янына чыгып чәй эчеп керәм. Электр чәйнеге гел кайнаган... Мине көтә.

Апрельнең 29 ында кичтән хәле бетте. «Үзәгем көя», – дип аптыратты. Әлегә кадәр бирә торган даруларын тамызып эчердем. «Әй Аллакаем, өч көннән дә артык яткырма урын өстендә. Бердәнбер балам җәфаланмасын. Әлпи, диси, җәмгый, әхәт... ал-фия. Кабатла, балам. Иренмә...» Үзеннән үзе ятланган доганы кабатлыйм. Теләкләрем генә башка. Тик күз алдыма болытлар өстендә тәхеттә утырып бизәкле башлы таягы белән кеше язмышларын хәл итүче булып килгән Алла бабай гына мине ишетми, ахры. Нәнәй өйрәткәнчә, бик дөрес итеп, ихлас укыдым бит догамны югыйсә...

Мин йокламыйм. Кулым – нәнәйнең пульсында. Күзем – тәрәзәдә. Кыска ак пәрдәне тартып куйдым. Күктәге ай никтер моңсурак карый кебек. Нәнәй үлсә нишләрмен, дип, тагын үземне җәлләп елап җибәрәм. Тавышсыз гына күз яшем ага. Нәнәй боларның берсен дә белми, йоклый бирә...

Болай авырганнан соң иртән тормый калганы юк иде. Бу юлы тормады нәнәем. Мин ниндидер табигый сизгерлек белән нәнәй телägән өч көннең килеп җиткәнен аңладым. Кичен әнки килде, күрше Әкълимә апаны да кунарга алып керде, һаман шул көрән күлмәгеннән Әкълимә апа. Артык бер сүз эндәшмәс, һавада үлем шомы эленеп торганда, шундый кеше кирәктер дә янда.

Нәнәй икенче көнне дә тормады, ризык капмады. Каен суы сорады. Бер йотым капты. Каен суы өстәлдә

утырып калды. Күнозын ачмаган күз кабакларын селкетеп, кечкенә сеңлемне чакырырга кушты. Хушлашырга. Нәнәй белән энем якын кешеләрем исемлегендә иң беренче торалар. Әмма сеңлемне бөтенләй башкача яратам мин. Ул туганда мин зур идем инде. Барын да аңлап кабул итәрлек зур. Аксак нәнәем ул вакытта район үзәгендәге хастаханәгә өченче онытын барып күрерлек хәлдә иде әле. Бергәләп бардык. Бер катлы йортның тоныкташ тәрәзә пыялалары аша кечкенә төргәкне күрсәтте әнки. Нәнәйнең куанганы! Әтки, минем салпы ягыма салам кыстырып: «Матур бит, әйеме?» – дип сорап, мәҗбүри «әйеләтеп», Гөлназ дип исем кушты аңа. Сеңлемнең тәүге сүзе, адымнары, кызыклары – барысы да исемдә. Нәнәй белән бергәләп карап үстердек аны. «Туган җирем, рәхмәт сиңа!» дигән бик киң таралган җыр бар иде ул чакта. Шуны өйрәттем. Сеңлем, «р» хәрефен әйтәлмәгән көенә җырны, чатнатып, клуб сәхнәсендә җырлады. Әтки белән әнкинең моннан да горуррак чагын күрмәгәнмендер. Мин дә эчемнән бик горурландым: башыннан алып азагына кадәр мин куйдым бит бу номерны сәхнәгә. Ул вакытта 5 яшендә бөтен авылны таң калдырып җырлаган бала сирәк булгандыр әле. Ул туганчы, җырчыга әйләнгәнче дә мин күләгәдә идем. Ул вакытта, бердәнбер малай булarak, гел энем макталды. Аның кызык сүзләрен кабатлап көләләр иде ирләр, әтки масая иде. Ә минем әллә ни мактар җирем юк: әнки әйтмешли, чәчем сыек, маңгаем киң, җырламыйм, борыным да озын, үзем дә... Дөресен генә әйткәндә, мин әнки ягына охшаганмын, ахры, шуңа да түбән очтагы өйдә мин бик яратылмыйм. Мин күләгәдә булып өйрәнгән, һәм «алдынгылыкны» күптән энемә һәм сеңлемә биргән, якыннарыма кушылып, «олыларча» кыланып, аларны яратырга өйрәнгән. Мин боларны ничек бар шулай кабул иткән һәм аңлаган. Тик нигә үлем түшәгендә яткан нәнәй сеңлемне дәштерә соң хушлашырга? Нигә мине түгел? Ничә еллар буе аның янында МИН яшәдем бит! Аңа тугры булдым! Әнкиләрдән дә артык күреп яраттым! Җитмәгән, кыек җирләрен күрә торып, үзе аңламаса да, бала йөрәгем белән кичереп яраттым! Нигә ул соңгы сәгатендә мине караваты янына чакырып хушлашмады?

Бөтен өйне тутырып гырылдап йоклавыннан ул өченче көнне дә уянмады. Иреннәрен карагат кайнатмасы суына манган каз канаты белән чылатып тордылар. Күзләрен ачар да, нәнәй мине чакырыр дип көттем. Мине өйдән чыгара алмадылар. Күңелемдә нинди уйлар давылы купканын сизүче дә булмады. Минем күп нәрсәне тирән аңлавымны белми иде өлкәннәр. Тәүге тапкыр татыган бу авыр хис көнләшү түгел бит дип, эчтән сызландым. Юк, мин көнләшергә тиеш түгел. Мин апа кеше бит. Бу әрнүне дә һич кенә сеңлемә булган туган мөнәсәбәтенә ягылдырмадым. Үземне мәҗбүриләп кичердем нәнәйне. Әмма мин бу көннәрдә чынлап бәхетсез булдым. Нәнәсе үлгәннән кайгыра дигәннәрдер. Ә мин өчләтә кайгырдым, яндым: нәнәйсез калдым, аның соңгы көнендә хыянәтен кичердем, хәзер миңа әнкиләргә кайтырга туры киләчәк... Бәхетсезлек тәмен тәүге тапкыр татуым шул булды. Аннан соң да күп тапкырлар югалту-хыянәтләр кичерсәм дә, беренчесе онытылмый икән.

Әнкиләрдәге тормышка өйрәнеп китәлми озак газапландым. Дүрт ел үткәч тә, сигезенче сыйныфны тәмамлаганда, имтиханнарга әзерләнгән, бәбкәләр саклаган, су ташыган арада да качып кына зиратка, нәнәй каберенә барып килә идем. «Сезгә сәпит алып бирәбез», – дип, мине җайлый-җайлый, нәнәйнең кечкенә өен бер әбигә саттылар. Мәктәптә укыганда кереп-кереп чыга идем. Стеналар да, идәннәр дә шул ук, бер җиһаз кузгалмаган, ә өй караңгы. Нәнәйнең очкынлы күзләре, киң елмаюы, кычкырып сөйләшүе белән якты булган икән ул. Нәнәйне күмеп, берничә көн үткәч, әнкинең елавын икенче тапкыр күрдем. Радиодан агылган «Җидегән чишмә»гә кушылып, күз яшьләре тәгәри. «Исән чагында бик якын да түгелләр кебек иде. Барыбер әнки аны яраткан икән», дигән уй сызылып үтте башымнан. Чынлап, әнкинең гел вакыты юк иде шул. Гел ашыга, гел канәгатьсез, гел ачулы. Бер тапкыр да нәнәй янына килеп иркенләп утырып чәй эчкәнен, сөйләшкәнен хәтерләмим. Әллә шуңа әрнеп елыймы? Әнки тәрәзә буена, озын челтәрләр артына качкан. Шундый жәл, үзе миннән кыенсына да кебек. Әнкине кочаклап җәллисем килә, әмма мин кочаклашырга күнекмәгән. Әнкиләрнең өендә челтәрләр дә озын, җиһазлар да башка, тормыш та. Ә мин кыска пәрдәле, җепкә тартылган кыска ак чаршаулы, бармак сыешлы ярыклы бер кат тәрәзәне сагынам. Нәнәй тәрәзәсен. Дөньяга да, туганнарга да, авылдашларга да, дусларым әйткән сүзләргә дә күп вакыт нәнәй күзе аша караганымны сизәм. Нәнәй тәрәзәсе аша... Нәнәй өйрәткән доганы каберенә менгәч тә кабатлыйм. Азагын «тыныч ят» дип үзгәртәм. Нәнәй догасы беркайчан да онытылмый, күңелдә яши. Дөрес әйтмәдем. Доганың көченә ышаныч күңелнең төбенә яшерелеп куелган. Үзе теләгәнчә, нәкъ өч көн чирләп ятты бит нәнәй. 2 майда җан бирде...

Гарип бәбкә дә, кадерле нәнәем дә, аксак дустым Роберт та бер-бер артлы киттеләр дөньядан. Минем тулы тормышымны буш итеп...

Дистә еллар үткәч, дин кире кайтты халыкка. Хәзер инде үлгәннәрнең өчесен, җидесен, кырыгын без үскәндәге кебек ярым качып укытмыйлар. Зурлап мәҗлес коралар. Муллалар, хәзрәтләр моңлы итеп Коръән сүрәләре укый. Тыңлаган саен, нәнәйне, яттан дога белмәгән, белсә дә укырга аптыраган, дөнья нужасыннан башлары чыкмаган ялгыз әбиләремне искә төшереп утырам. Нәнәйнең догасын ишетергә теләп, бөтен игътибарымны муллаларның авызыннан чыккан сүзләргә юнәлтәм. Юк нәнәйнең «әлпи, диси...»е! Булмаса булмый инде, мин барыбер амин тотканда нәнәй догасы белән тәмамлап куям.

Күп еллар узгач, гаиләбезгә укымышлы апа килеп керде. Ислам институтын тәмамлады ул. Хаҗия. Аңа укып күрсәттем нәнәйнең догасын.

– Бу гарәп алфавиты хәрефләре. Шулкадәр дә үзгәртелгән авазлар! Бик күп догалар шул хәрефләр белән башлана. Күңелеңә кереп калган икән, укы! Догаң ихлас булса, теләгең кабул булыр, сеңлем! – диде хаҗия.

Кадерле нәнәем Зәйтүнә Әбрар кызы рухына догамны юллыйм: «Әлпи, диси, җәмгый, әхәт, алдал, рәҗи, шәмсам, бикуф, каплам, миңнум ам алфия. Оҗмах түрләрендә булсын урының, якты күңелле нәнәем! Тәрбияң, дөньяны яратуың, яшәү ямең, дога көчең яши миндә. Рәхмәт сиңа!»



ЯШЭЕШ



Авылны бары тик аның халкы гына саклап кала ала. Бәхеткә, андыйлар күп бездә. Бу язмамда шундый гаиләләрнең берсе белән таныштырасым килә.

Бөтенроссия Татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумында Рәзилә Хәмидуллина белән мин якыннан танышып киттем. Безне уртак эшләр, теләкләр берләштерде бугай. Дөньяга карашларыбыз да бертөслерәк булып чыкты.

Рәзилә ханымның уллары белән күптәннән таныш идем инде. Олысы Рамил Хәмидуллин Казан дәүләт университетының татар бүлегендә белем алды. Хезмәт юлын Удмуртиядә нәшер ителүче «Яңарыш» газетасында хәбәрче буларак башлап җибәрде. Аннан соң ул революциягә кадәр үк Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танылу алган Иж-Бубый мәдрәсәсенең дәвамчысы булган мәктәптә укытты.

Энесе Радик Хәмидуллин (Рамазан хәзрәт), Россия Ислам университетын тәмамлаганнан соң, Әгерҗе мәчет-мәдрәсәсендә эшли башлады. Мин үзем эшләгән һөнәри училище укучылары белән ике ел буена һәр шимбәдә Рамазан хәзрәтнең вәгазьләрен тыңларга йөрдем. Бер группада 30 укучы – булачак тимерьюлчылар – төрле милләт уллары, төрле тәрбия алган егетләр. Барысы да татар телен өйрәнә. Ә Рамазан хәзрәт аларның күңелләренә үтәрлек итеп, вәгазьләрен татар, рус, гарәп телләрендә чиратлаштырып сөйли. «Эх, мәктәпләрдә дә шундый укытучылар күбрәк булса иде», – дип, дөньяларымны онытып тыңлап утырам.

Бу егетләрнең әниләре Рәзилә Миңнехан кызы – һөнәре буенча шәфкать туташы. Күңеле тулы шәфкатьлелек, кешеләргә ярдәм итү теләге аның. Балаларына да шундый тәрбия биргән.

Сез аларның бакчаларын күрсәгез! Бакчада эшләү гаилә башлыгы Расим Хәмидуллинның яраткан шөгыле икән. Лаеклы ялга чыкканчы ул тимер юлда эшләгән. Буш вакытларын бакчачылыкка багышлаган. Авыл кешесенең бакчачы һөнәрен үзлегеннән өйрәнеп, аның карталарын төзеп, безнең якка хас булмаган җиләк-җимеш агачларын үстереп, тәҗрибәләр ясавын минем әле беренче тапкыр күрүем. Җылы як үсемлекләрен үзебездә үстерү өчен күп көч куя ул. Расим әфәнденең девизы да: «Тормышыбыз – гөлбакча, ә яшәү рәвешебез андагы һәр үсентегә тиешле тәрбия, игътибар күрсәтелергә тиеш». Гөлбакчасында да, тормышында да үз девизына тугрылыклы ул.

Расимны иң борчыганы – татарларның кимүе. Аннан соң сыйфат мәсьәләсен дә җитди кайгыртырга кирәк дип исәпли. Гыйлемлелек, милли үзаң, ислам дине кушканча яшәү дип аңларга кирәк сыйфатны. Әмма беренче урында тел мәсьәләсе тора. Туган телсез без – кисеп ташланган агач кебек.

– Милләтебез өчен сан да, сыйфат та беренче урында. Телебезне югалтсак, аны бүтән терелтеп булмас, – дип фикер йөртә Расим Хәмидуллин.

Уллары Рамил белән Радик, әтиләренең дәвамчылары буларак, аның фәлсәфәсен тормышка ашыру юлында. Икесе дә Ямурза авылында эшмәкәр Сәхиповлар нигез салган яңа тормыш сафында әйдәп баручылар. «Авыл яшәсә генә милләтебез яшәр» дигән девизга тугрылык саклап, Ямурзада иң беренче яшьләр өчен эш урыннары булдырылган. Балалар өчен татар телле бакча, мәктәп эшли. Телебезне, гореф-гадәтләребезне, тарихыбызны, гомумән, кешелекне саклаучы ислам диненең роленә зур игътибар бирелә монда.

Бу егетләрнең икесен дә шулар тартып китергән Ямурзага. Рамил эшмәкәр Сәхиповлар оештырган авыл хуҗалыгы артелендә эшли. Берничә китап бастырып чыгарырлык шигырьләре бар, көйләр яза, җырлый да. Рамазан хәзрәт исә хатыны Эльвира белән өч бала үстерә.

Ямурзада мөселманча яшәү рәвешен яңадан торгызган Илшат Сәхипов үзе инде вафат. Ләкин дәвамчылары – уллары-киленнәре, оныклары, хатыны Әнсәрия, авылдашлары, Рамил һәм Радик кебек фикердәшләре аның эшен дәвам итә. Аларның төп максаты – Ямурза авылында милләтебезне, телебезне, мәдәниятебезне саклап яшәү.

Вәсилә ХӘКИМОВА.
Әгерҗе шәһәре.

Фото: Ксения Богданова

Быелгы җәй салкын башланды. Шуңа да мин, җылы эзләп, Сочи якларына юл тоттым. Рәхмәт балаларыма, пенсиядәге әбине шундый күңелле сәяхәткә җибәрделәр.

Сәфәрем Казанның тимер юл вокзалында башланды. Адлерга барасы поезд иртәнге биштә үк китә икән. Кеше әллә ни күп түгел, булганының да яртысыннан күбрәге балалар. Каникул вакыты бит, алар да ял итәргә бара, күрәсең. Әле поезд китәргә вакыт бар, чәй эчеп килим дисәм, бәяләрне күреп, чәй эчәсе килү теләгем бик тиз сүрелде.

Җәйге җилләр белән узышып, поезд алга чаба. Ә хыяллар аннан да җитезрәк. Яшь чакларда Волгоград, Әстерхан шәһәрләренә барганым булса да, Кара диңгезгә беренче баруым. Нинди икән син, серле диңгез?! Поезд тәрәзәсеннән карап барырга яратам мин. Бөтен җирдә яшеллек, матурлык... Ак каеннар, чәчәкле тугайлар күренеп кала. Андасанда аунаган тимер-томыр кисәкләре генә күзне ертып, эчне пошыра. Шушы матурлыкны боза алар.

Ике төн барганнан соң, ниһаять, диңгезгә дә килеп җиттек. Зәңгәр дулкыннарга сокланганчы, башта вокзалдагы чәчәкләрнең купшылыгына хәйран калдым әле. Юлдагы арулар да онытылды...

Рәхәт ял булды ул. Матур өйләрдә яшәдем, хуҗалары да җайлы кешеләр булып чыкты. Диңгез суы бераз салкынчарак иде әле, ләкин күңелне һич тә төшермәде. Аяк астындагы ташлар табанны авырттыра – бушлай массаж дип кабул иттем анысын.

Таулар! Болытлар артына яшеренгән биек тауларны янәшәмдә күргәч телсез калдым. Менә кайда икән ул гүзәллек! Бәхет таулар артында түгел, тауларда икән. Сочига барсагыз, серләре әле дә ачылып бетмәгән «Роза Хутор» тауларына менми китмәгез! Тау түбәләрендә кар катламы. Салкын. Кара диңгез өстеннән 2320 метр биеклеккә күтәрелдек. Югарырак күтәрелгән саен, табигатьнең матурлыгы ачыла гына бара. Йөрәк тибешенә кадәр үзгәрә.

Сочи, Адлер шәһәрләре шундый матур! 2014 елда Сочида кышкы Олимпия уеннары узган иде бит. Олимпия шәһәрчеге әллә каян үзенә тартып тора.

Шарлавыклар – аерым тема. Аларны сүзләр белән генә тасвирлап бетереп тә булмас. «Менделиха» шарлавыклар паркы 1472 метр биеклектә үз колачына 33 шарлавыкны сыйдырган да, төннәр буе челтер-челтер челтери. Мзымта елгасы ярларына сыймый агып ята.

Ярый әле тәвәккәлләп чыкканмын бу сәяхәткә. Дөнья күрдем, рәхәтләнеп кешеләр белән аралаштым, көньяк җимешләре белән сыйландым. Кибетләрдә йөрдем... Диңгезнең суы да, һавасы да шифалы инде аның. Көньяк җилләреннән дә тәннәребез каралды. Тагын барырга насыйп булсын иде дип, матур хыялларга бирелеп кайттым әле.

Рәшидә *ҖИҺАНШИНА.*
Зәй шәһәре.

Кечкенә чакларым бик күңелле узды минем. Киясе килгән киемемне кидем, ашыйсы килгән ризыгымны ашап, барасы килгән җиремә бардым. Матур һәм якты балачагым өчен әти-әнигә рәхмәт! Яшь барган саен, «балачак иле»ндә еш кунак буласың икән.

Сабый баланың энеле яисә сеңелле булырга хыялланган чагы. Теләкне әтиәнигә дә җиткереп карадым, «Акча юк», – диләр. Көтә торгач, килде ул көн. Әнине бала табу йортына алып киткәч, иптәшләремә, күрше-тирәләргә: «Әни Динарны алып кайта!» – дип такмаклап йөргәнем хәтердә. Май ахырында әнием энекәш алып кайтты. Динар исемле! Исемне үзем сайладым!

Сөенечле көннәрем озакка бармады. Динарны карау минем җилкәгә төште. 4 яшьлек бала җилкәсенә. Җәй ае бит, бакча эше дә күп булгандыр инде, хатын-кызның эше бетә димени?! Әниемнең көннәр буе чиләк-көянтәләп бакча башындагы инештән су ташыганын бүгенгедәй хәтерлим. Бераз кул арасына керә башлагач, әлеге чиләк-көянтәләр безнең иңнәргә күчте.

Энем тугач, иптәшләрем белән авыл буйлап йөгерүләргә нокта куелды. Капка төбендә сикереп уйнап керергә рөхсәт бар барын, тик анысы да Динар йоклаган арада гына.

Бер вакыйга аеруча истә калган. Җәйге бер матур көндә шулкадәр уйнарга чыгасым килә. Ә энем йокламый да йокламый. Үземчә әрләп тә карыйм, юк бит, бишегендә селкенеп тик «сөйләшеп» ята. Ачуым чыгып, бишекне бар көчемә тирбәтә башламасаммы?! Динар шым булды. Алай гына да түгел, бишек пружинасыннан очып та чыкты, Динары белән бергә тимер карават астына тәгәрәп кереп тә китте. Аны карават астыннан тартып чыгардым да, өйдән чыгып та йөгердем. Үзем ачык тәрәзәдән тыңлап торам: елыймы, юкмы? Юк, еламады. Үзенчә «сөйләшеп" яткан тавышын ишеткәч, тынычланып, иптәшләрем янына чаптым. Бүген энем белән очрашканда, җае чыккан саен әлеге хәлне искә төшереп, көлешмичә калмыйбыз.

Динарыбызга алты ай тулуга, әни эшкә чыкты. Ноябрь ахыры иде ул. Көннәрнең кыскарган, төннәрнең озынайган чагы. Иртәнге сәгать дүрттә әти белән әни энемне киендереп, каршыда гына яшәүче әбиләргә кертеп калдыралар да, минем өстән йозак белән бикләп, атка утырып эшкә китәләр. Эх, ул йозакны бикләгәндә ачкыч тавышының үзәккә үтүләре, юрган астыннан башны чыгарырга куркып, тизрәк таң атуын тели-тели, әнинең эштән кайтуын көтеп ятулар... Ә бервакыт таң да атмаган иде әле. Әнием кайтып керде дә мине кочаклап елый ук башлады. Озак елады ул. Баксаң, минем тәрәзә төбендә пыялага кага-кага елап басып торганны әни белән бергә эшләүче Рәүфә апа күргән булган икән. Фермага килү белән, әнине кайтарып җибәргән.

Мин колхозчылар гаиләсендә үстем, әти-әнием кул көче белән төзегән тормышта аларның чиксез яратуын тоеп үстем. Акчасыз чаклар күп булса да, ач-ялангач булмадык, тәмле ашадык, барасы килгән җиргә бармыйча калмадык, мәктәптә яхшы укыдык, кешенекенә кызыкмадык, булганының кадерен белдек. Бүгенге көндә, Аллага шөкер, энем белән икебез дә тормышта үз урыныбызны таптык.

«Эх, хәзерге акылларым булсамы? Сабыйларымны шушылай тилмертеп эшләп йөрер идемме соң?!» – дип еш кабатлый бүген әнием. Йөрер иде. Кеше кабат үткәненә кайтса, шул ук сукмаклардан узар иде дип уйлыйм мин.

Куанычлы, искә алган чакта үксепүксеп еларлык мизгелләре булуы белән кадерле дә инде ул гомер дигәннәре. Һәркемнеке төрле, һәркемнеке үзенчә...

Гүзәл ХӘБИБУЛЛИНА.
Балык Бистәсе районы,
Корноухово авылы


Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru



«Ә МӘХӘББӘТ ГОМЕРЛӘРДӘН ОЗЫН...»

Хәдичә хәзрәтләре үлем түшәгендә ятканда, Мөхәммәд пәйгамбәребез аның янына килә һәм хәләхвәлен сораша, аннан болай ди: «Хәдичә! Анда баргач, синең кыяматтә көндәшең булачак – фиргавен кызы Асия белән Мәрьямне күрерсең... Аларга миннән сәлам әйт!»
Хәдичәне соңгы юлга озатканнан соң, кызы Фатыйма әтисеннән:
– Нигә инде үләр алдыннан әнинең күңелен шулай рәнҗеттең? – дип сорый.
– Анаңның изгелек дәфтәрендә һәр яхшылыкны күрдем, ләкин көндәшкә сабыр итте дигәне булмады – шул юлны да тутырыр өчен әйттем, – дип җавап бирә пәйгамбәребез.
Көндәшкә сабыр итү... «Ай-һай, аның ачысына түзү бик авыр шул», – дияр башыннан кичергәннәр. Ә бит түзгәннәр дә бар. Гөлия апаның әнисе – шундый сабыр хатыннарның берсе.

Гөлнур САФИУЛЛИНА



Радиодан җыр яңгырый. Юк, җыр гына түгел, үзәк өзгеч бер моң! Сагыш! Әйтеп аңлата алмаслык бер сагыну... ***Син кайда, мин шунда, Галиям, / Шатланам, елыймын һәм көләм. / Мәхәббәт алдында баш иям, / Син кайда, мин шунда, Галиям...***

Р

«Галия» спектакленнән «Галия белән Заһир» дуэтын (Рим Хәсәнов көе, Әнгам Атнабаев сүзләре) тыңлаганда алар икесе дә һәрвакыт бер кеше турында уйлаганнар. Хәер, әлеге җыр туганчы да, бу исемне очраклы рәвештә чит-ятлар телендә ишеткән чакларда да алар гел сискәнеп киткәннәрдер. Берсенең йөрәге өзелепләр сагынудан, гомерлек үкенечтән тагын бер кат сулкылдап куйгандыр, күзләренә янә моңсулык өсталгәндер. Ә икенчесе... Икенчесе...

...Бөек Ватан сугышы башланганда Газизгә әле 13 яшь кенә була. Әтиләре, абыйлары барысы да фронтка китеп, авыл бушап калгач, ул да, аның яшьтәшләре дә бер көн эчендә яшүсмерләрдән егеткә әйләнәләр. Ул чорның барлык авырлыгы аларның әле ныгып та өлгермәгән иңнәренә күчә.

Оста гармунчы була Газиз. Ә гармунчылар башкаларга караганда болай да күпкә иртәрәк җитлегә. Дөресрәге, җитлектерәләр... Моңарчы мәктәп сәхнәсендә чыгыш ясап йөргән егетне, авылдагы аулагөйләргә генә түгел, күрше авылларга кадәр чакыра башлыйлар. Яшьлек һәр кеше тормышында бер генә килә, аның сугыш китергән хәсрәтләрне азга булса да онытып торасы, уен-көлкегә, җыр-моңга күмеләсе килгән мизгелләре булу гаҗәп түгел. Мәхәббәт тә шулай. Ул да рөхсәтләр сорап килми: ачлыкка, юклыкка, өскә кияр кием булмауга да карамый. Күңелгә үтеп керә дә

барысын да онытты ра... Синең өчен тирә-юньдә генә түгел, бөтен дөньяда кадерледән-кадерле бер генә исем кала.

Галия! Әйе, Газиз өчен ул исем «Галия» була. Иптәшләре белән күрше авылга аулагөйгә баргач, кич утырган җирдә таныша ул аның белән. Газизгә бу вакытта 15 яшь, ә Галиягә инде – 17. Аны бу авылга укытучы итеп җибәргәннәр – әле беренче елын гына укыта.

Ике йөрәктә дә очкын берьюлы кабынгандырмы, әллә берсеннән икенчесенә күчкәндерме – анысы инде билгесез. Әмма аларның бер-берсен яратулары хак. Ике яшь аермасы әллә ни зур түгел бит ул, аннан сугыш чоры икәнен дә онытмыйк: барлык ир-егетләр фронтта, шуңа күрә Газиз кебекләрнең дә кыз-кыркын арасында дәрәҗәсе югары.

«Тиздән бергә булабыз, өйләнешәбез», – дип хыяллана алар. Газизгә 17 яшь кенә тулсын да... Никах укылганнан соң, аннары инде армиягә китсәң дә куркыныч түгел. Галия инде синеке булып калачак! Ул көткәндә солдат хезмәте дә тизрәк узачак. Борылышта язмышның нинди сынавы көткәнен икесе дә белми шул алар.

– Галияне әтисе авылларына алып кайтып киткән...

Бу хәбәр Газиз өчен аяз көнне яшен суккандай яңгырагандыр ул чакта. Нигә, ни өчен, ни сәбәпле? Алардан Самара өлкәсенең Мансур авылына кадәр тиз генә барып җитә торган түгел. Нәрсә уйларга, ни булганын аңларга, нидер эшләргә өлгергәнче, хәбәрнең икенчесе килеп ирешә. Аяктан ега торганы.

– Әтисе Галияне кияүгә биргән... Сугыштан кайткан күрше авыл егетенә...

Булачак кияве белән әтисе арасында барысы да алдан сөйләшенгән булгандыр – болай тиз хәл ителмәс иде.

Бу хәбәрне ишеткәч, Газиз чиргә сабыша. Алай гына да түгел – бөтенләй акылдан шашар дәрәҗәгә җитә. Бар өметхыяллар бер мизгел эчендә чәлпәрәмә килә, юкка чыга бит. Яшәүнең мәгънәсе калмый...

Алга таба атлап китәргә кайлардан, ничек көч алды икән ул – анысын инде белмибез.

Күпмедер вакыт узгач, авылга кунак кызы килә. Сеңлесенең ахирәте Суфиянең моңарчы да аларга утырмага килгәләгәне була. Әмма күңеле, уе башкада булган Газиз аны «күрми», билгеле. Ә бу юлы килүендә ул аңа сүз куша. Азрак онытылыйм, янган йөрәгемне беразга булса да басыйм диюе булгандыр инде. Тик ахирәте аркылы Газизнең мәхәббәт тарихы белән яхшы таныш булган кыз аның белән аралашудан шунда ук баш тарта. Әмма егет тә аның инде бик акыллы һәм сабыр икәнен аңларга өлгерә. Чибәрлеген дә күрә! Боларга үз сүзендә торасы килү дә өстәлә: тагын бер кыз аңардан баш тартырга шулай төшеп калган егетмени ул?! Ничек инде күзе төшкән икенче кыздан да коры калсын ди?! Ул арада армиягә китәр вакыты да якынлаша: Газиз аннан өйләнеп кайтканчы шундый чибәр Суфияне берсе үзенеке итмәс дип кем әйтә ала? Әйе, көтмәс ул аны, көтмәс... һәм ул тәвәккәлли! Баскан җирдән ут чыгаручы бик гаярь йөрәкле Искәндәр исемле һәм сабыр, күндәм холыклы Шәмгун атлы ике дусты була аның. Өчәү бергә киңәшеп, план корып, юк сәбәпне бар итеп, Суфияне өеннән чакырып чыгаралар да, көпә-көндез атка салып урлап кайталар.

Кызлары Гөлия апа сөйли:

– Ул чакта бит әле солдат хезмәте өч ел була. Әни шул еллар буе «солдатка» исемен күтәрә. Ишле гаиләгә килен хезмәте күрсәтә. Баласы булмагач, аңа үгез җигеп урман ташырга да, җир сөрергә дә туры килә. Без белгәндә әбиебез исән иде әле. Әтинең сугышта үлеп калган абыйсының хатыны – зур апабыз да ике кызы белән бездә тордылар... Әнине дә яратып яшәде әти, әмма Галиясен беркайчан оныта алмаганын барыбыз да белә идек...

Өченче кызы тугач, әтиләре: «Исемен Галия кушабыз!» – ди. Әниләренең каршы төшкәнен хәтерләмиләр, димәк, иренең теләге белән килешкәндер. Күршедә бабаларының сеңлесе – бөтен нәселне барлап торган бик гайрәтле туган апалары була. «Илдә булмаган бу нинди хәл?!» – дип, ул тавыш күтәрә. Исемне үзем кушам, кызыгыз Лилия булыр, ди. Ә аннары «Заһир белән Галия» җыры чыга. *Йолдызларга йолдыз атылганда, / Очрашканнар көннәр төн белән. / Бу дөньяны белгәнемнән алып, / Синең барлыгыңны мин беләм.*

Фидан Гафаров белән Нурия Ирсаева башкарган ул җырны әтиләре тыңлап туя алмый! Аннан үзе әлеге көйне гармунда уйнарга өйрәнә һәм ул азрак кәефләнеп алган саен, өйдә шушы җыр яңгырый: *«Син кайда, мин шунда, Галиям...»*

Тик йортта әтиләренең бу сәер гадәтенә өйрәнгән өч кыз гына түгел, тагын берәү бар бит әле. Әниләре! Иренең уенда да, телендә дә Галия генә икәнлеген белгән, күргән килеш ул ничек яшәгән соң?! Аның йөрәге моңа ничекләр түзгән?

Тагын Гөлия апаны тыңлыйк:

– Әниегез көнләшмәдемени, дисез... Сез алдагы көнне бу сорауны биргәч, төнката хатирәләр кочагыннан арына алмадым. Кайтып-кайтып уйладым һәм кабат шул фикергә килдем: безнең әни бик акыллы хатын булган! Бөтен ир белән хатын арасындагы кебек, безнең әти белән әни арасында да юктан гына сүзгә килү, үпкәләшүләр була иде, билгеле. Әмма көнләшү аркасында, Галия апаның исеме телгә алынып, өйдә бер тапкыр да тавыш чыкканын хәтерләмим. Ул кызны әнинең бер тапкыр гына күргәне булган. Әтинең сеңлесе безнең әнинең ахирәте булган дип әйткән идем инде: бер тапкыр ул әнине үзләренә аулагөйгә чакыра. Әти дә шул вакыт дуслары белән Галияне һәм Кәримә исемле тагын бер укытучы кызны аулагөйгә алып кайта. «Галия бик чибәр иде», – ди әни... Мөгаен, фотосы әтидә булмагандыр аның, булса, без күргән булыр идек. Кәримә исемле шул укытучы кыз аркылы соңыннан Галия әтигә соңгы хатын тапшырта. «Син бит әле яшь, армиягә барасың да бар. Үз насыйбың табылыр. Ә минем яшем бара, инде кияүгә китәргә кирәк» дигәнрәк сүзләр язылган була анда. Аның юатырга тырышып язган бу юллары аерылышу ачысын көчәйткән генәдер. Әти ул хатны бик озак саклый...

«Көнләшеп, әтиегезнең дә, үземнең дә җанымны кыйнамадым – андый уйлар белән әрнетмәдем. Яратуым да булгандыр... Ул урлап киткәндә 18 яшемдә генә идем. Аңа кадәр башка берәү белән дә йөрмәдем. Әгәр яратмасам, өч ел буе «солдатка» булып та түзеп яшәп бетә алмас идем. Гомер буе әтиегезне санлап, хөрмәтләп тордым», – ди әни.

Әтинең үткәннәре белән яшәве әни өчен кулай да булгандыр дип уйлыйм. Ирләр бик исәптә булган еллар иде бит... Әнинең бер ахирәтенең ире, аны дүрт баласы белән

Фото: Алсу Шакирова

Әнине дә яратып яшәде эти, әмма Галиясен беркайчан онытa алмаганын барыбыз да белә идек…

калдырып китеп, әллә ничә еллар бер тол хатынга йортка кереп яшәде. Тагын берсенең ире, аны ташлап, икенче хатынга өйләнде, аннан өченчегә… Сугыш елларында, әле яшүсмер генә килеш, җиде класс белеме белән авыл советы секретаре булып торган эти. Армиядән шофер һөнәре алып кайтып, байтак еллар машина йөрткән. Әллә ничә ел ферма мөдире вазыйфасын башкарды. Авылдагы барлык тол хатыннарга бик булыша иде дип, әле дә сөйлиләр. Әмма авыл өстенә бер тапкыр да исеме чыкмаган бит аның! «Нигә көнләшим: өстемнән йөрмәде, битемнән көлмәде. Галияне дә, атаңны да җәлли генә идем», – ди әни.

Суфия апаның көнләшмәвенең, сабырлыгының сәбәпчесе (иң зур сәбәпчесе!) дин булгандыр, мөгаен. 12 яшеннән уразасын калдырмаган, гомер буе биш вакыт намазын укыган ул. Нинди генә мәҗлесләр, туйлар узса да, ул вакытта табын күрке аракы була. Әмма кызлары әниләренең кулына чәркә тотып кунак кыстаганын хәтерләми: туганнарны, Газизе белән кара-каршы басып, җырлап сыйлый торган була ул. Башкалардан аерылып торган алар гаиләсе. Икесе дә укырга яраткан, өйләренә бик күп газета-журналлар алдырганнар. «Коммунист» журналыннан башлап, әллә ничә төрле татарча-русча газета килгән аларга. «Азат хатын», «Казан утлары» журналларын да укып барганнар. («Казан утлары»ның бер санында Заһир белән Галия мәхәббәте турында бәян басыла. Әтиләре өчен зур вакыйга була ул! Аны үзе дә укый, кызларына да укыта, хәтта хатынына да укыта.)

Кабат Гөлия апаның хатирәләренә күчәбез:

– Әти бик йомшак күңелле кеше иде безнең. Авыл советы секретаре булып торганда, халыкны көчләп төрле заемнарга яздыру үзегенә ничек үткәнен ул беркайчан онытмады. Кешелекле, юмарт һәм бик ярдәмчел иде безнең эти. Мал туплауга да артык һәвәс түгел иде. Шуңа да бәлки тормыш дилбегәсен әни үз кулына алгандыр. Аның гел күбрәк булдырасы, яңартасы, төзисе килә иде. Әтине дә үзе артыннан кузгата белә иде ул. Әнинең эти-әнисе, туганнары Стәрлетамакта гомер-гомергә мул тормышта яшәде. Бабай тимер юлда эшләде, ир туганнары паровоз машинистлары иде. Андагы әби дә, әнинең апасы да, киленнәре дә гел мамык шәл бәйләп саттылар. Әби Күмертау аша Оренбургка кадәр шәл мамыгына барып йөри иде. Сораучыларга, туганнарга, дусларга әни алардан шәлләр алып кайтып сатты. Бераз булса да үзенә дә файдасы калгандыр инде…

Бер елны чөгендердән уңышны күп алгач, әнинең фотосын «Мактау тактасы»на куйганнар. Ләкин соңрак, хатының спекуляция белән шөгыльләнә дип, этине партия җыелышында бик каты сүгеп, әнинең фотосын «Мактау тактасы»ннан алганнар. Эти шул фотоны алып кайтып әнигә тоттырды да: «Спекулянт исеме күтәрәсең бит хәзер. Туктаткан бул бу гамәлеңне», – диде. Әнинең әллә ни исе китмәде бугай. «Ярар, «Почет тактасы»ннан барыбер икенче елга алып аталар иде инде ул фотоны. Ичмасам, серванттa истәлек булып торыр», – диде. Чынлап та, ул фото бик күп еллар сакланды бездә. Ә «Мактау такта»сына берничә елдан сурәтен барыбер куйдылар аның. Анысы – яшь бозаулар тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен иде. Ул чактагы совхоз директоры әнинең хезмәтен күрә белде, гел югары бәяләде – әни алдынгылар исемлегендә йөрде…

Күп итеп терлек асрап, бакча тутырып суган үстереп сатып, авылда беренчеләрдән булып бишекле мотоцикллы булалар, аннары башта «Запорожец», соңрак өр-яңа «Нива» машинасы алалар. Таштан зур йорт салып керәләр. Кызларына да гел булышып торалар.

Сүз башыннан читкәрәк киттек. Галия! Ул бит һаман да бар, ул бит әле һаман да йөрәктә!

Менә шулай матур гына, тыныч кына яшәп ятканда бер якын туганнарының оныгы Самара өлкәсенең Мансур авылына килен булып төшә. Мансурга – Галиянең туган авылына… Башка туганнар белән бергә, Газиз белән Суфия дә парлашып туйга китәләр.

Туйның икенче көнендә Газиз хатынына:

– Галия кияүгә чыккан авыл моннан ерак түгел икән… Барып күреп кайтыйм әле? – ди.

– Бар шул, күреп кайт – күңелеңне бастыр. Күпме болай газапланып яшәргә була?! – ди Суфиясе.

Кодаларның бер туганы белән машинага утырып чыгып китәләр. Әмма исән чакта кабат очрашулар язмаган икән аларга. Галиянең вафатыннан соң кырык көн генә узган була әле… Газизнең кемлеген, кайдан килгәнлеген белгәч, Галиянең ике тамчы су кебек үзенә охшаган кызы елап ук җибәрә. «Әнием сезне гомер буе күрәсе килеп яшәде… Беркайчан онытмады… Гел сагынып сөйләде», – ди ул. Каберен үз күзләрем белән күреп, салкын туфрагын булса да учыма алып салыйм дигән Газизне ияртеп зиратка да алып бара…

Туй узган йортка кире әйләнеп кайтканда, ирнең йөзеннән нур качкан була, ул ничектер кинәт сүлпәнәеп кала – дөньядан гаме киткәндәй тоела. Шул кичне туйда «Заһир белән Галия» җырын җырлаталар аңардан. Бу кадәр дә моңлы итеп, үзәк-бәгырьләргә үтәрлек итеп җырлаганы булмый әле Газизнең. Кунаклар шаулатып кул чабалар, тагын-тагын җырлавын сорыйлар. Ялындырмый гармунчы – бер ноктага төбәлә дә, кабат шул ук көйне башлый… Аның хәлен, бу мизгелләрдә ниләр кичерүен үзеннән кала, табында берәү генә аңлый. Суфиясе…

– «Ул кичне миңа да бик авыр булды…» – дип сөйли әни. Аның белән барысын да яңадан искә төшереп утырдык әле. Галияне эзләп барганда этигә 65 яшь булган икән…

Ә мәхәббәт чынлап та бар ул! Әгәр бер мавыгу гына булса, гап-гади авыл кешесе булган этиебезгә шушындый олы тойгылар, хис-кичерешләр кайдан килер иде икән?! Галиянең инде исән түгеллеген белгәннән соң, бар калебе белән дин юлына басуы, догалар, намазлар аша җанына тынычлык табуы да мәхәббәт белән бәйледер. 78 яшендә авырып китте дә, бик каты газапланмыйча гына, дөнья белән алыш-биреше өзеп, этиебез бакыйлыкка күчте. Урыны җәннәттә булсын…

Гөлия апа белән килешәм: мәхәббәт бар, һәм ул гомерләрдән озынрак. Шулай булмаса, бу тарих безгә килеп ирешер идемени?!



Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!



tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar







Реклама 6+



Фото: ru.freepik.com



Республика клиник балалар хастаханәсе нефрологы Чулпан ӘШРӘФУЛЛИНА җавап бирә

? Баланың бәвел анализында һәрвакыт тозлар күп була: уратлар, фосфатлар. Балага бу нәрсә белән яный?

Баланың бәвел анализында тозлар табылса, туклану һәм су эчү режимына игътибар итәргә кирәк. Анализ бирегез, бөерләргә һәм сидек куыгына УЗИ ясатыгыз. Тозлар бөерләрдә йә сидек куыгында җыелып, эритроцитлар артуга китерергә мөмкин. Нефрологка һәм гастроэнтерологка күренеп тору мәҗбүри.

? Улыбыз һәр иртә шешенеп уяна. Йөзендә, күз төпләрендә, иреннәрендә бик сизелә бу. Төшкә таба гына шешенүе кими. Моның сәбәбен ачыклар өчен тикшеренүне нәрсәдән башларга кирәк?

Бала иртән шешенеп уяна икән, монда ким дигәндә ике белгеч киңәше кирәк: аллерголог һәм нефролог. Иң беренче чиратта бәвелгә гомуми анализ тапшырыгыз. Нәтиҗәсе белән

? Ярты ел дәвамында инде өченче тапкыр кызыма цистит диагнозы куйдылар. Шулай еш авырып, хроник формага күчү куркынычы бармы? Моны ничек булдырмаска?

Кызганыч, әмма бала шулай еш цистит белән авырый икән, димәк, инде ул хроник формага күчкән. Балагызны нефрологка, урологка күрсәтеп торырга кирәк. Ай саен яки аннан да ешрак бәвел анализы бирергә киңәш итәм. Шулай ук бөерләр һәм бәвел куыгына УЗИ ясатыгыз. Иң мөһиме – бала даими рәвештә табиб күзәтүендә булсын.

? Әни еш кына балабызга үлән чәйләре эчертә. Гөлҗимеш, бөтнек, ромашка, мүк җиләге салып пешерә ул аны. Балага бу үләннәрне даими эчү зыянлы түгелме?

Балаларга иң кулай эчемлек – су. Үлән чәйләрен даими рәвештә эчертергә ярамый. Алар аллергик реакция да чыгарырга мөмкин, шулай ук бөерләргә дә зыяны булмый калмый.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Республика клиник балалар хастаханәсе педиатры Лилия ЗЫЯТДИНОВА җавап бирә.

Балаларның аермасы – яшь ярым. Башта кызыбыз җил чәчәге белән авырый башлады. Табиб чакыртып, ул биргән күрсәтмәләр буенча дәваладык. Биш көннән соң улыбызга да йокты. Аны да шулай ук дәваладым. Ләкин, табибка күренмәү сәбәпле, сәламәтлек картасына җил чәчәге белән авырмаган дип язылган. Җәен лагерьга барганда да проблемага әйләнә бу. Баланың авырганын ничек исбатлап була? Антитәнчекләргә анализ бармы?

Балага җил чәчәге йоккач, табибка мөрәҗәгать итмичә генә дәваланган булсагыз да, бала савыккач табибка барыбер күренергә кирәк иде. Инде озак вакыт узган булса, җил чәчәге антитәнчекләренә анализ бирергә мөмкин. Андый анализ, чыннан да, бар. Анализ югары титрлар күрсәтсә, димәк, бала авырган дигән сүз.

Кызыбызга АКДС прививкаларының өчесен ике ел ярым элек ясаттык. Ел ярымнан ясалырга тиешле ревакцинацияне инде бер ел кичектереп киләбез. Хәзер аны ясатудан мәгънә бармы? Бөтен срокларын узды-рып җибәрдек бит инде...

Ревакцинацияне, әлбәттә, ясатырга кирәк. Аны бераз соңарып ясаудан да зыян юк. Шулай да бу хакта вирусолог белән киңәшләшсәгез була. Ул сезнең очракны аерым тикшереп, үз киңәшен бирер.

Үзебез ялга киткәндә балаларны әбиләре янында калдырдык. Шул вакытта иясез песи баласын алып кайтканнар. Аның бигүк сәламәт булмавы күренеп тора, чирле кебек. Бу песидә токсоплазмоз булырга мөмкинме? Балаларга йоккандыр дип шикләнәм. Ничек ачыкларга?

Әйе, тикшеренәсегез килсә, «Гондии токсоплазма»ларына иммунофермент анализы бирә аласыз. Шулай ук тәрәтне бабасыр күкәйләренә тикшерергә кирәк. Песи баласыннан да анализ алырга киңәш итәр идем. Казанда эпидемиология һәм микробиология институтында паразитларны ачыклаучы анализлар бик югары дәрәҗәдә ясала.

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ—ҖАВАП

ДЕТОКС

Детокс чистарыну дигәнне аңлата. Организмны токсиннардан чистарту өчен интернет киңлекләрендә бик күптөрле детокс-программалар бар. Ул хәзер популяр туклану системасына әверелеп бара. Организмны чистарту һәм сәламәтләндерү елның теләсә кайсы фасылында да актуаль. Ә җәен ул бигрәк тә файдалы һәм нәтиҗәле: бакча тулы яшелчә, җиләк-җимеш. Ләкин аңа ничек итеп әзерләнергә, ничек тукланырга? Бу сорауларны диетолог, нутрициолог Алия САФИНАга бирдек.



Организмга чистарыну кирәклеген ничек аңларга?

Организм үз-үзен чистарта. Иң яхшы «чистартучылар»: кан, лимфа, төкерек, бөер һәм бәвел бүлеп чыгару системасы, ашказаны-эчәк тракты, үпкәләр. Әмма экология, дөрес тукланмау, сәламәт яшәү рәвеше алып бармау аркасында организмда интоксикация барлыкка килә. Аның билгеләре: даими ару, хәтер һәм игътибарлылык таркаулану, шешенү, күз төпләре каралу, баш авырту, йокы туймау, бит тиресе тоныклану, тәнгә тимгелләр чыгу, гөмбә инфекцияләре, иммунитет төшү. Болар инде организмга ярдәм кирәк дигән сүз.

Чистарынуга ничек әзерләнергә?

Барысы да сезнең организмга детокс никадәр кирәк булуыннан тора. Ул һәр өч ай саен өчәр көн, сезонлы (язын һәм көзен җидешәр көн), язын һәр ай саен бер көн була ала. Үзегезнең ихтыяҗлардан чыгып үзегез сайлагыз. Гомумән, детокс курслары бер көннән берничә атнага сузылырга мөмкин. Организмны теләсә кайсы вакытта чистартырга була. Шулай да иң уңайлы вакыт – бер ел фасылы икенчесен алыштырганда. Детоксны башлар алдыннан сөт, кызыл ит, каһвә, алкоголь, шикәр, ярым-фабрикатлар ашауны киметегез. «Иң шәп дустыгыз» чиста су икәнен дә онытмагыз. Көнегезне җылы су эчүдән башлагыз. Чистартылган шикәр, ярма азыклары ашамагыз. Эшкәртү барышында алардагы барлык файдалы элементлар юкка чыга. Төп туклану рационы итеп яшелчәләрне алыгыз. Тәлинкәгезнең яртысы үсемлек продуктларыннан торсын. Ашарга яраклы яшел үләннәрне күп кулланыгыз. Аларда калорий аз, ашказанында урынны күп алалар, димәк, бик озак ашыйсыгыз килмәячәк. Кичке сигезенче яртыдан соң ашауны туктагыз. Кичке сәгать унберенче яртыдан соңга калмыйча йокларга ятыгыз. Чистарыну процессы нәкъ менә төнлә ныклап эшли. Вакытында йокларга ятмыйсыз икән, детокс башлау мәгънәсез. Тирләгез! Даими рәвештә мунчага йөрергә, спорт белән шөгыльләнергә тырышыгыз. Тирләгәндә токсиннар тире аркылы чыга. Ял итәргә өйрәнегез. Бу да бик мөһим.

Детоксны диета алыштыра аламы?

Организмны чистартканда диетолог һәр кешегә шәхси программа төзи. Кайбер кешеләргә дәвалау диетасы да таләп ителергә мөмкин. Шуны да онытмаска кирәк: детокс – ашаган ризык күләмен киметү дә. Җәй алдыннан диета тотучыларга каршы бер сүз дә әйтмим. Әмма безнең организм елга бер генә тапкыр түгел, һәр көнне пычрана. Шуңа күрә чистарынуны даими үткәреп торырга кирәк.

Ай буе шикәр һәм камыр ризыкларын кулланмау детокс булып саналамы?

Шикәрдән һәм камырдан баш тарту – организм өчен зур плюс. Детоксның иң гади алымы да – шул. Артык тән авырлыгын югалтырсыз, целлюлиттан котылырсыз, энергиягез артыр.

Җәйге сезонда нинди детокс-программа иң яхшысы?

Детокс өчен бер көнлек рацион тәкъдим итәм.

- Иртәгезне бер стакан кайнар су эчүдән башлагыз. Смузи эчегез. Аны бер бәйләм шпинат, бер алма, 1 чәй кашыгы бал, 150 мл су, ярты сельдерей сабагыннан ясарга була.
- Әбәткә яшелчәләрдән суда пешкән аш һәм «щётка»-салат ашагыз. Салат рецепты: пекин кәбестәсе, кишер, кыяр, яшел үлән, 1 чәй кашыгы көнҗет мае, тоз.
- Көн дәвамында имбир һәм бөтнектән ясалган җылы эчемлек, цикорий һәм иван-чәй эчә аласыз.
- Кичке ашка да яшелчәләрдән пешерелгән ризык.
- Йоклар алдыннан фенхель һәм әнис төнәтмәсе эчегез. Икенче көнне яхшы кәеф белән уянырсыз.

Детокс-диетаны ничек тәмамларга?

Кисәк туктарга ярамый, чистарыну программасын әкренләп тәмамларга кирәк. Беренче атнада ярма азыклары, ипи, шикәр ашамагыз. Соңрак рационга әз-әзләп боткалар, аш, ит кертеп, гадәти менюга кайтыгыз.

КОБИДО

Кобидо – япон чибәркәйләренә йөзләренең яшьлеген һәм матурлыгын сакларга ярдәм иткән борынгы мануаль алым. Әлеге техника турында беренче тапкыр 1472 елда ук язганнар. Европага бу массаж төре XX гасырда гына керә һәм шунда ук популярлаша. Кобидо япон теленнән «матурлыкны саклау юлы» дип тәрҗемә ителә. Һәм ул, чынлап та, битнең яшьлеген саклап калу өчен иң нәтиҗәле ысул булып тора. Бу массажны ясаганннан соң тире күзәнәкләренең тернәкләнү функциясе яхшырак эшли башлый. Йөз, муен, баш мускуллары киеренкелектән чыгып, кан йөреше яхшыра. Аны ясаганда майны күп кулланып ясау мөһим. Кобидо массажын матурлык белгечебез Ләйсән САБИТОВА өйрәтә.





- Гадәттәгечә, массажны күкрәк өслеген әкренләп каккалаудан, уртадан күкрәк читенә таба бармаклар белән «тырмалаудан» башлыйбыз. Бу – лимфа йөрешен уятып җибәрер өчен кирәк.
- Баш бармак нигезе белән муенның кырыйларын, артын астан өскә таба ышкыйбыз. Калкансыман биз урнашкан җиргә тимәгез.
- Ике кулның да имән һәм урта бармакларын ыргак кебек бөклибез, иякне эләктерәбез һәм капма-каршы якка, ягъни колакларга таба хәрәкәт иттерәбез.
- Имән һәм урта бармаклардан кайчы ясап, өске һәм аскы иреннәр кырыена куябыз да елмаю рәсеме ясыйбыз.
- Ике як чигәгә перпендикуляр итеп имән бармакларны куябыз һәм баш бармаклар белән бит алмаларын массажлыйбыз.
- Борын читләрен, кырыйларын урта бармак очлары белән ышкыйбыз.
- Каш арасындагы җыерчыкларны бетерәбез. Моның өчен чәч үскән җиргә параллель итеп имән бармакларны куябыз да баш бармаклар белән ике каш арасын өскә таба тиз-тиз сыпырабыз.
- Имән бармакларны кара-каршы китереп, маңгайны ышкыйбыз.
- Бит йөзен бармаклар белән чеметкәләп чыгабыз, аны тарттыру өчен йөзнең тирә-ягын колакка, чәч үскән урынга таба массажлыйбыз.



















QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Алмалы крамбл

Бакчаларда алма исе генә! Август ул – алма ае. Бу нигъмәтләрдән туйганчы авыз итеп каласы иде бит. «Матур булыйк» сәхифәсе аша яхшы таныш тренер Резеда МУСИНА алмадан бик тәмле крамбл пешерергә тәкъдим итә. Резеда – Башкортстанның Илеш районы Бишкурай авылы кызы. Казан театр училищесын тәмамлап, актриса-педагог белгечлеге ала. Ләкин язмышын театр белән бәйләми, тренер һөнәрен үзләштереп, хәзер шушы өлкәдә хезмәт куя. Аш-су әзерләү белән мавыгып китүе дә тренерлык эшенә бәйле. «Мин дөрес туклану яклы – шикәрне, тиз үзләштерелүче углеводларны кулланмыйм. Тел йотарлык тәмле ризыкларны алардан башка да әзерләп була. Үзем пешерә торган торт, чизкейк, меренгалы рулетларда бодай оны да, шикәр комы да юк», – ди ул. Сер итеп әйтик, киләчәктә үзенең кондитер кибетен ачарга хыяллана Резеда. Билгеле инде, бирелә бары тик файдалы десертлар гына булачак. Резеданың аш бүлмәсендә көне буе кояш һәм... җыр. Ул үзе дә җырлар яза. Менә нинди талантлы безнең кызлар! Ә крамблга әйләнеп кайтсак, ул бик җиңел әзерләнә, ингредиентлары да гади генә. Әйдәгез әле, өебезгә август алмаларының хуш исен таратып, бергәләп әзерлик аны. Дөрес, бу юлы он һәм шикәр комын кулланабыз, ләкин шикәрне табигый баллаткычларга (мәсәлән, стевия) алмаштырырга мөмкин.



Кирәк (биш кешелек гаилә өчен) / 500 г алма / 100 г көрән шикәр комы / 150 г он / 85 г атланмай / 60 г гадәти шикәр комы / 1 чәй кашыгы дарчин (корица) / 35–40 г әстерхан чикләвеге.

Эш барышы

■ Атланмайны вак шакмакларга кисеп, суыткычның туңдыру камерасына куеп торабыз. Май бик туңган булырга тиеш.
■ Әстерхан чикләвеген ваклап, коры табада 5 минут чамасы кыздырабыз. Болай аның тәме тагын да ныграк сизелер. Вакытыгыз чикле булса, чикләвекне кыздырмаска да мөмкин.
■ Алмаларның кабыгын әрчеп, шакмаклап турыйбыз. Шакмаклар артык вак булмасын. Крамбл өчен алманың катырак һәм әчкелтемрәк сортлары яхшы. Андый алмалар пешергәндә изелми дә.
■ Коры табага көрән төстәге шикәр комы, дарчин һәм туралган алмаларны салып, утка куябыз. Шикәр, эреп, карамельләнә башлый. Алмалар, йомшарып, суты бүленеп чыгу белән тагын бер тапкыр яхшылап болгатабыз да табаны уттан алабыз. Алма кисәкләре карамель белән капланырга тиеш.
■ Тирән эчле савытка он, гадәти шикәр комы һәм туңдыргычтагы атланмайны салып, камыр валчыгы ясыйбыз. Монда бер мөһим сер бар: майны фәкать чәнечке белән генә изәргә кирәк. Югыйсә май, кул җылысыннан эреп, камыр кетердәвек булмый.
■ Крамблны аерым-аерым кечкенә формаларда да, зур табада да әзерләргә мөмкин. Форма төбенә башта әзер алмаларны салабыз. Аннары кыздырган чикләвекне кушабыз. Теләсәгез, алма белән чикләвекне күбрәк тә алырга була.
■ Чикләвек өстенә камыр валчыгын түшибез һәм табаны алдан ук 180 градуска кадәр кыздырылган мичкә куябыз.
■ Крамбл якынча 25 минуттан әзер була (һәркемнең миче төрлечә пешерә, аны да исәпкә алыгыз).

Гадәттә, кайнар крамблны табынга салкын туңдырма белән чыгаралар. Алай тагын да тәмлерәк. Монысы инде баллыны яраткан кешеләр өчен.

Чәйләрегез тәмле, тормышыгыз ямьле булсын!


















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Өйнең яме — гөлләрдә




Гибискус

Гибискусны икенче төрле Кытай розасы дип йөртәләр. Аның чәчәк атканын сабырлар гына күрә ала, чөнки ул озак үсә. Тропик үсемлек буларак, яктылыкка, суга һәм һаваның дымлылыгына таләпчән. Өйдә үстерергә уйласагыз, көнчыгышка яки көнбатышка караган якты тәрәзә төпләрен сайлагыз. Көндез туры төшкән кояш нурлары яфракларын һәм чәчәкләрен көйдерергә мөмкин. Яктылык җитәрлек булмаганда ясалма яктыртырга туры киләчәк. Бу гөл артык эссене өнәми, 20–22 градус җылылыкта яхшырак үсә. Кышын температура 15–18 градус җылы булса кулай. Гибискуска җәен һәм язын суны мул һәм еш сибәләр. Сугарганчы, туфракның өске өлеше кибеп өлгерергә тиеш. Кышын исә туфрагының өске өлеше кипкәннән соң да ике-өч көн көтәргә кирәк. Һаваның дымлылыгы югары булганны яратканлыктан, яфракларына әледән-әле су бөркеп торалар. Ләкин суны чәчәк бөреләренә тидермәскә тырышыгыз, югыйсә таплар барлыкка килүе бар. Чәчәк атучы башка гөлләр кебек үк, ул да даими тукландыруга мохтаҗ. Язын составында азот, тимер һәм бакыр булган ашлама кулланасалар, чәчәк аткан чорда фосфор һәм калий кирәк. Гадәттә ашлауны айга ике тапкыр башкаралар. Чәчәк бөреләренең яшь сабакларда гына формалашуын истә тотып, яз көне карт ботакларны кыскартып киcәләр. Чәчәк атып бетергәннән соң ботак очларын кыскартып кисү дә әһәмиятле. Яшь гөлне – ел саен, ә картракларын ике-өч елга бер күчереп утырталар. Зур гөлләрне күчермиләр, туфрагының өске ягын гына алыштыралар. Һәр күчергәндә чүлмәкнең беразъ зуррагын сайлыйлар, ләкин кечкенә гөлне зур савытка утыртмагыз: ул бар көчен тамыр үстерүгә сарыф итәчәк. Гибискусның тагын бер үзенчәлеге – урын алыштырганны яратмый.

Шеффлераны зур чүлмәкләрдә агач кебек үстерәләр. Өй шартларында 2,5 метрга кадәр үсә ала ул. Яфракларының җилпәзә сыман үзенчәлекле формасына күрә, аны зонтик-агач дип тә йөртәләр. Бу гөлнең сабаклары бик нәфис, тераү булмаса, сынып китәргә мөмкин. Бер чүлмәккә берничә кечерәк гөл утыртканда аеруча матур күренә. Соңыннан аларның сабакларын үзара үреп куярга да була.

Шеффлера якты урынны ярата, көньяк тәрәзәгә якын урында әйбәт үсә. Температурага талымлы түгел, бүлмә шартларында үзен яхшы хис итә. Бары үтәли җилдән һәм температураның кисәк уйнавыннан гына сакларга кирәк, югыйсә яфракларын коя башлавы бар. Һаваның дымлылыгына таләпчән булмаса да, ара-тирә су бөркеп торсаң, яфракларының төсе тагын да җетеләнеп китә. Суны чама белән, туфрагы кипкәннән-кипкәнгә генә сибәләр. Туфрагында артык дымны ул авыр кичерә, суны да тондырып кына сибәргә кирәк, йомшак һәм җылы су ярата. Гөлне яздан көзгә кадәр атнага ике тапкыр универсаль ашлама белән тукландыралар. Кышын аның тынлык чоры, бу чакта ашларга кирәкми. Ябалдашларын куерту өчен, язын шеффлераның очларын кыскарталар, төптән чыккан яңа тармакларын өзәләр. Шул рәвешле аны җыйнак кына агач рәвешендә үстерергә мөмкин. Ел саен кисмичә, берничә елга бер тапкыр 30–40 сантиметрга кыскартырга да була. Шеффлераны үрчетүе авыр түгел, яшь тармагыннан да, төптән чыккан үсентеләрдән дә үстереп була аны.



Шеффлера



Азалия

Азалия – нәзберек гөл. Аңа әчелеге югары булган туфрак кирәк, шуның өчен туфракның азалияләр яки рододендроннар өчен махсус әзерләнгәнен сатып алырга туры килә. Кояш нуры туры төшмәгән якты урынны ярата. Аз гына күләгәле урында да үстерергә мөмкин, ләкин чәчәк бөреләре яралганда (көзгә якка туры килә) һәм чәчәк атканда (кыш айлары) ясалма яктыртырга туры киләчәк. Салкынча температурада гына яхшы үсә. Чәчәк атканчы температура 15–18 градус, ә чәчәк атканда 10–12 градус җылы булса әйбәт. Җәй көне 20 градуска кадәрге җылыны да кичерә ала, ләкин чәчәк бөреләрен коярга мөмкин. Җәй көне аны көнбатыш яки төньяк тарафка караган балконга чыгара аласыз. Һаваның дымлылыгына таләпчән. Дымлылыкны арттыру өчен, янына сулы савыт куярга була. Азалияне үстергәндә тагын бер кыенлык – суны дөрес сибү. Туфрак дымлы булырга тиеш, әмма артык дым тамырларына зарарлы. Сугарганнан соң, тәлинкәгә агып төшкән суны шунда ук түгәргә кирәк. Җәйге чиллэдә яки туфрагы артык кибеп китсә, гөлегезне салкынча сулы табакка утыртып тора аласыз. Шәһәр җирендә краннан килгән су азалияләр өчен яраксыз, анда хлор һәм известь бар, моны да истә тоту зарур. Ун көнгә бер тапкыр суга берничә тамчы лимон суты тамызып сибү, туфракның әчелеген арттыра, чәчәк атуны яхшырта. Чәчәк атканда атнага бер калий һәм фосфорлы ашламалар белән ашлау таләп ителә. Әгәр чәчәк бөреләре әле ачылмаган булса, азалияне сатып алу белән башка савытка утырту яхшы. Бөреләре ачылса, чәчәк атып бетергәнен көтәргә туры килә. Күчергәндә савытның саерагын һәм калын стеналысын сайларга кирәк. Аны яшь тармакларны тамырландырып үрчетәләр. Вакытында кисеп, формалаштырып торуны таләп итә.



Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

Фото: ru.freepik.com

тест:
сез төпле кешеме?

Төпле кешеләр берәр нәрсәгә тотынганчы, башта «җиде кат үлчи». Ә кемнәрдер уйламыйча гына яшәргә күнеккән. «Арба ватылса – утын», дип, шулар хакында әйтәләр инде.
Сез кайсы төркемгә керәсез икән, тикшереп карыйк әле.

1. Кечкенә генә бер сәбәп тә сезне чыгырдан чыгара аламы?
2. Үзегездән шактый көчле кешенең ачуын китерүдән куркасызмы?
3. Башкаларның игътибарын үзегезгә җәлеп итү өчен генә низаг чыгарган чакларыгыз буламы?
4. Гомерегезгә куркыныч янаса да, кызу тизлектә йөрергә курыкмыйсызмы?
5. Авырганда дарулар белән мавыгасызмы?
6. Теләккә ирешер өчен теләсә нинди адымга бара аласызмы?
7. Зур этләрне яратасызмы?
8. Сәгатьләр буена кояш астында утыру ошыймы?
9. Кайчан да бер танылачакмын дип ышанасызмы?
10. Оттыра башлавыгызны сизүгә, вакытында тукталып кала беләсезме?
11. Тамагыгыз ач булмаса да, күп ашау гадәтегез юкмы?
12. Үзегезгә нәрсә бүләк итәселәрен алдан белеп тору ошыймы?

Әйдәгез инде, балларны саныйк.
2 нче һәм 10 нчы сорауга «әйе» дип җавап бирсәгез – 1 балл, 1, 3, 4, 5, 6, 8, 9, 11, 12 нче сорауларга «юк» дип җавап бирген булсагыз – 1 әр балл куегыз.

8 баллдан күбрәк. Сез бик зирәк кеше. Төптән уйлап эш итәсез, таләпләрегез артык күп түгел. Ләкин тормышка чак кына җиңелрәк карау сезгә комачауламас иде, мөгаен. Бу кешеләр белән мөнәсәбәтләрне дә җиңеләйтеп җибәрәчәк.
4 баллдан 8 баллга кадәр. Алтын урталык. Сезнең чама хисегез яхшы. Үз мөмкинлекләрегезне яхшы беләсез, күктәге торнага өметләнмисез. Кайчагында җилбәзәкләнеп тә алгалыйсыз, ләкин бу сезгә күркәмлек кенә өсти.
4 баллдан кимрәк. Сез – уйламый гына эш итә торган кеше. Сезгә һаман барысы да аз. Канәгатьсезлек аркасында үзегезне еш кына бәхетсез хис итәсез. Тормыштагы вак-төяккә дә шатланырга өйрәнегез, алар аз түгел бит.

йолдызнамә
сентябрь

Кучкар. Сәламәтлекне ныгыту, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне җайлау өчен яхшы вакыт. Катлаулырак мәсьәләләрне айның беренче яртысында хәл итәргә тырышыгыз, соңрак моңа күбрәк көч сарыф итәргә туры килер.

Үгезбозау. Иҗади ачышлар һәм үзенчәлекле фикерләр ае бу сезнең өчен. Кызыклы идеяләрегезне тормышка ашыру өчен, әлеге форсаттан файдаланып калыгыз. Ләкин акчалар белән сак булу кирәк, шикле адымнарга бармагыз.

Игезәкләр. Барысы да план буенча бара. Үзегезне күрсәтү, абруегызны арттыру өстендә эшләсәгез, уңышка ирешерсез. Моның өчен максатчанлыкны, инициативагызны ныграк күрсәтергә кирәк.

Кысла. Яңа стратегия төзү, яңа планнар кору өчен моннан да яхшырак вакытны табуыгыз икеле. Мөһим чараларны, эшлекле очрашулар, әһәмиятле килешүләрне, икеләнмичә, хәзер билгели аласыз.

Арыслан. Энтузиазмыгыз ун кешегә җитәрлек, ләкин үзегезне билгеле бер кысаларда тотарга туры килер. Яңа эшкә алынсагыз, отарсыз. Гомумән, тормышыгызда яхшы якка үзгәрешләр булуы көтелә.

Сөмбелә. Үз-үзегезне табу, күптәнге планнарны тормышка ашыру өчен кулай чор. Моңарчы тотынырга куркып торган эшләрне дә хәзер җиңел генә башкару форсаты чыгар, яхшы ярдәмчеләр табарсыз.

Бизмән. Иң кыю планнарга нәкъ менә хәзер тотына аласыз. Мөһим эшләр башлар өчен – уңай чор. Хәзер танышкан кешеләр, төзегән килешүләр – киләчәк өчен ныклы нигез булачак.

Чаян. Моңарчы борчыган проблемаларның чишелеше табылыр. Кайдандыр көтелмәгән ярдәм күрсәтерләр. Сәяхәт кылу, яңа дуслар табу, яңа эшкә керешү өчен кулай вакыт. Алда яхшы перспектива көтелә.

Укчы. Ай позитив дулкында узачак. Яңа проектларга курыкмыйча тотына аласыз. Үзегезне тормышыгызның чын хуҗасы итеп тоярсыз: фикерегезгә колак салырлар, абруегыз артыр.

Кәҗәмөгез. Уйлап табу, фикерләү сәләтегез бик югары. Күптәнге проблемаларны хәл итү нәкъ менә шушы чорда җиңел бирелечәк, мөмкинлектән файдаланып калыгыз. Бу ай күңелле вакыйгалары белән истәлекле булыр.

Сукояр. Күңелегезгә тынычлык бирүче үзгәрешләр булыр. Дөньяга башкача карап, күп кенә сорауларыгызга җавап табарсыз. Тормышыгызның рәхәт һәм тыныч чоры, үз-үзегез белән тулы гармониядә булудан тәм табачаксыз.

Балык. Финанс хәлегезне яхшыртыр өчен форсат килеп чыгар. Күптән күрәсе килеп йөргән кешегезне очратырсыз. Тормышыгызда яңа перспективалар ачылырга тора, аларны сизми калмагыз.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.









СЫННАРЫНДА – ТАТАР МОХИТЕ

Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, сынчы Винера Абдуллина – заманыбызның иң актив иҗатчыларыннан берсе. 1965 елда Ленинградта туган, бүген дә шунда яшәп иҗат итә. Сынчы илебезнең Сынлы сәнгать академиясе карамагындагы Б. В. Иогансон исемендәге урта сәнгать мәктәбен, В. А. Серов исемендәге сынлы сәнгать-педагогика училищесын, И. Е. Репин исемендәге академик сәнәгать институтының скульптура факультетын, аннары аспирантураны уңышлы тәмамлаган. 2001 елдан Винера Зәви кызы үз эшләре белән төрле күргәзмәләрдә катнашып килә, шәхси күргәзмәләрен дә ача.

Аның Сөембикә-ханбикәгә багышланган сыннары да бар. Винера ханым бу тарихи шәхеснең образын берничә төрле итеп уйган. Гомумән, сынчы иҗатында кече пластикадагы хатын-кыз образлары җитәрлек. Ә җитди һәйкәлләргә килсәк, Казанда урнаштырылган «Казан әбисе» сыны да күпләргә ошый.

Винера Абдуллина – Россия Сынлы сәнгать академиясенең гипс эшләнмәләр ясау остаханәсе җитәкчесе. 1999, 2000, 2002 елларда Санкт-Петербургның «Петербург музалары» дип аталган грант бәйгесендә җиңеп чыккан тырыш затларның берсе. Әсәрләре Санкт-Петербург, Мәскәү, Иваново, Казан, Дагстанның Махачкала, Казакъстанның Семей, Свердловск өлкәсенең Серов, Ленинград өлкәсенең Тосно, Любань шәһәрләрендә, Кама Тамагы районы үзәгендә, Тукай районының Яңа Бүләк авылында урнаштырылган. Иҗатчыбызның Тукай, Җәлил, Туфан Миңнуллин, Петр I, граф Сергей Витте, Лев Гумилев, Бөек Ватан сугышында һәлак булган Советлар Союзы Герое Туйчи Эрджигитов, даһи җырчыбыз Илһам Шакиров бюстларын халык яратып кабул итте.

Винера ханым үз милләте тарихын, мәдәниятен, сөекле әнисе Зәкияне, кадерле әтисе Зәвине, кече Ватанын һәрчак йөрәк түрендә тотып, милли тематикага еш мөрәҗәгать итә. «Милләтемнең бар уңышлары – иҗатым өчен саекмас илһам чыганагы. «Сабантуй», «Татар авылы», «Балачак», «Мин тудым» темаларына сыннар иҗат иттем. Бүгенге көндә татар сәнгать эшлеклеләре бюстларын ясыйм», – ди ул. Петроградта 1905–1917 елларда татар телендә чыккан «Нур» газетасына нигез салучы А. Баязитов бюсты да – аның эше. Ул 2011 елда Санкт-Петербургта урнаштырылды.


Винера үзле балчыктан да төрле эшләнмәләр ясый, китап графикасын да үз итә. Мәсәлән, «Мөхәммәд пәйгамбәр – бөек кеше, һәрчак һәм бүген» китабын бизәгән чәчәкләр аның кылкаләме белән ясалган. Казыя Мөхлисә Бубый сурәтләнгән рельефын исә ул Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе Диния нәзарәтенә бүләк итте. «8 нче сыйныфта гарәп телен үзлегемнән өйрәндем, ике ел дәвамында гарәп теле курсына йөрдем. Шәмаилләремдә Аллаһы Тәгаләнең 99 күркәм исемнәре язылды, – дип аңлатты сынчы. – Инде безгә кадәр үк иҗатчылар: «Дөньядагы гомеребез кыска, әмма сәнгать дәвамлы», дип әйтеп калдырган. Мин дә үз сәнгатемнең, шул исәптән, татар мохите, тарихы белән бәйле сыннарымның озак еллар буе саклануын теләр идем!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









ВИНЕРА АБДУЛЛИНА




Шах
Group
баклава лукум продукт

КИБЕТ АДРЕСЫ: КАЗАН, МАРТЫН МЕЖЛАУК УР., 6 НЧЫ ЙОРТ
ОФИС АДРЕСЫ: КАЗАН, ПОСЕЛКОВЫЙ ПЕРЕУЛОК УР., 31 НЧЕ ЙОРТ
ЭЛЕКТРОН ПОЧТА: INFO@SAHGROUP.RU
САЙТ: WWW.SAHGROUP.RU
ВКОНТАКТЕ: ШАХ-ГРУПП БАКЛАВА-ПРОДУКТ
ТЕЛЕФОННАР: 8 987 297 01 41, 8 987 222 16 16



РЕКЛАМА



